«Татмедиа» ААҖ
«Мәгариф» журналы редакциясе
Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге
Казан (Идел буе) федераль университеты

Белем һәм тәрбия чарасы буларак татар журналистикасы

«Мәгариф» журналының
100 еллыгына багышланган
фәнни-гамәли конференция материаллары

26-27 февраль, 2014 ел

Казан - 2014

Белем һәм тәрбия чарасы буларак татар журналистикасы: «Мәгариф**»** журналының 100 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары (26-27 февраль, 2014 ел) / төзүче-редакторлары В.З.Гарифуллин, Р.Л.Зәйни. – Казан, 2014. – 178 б.

БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ БИРҮДӘ ГАММӘВИ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫНЫҢ РОЛЕ

Дәүләт тарафыннан игълан ителгән тематик елларның татар матбугатында чагылышы («2012 - Мәдәни мирас елы» мисалында)

И.И. Ахунова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Л.Зәйни)

Татарстанда тематик елларның гадәти хәлгә әйләнеп баруын күзәтә алабыз. Бер-бер артлы үтеп киткән Хәйрия, Гаилә, Спорт, Укытучы еллары вакытлы матбугатта да һәрдаим иркен яктыртылып килде. Бу өлкәгә караган мәкаләләр, интервьюлар, укучыларның күңел борчуларын җиткергән хатлар һ.б. шундый язмалар татар матбугатында шактый очрады. Әмма, узган елларга әйләнеп карасак, бу тематик елларның артык нәтиҗәләргә китерә алмавы күренә.

«Мәдәни мирас елы» белән бәйле язмалар да матбугатта инде гадәтләнгән рәвештә билгеле бер күләмдә урын алды. Без төрле характердагы газета-журналларны өйрәндек. Татарстанда чыккан һәрбер басмада диярлек (биредә сүз шәхси басмалар турында бармый) «Мәдәни мирас елы» белән бәйле язмалар урын ала. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» кебек газеталарда бу темага багышланган язмалар шактый. Әлбәттә инде, «Казан утлары», «Мирас» кебек әдәби журналлар бу теманы берничек тә читләтеп үтә алмый. Без исә дүрт басманы аерым тикшердек: «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» һәм «Безнең гәҗит». Бу газеталарны сайлавыбызның сәбәбе бар: бердән, аларда «Мәдәни мирас елы» белән бәйле язмалар башкаларга караганда күбрәк; икенчедән, бу басмалар үзләренең тоткан юнәлешләре белән бер-берсеннән шактый аерылалар, шуңа күрә аларны үзара чагыштырып өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирде.

2012 - «Мәдәни мирас елы»ның гаммәви мәгълүмат чараларында яктыртылышын өйрәнеп, без түбәндәгеләрне аңладык. Бу елны тарихи-мәдәни мирас белән бәйләү, һичшиксез, рухи-мәдәни яңарыш идеясе белән яшәүче зыялылар һәм Татарстан Республикасы Президенты тырышлыгы белән нигезләнгән. Аның төп максаты тарихи һәйкәлләрне торгызу гына түгел, ә бәлки татар халкының милли-мәдәни асылын тагын да ныгыту, халыкны уйландыру, үзаңын тирәнәйтү белән дә бәйле. Шуңа күрә аны бары тарихи-мәдәни мирас объектларын торгызу белән алшартланган чаралар җыелмасы дип кенә карарга ярамый, киресенчә, ул татар халкының мәдәниятен үстерүгә нигезләнгән чараларны да алга куя. Мондый зур проблемага вакытлы матбугат, һичшиксез, битараф кала алмый. Шулай да «Мәдәни мирас елы» тиешле дәрәҗәдә яктыртылган, дигән нәтиҗә дөреслеккә туры килмәс иде. Без тикшергән басмалардан «Ватаным Татарстан» газетасында гына язмаларның

саны шактый күп. Ә башка газеталарда берничә мәкалә яки гомуми күзәтү характерындагы язмалар белән чикләнелә. Шул ук вакытта проблемалы мәкаләләр бик аз.

Татар телендәге газета-журналларны, иң беренче чиратта, милли мәдәниятне, сәнгатьне һәм тарихны саклап калу, торгызу, үстерү проблемасы борчый. Шуңа күрә без тикшергән басмаларда нәкъ менә әлеге мәсьәләгә игътибар зур да. Төрле журналистларның язмаларында татар халкы тормышында зур урын биләгән күренекле шәхесләр белән бәйле хатирәләрне, истәлекләрне торгызу, милли китапханә бинасы белән бәйле проблема, мәдәниятебезне башка халыклар тарафыннан бозып күрсәтүгә мөнәсәбәт кебек сораулар укучы хөкеменә тапшырыла. Әйтергә кирәк, мондый язмаларның барысын да бер рух берләштерә: аларда тәнкыйть һәм борчулы уйланулар беренче урынга чыгарыла. Мәсәлән, бер төркем язмаларда милләтебезнең асыл йолдызлары турындагы истәлекләрне саклау, шул максаттан, аларга багышланган музейларның аяныч хәле, аерым берләренә истәлек йортларын ачу ихтыяҗы хакында сүз алып барыла. Әйтик, «Ватаным Татарстан»да Чистайдан Ә.Әгъзамованың «Исхакый музее аяныч хәлдә» дип аталган мәкаләсе басылган (Әгъзәмова Ә. Исхакый музее аяныч хәлдә // Ватаным Татарстан, 2012, 20 авг.).

Журналистларны халыкның, дәүләтнең тарихи биналарга карата битарафлык күрсәтүе борчый. Бу хакта күренекле әһелләр белән әңгәмәләр, укучы хатлары, журналистларның үткен һәм борчулы хисләр белән сугарылган язмалары әледән-әле матбугат битләрендә күренеп тора.

Дөрестән дә, тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклап калу – республика алдында торган бурычларның берсе. Бу мәсьәләгә, өстәвенә, тематик ел кысаларында, вакытлы матбугат һич битараф кала алмаган. Югарыда язылганнардан күренгәнчә, әлеге юнәлештәге эшләрнең торышы турындагы язмалар каршылыклы характерда. Болгар һәм Свияжск яңарышы белән бәйле мәкаләләрдә күтәренке рух хөкем сөрсә, Казандагы яңалыклар артык шатландырырлык түгел. Узган елның башында дөньяга чыккан язмаларда әле «Мәдәни мирас елы»ның нәтиҗәләр бирәчәгенә өмет беркадәр булса, ахырга таба ул ышаныч сүрелә. Газеталарда корылмаларның юкка чыгу алдында торуын әйтеп чаң суккан мәкаләләр арта.

Безнең карашыбызча, мондый рухтагы язмалар «Мәдәни мирас елы» концепциясенә югары дәрәҗәдә җавап бирә. Республикада игълан ителгән бу тематик ел исемнәре хаксыз рәвештә онытылган күренекле шәхесләребезнең якты истәлекләрен халыкка танытырга тиеш иде. Ә без һаман татарча берничә сүзне дә бәйләп әйтә алмаган җырчы Алсу, гимнастка Алинә Кабаева, Марат Бәшәровларны милләттәшләребез дип горурланабыз, алар исемен мәңгеләштерәбез. Ә халкыбызга фидакарьләрчә хезмәт иткән йөзләгән шәхесләребезнең исеме хаксызга онытылган. Р.Вәлиевнең матбугатта дөнья күргән сүзләре әлеге фикерне бик төгәл җиткерә: «Менә сәүдәгәрләр шәһәре – Алабуга бик матур итеп аякка бастырылды. Кемне алып барсаң да, йөз кызармас кебек. Күптән түгел генә әлеге кала турында фотоальбом чыкты. Бик

әйбәт эшләнгән. Әлбәттә, Алабуга, нигездә, урыс шәһәре. Әмма бит анда «Татар эзе» дә бар. Альбомга ни өчендер Тажи Гыйззәтне, опера җырчыларыннан иң беренче булып СССРның халык артисты исемен алган Азат Аббасовны кертмәгәннәр. Бит алар Алабугада яшәгән. (...) Алабуга урыс шәһәре икән, татарны телгә алу мәҗбүри түгел, янәсе. Анда Шишкинны, Дурованы, татарны явыз көчеккә тиңләгән Цветаеваны зурлыйлар. Альбомны төзүчеләр дә татарлар бит әле...» (Гыйлемханов Р. Татарның тагын бер фаҗигасе // Ватаным Татарстан, 2012, 17 июль).

Чыннан да, «Мәдәни мирас елы» кысаларында, иң беренче чиратта, милли тарихыбызны торгызу буенча эшләргә кирәк. Ә үз-үзен хөрмәт итмәгән халыкның башка милләтләрдә ихтирам уята алуы шикле. «Барысы да конкрет кешеләрдән, аларның осталыгы, профессионализмыннан, ягъни, бүгенгечә әйтсәк, кеше капиталыннан тора. Кадрлар әзерләү, реставрация, музей, архитектура һәм археология мәктәпләрен үстерү, гражданлык җәмгыятенең өлгерү һәм Татарстан җитәкчеләренең сәяси ихтыяр көченә ия булу зарурилыгын аерым билгеләп үтәргә кирәк. Җыеп кына әйткәндә, барыбызның уртак тырышлыгы белән генә Татарстанның тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен торгыза алачакбыз», - дип, ЮНЕСКОның архитектура һәм шәһәр төзелеше ядкарьләрен саклау кафедрасының Идел буе бюросы җитәкчесе Рафаэль Вәлиев, һичшиксез, хак фикер әйтә.

Һәм бу юнәлештә алып барылган эштә гаммәви мәгълүмат чараларының керткән өлеше зур. Бу хакта Р.Вәлиев болай дип билгели: «Ни гаҗәп: законны санга сукмаучылар тикшерү, җавапка тарту органнарыннан бигрәк, матбугат, радио-телевидение аша халыкка «танылудан» күбрәк курка икән. Тарихи мирасны саклау мәсьәләләре буенча узган киңәшмә уңаеннан шау-шулы мәгълүматлар тарала башлагач, инвесторлар безгә шалтырата башладылар: «Ярый, шауламагыз инде, эшләрбез», – диләр».

Димәк, татар халкының милли-мәдәни һәм тарихи мирасын саклап калуда вакытлы матбугатка йөкләнгән бурыч гаять олы икән. Газеталарда әлеге проблемага бәйле мәкаләләр шул хакта сөйли.

Газеталарны тикшерү барышында, без, нигездә, ел тематикасына бәйле берничә проблемага гына игътибар итү тенденциясенең көчле булуын күрдек. Әйтик, шундый мәсьәләләрдән Болгар һәм Свияжск шәһәрләрен торгызу өлкәсендәге эшләр киң яктыртыла. Беренче карашка, әһәмиятле һәм кирәкле гамәл. Әмма бу да әле бәхәсле мәсьәлә булып тора. Чөнки күп кенә кешеләрдән: «Болгар бу үзгәрешләр белән тарихи йөзен югалта» дигән хакыйкый фикерне ишетергә мөмкин. Әмма матбугатның моңа фикере бер: «Алга таба Татарстанда яшәүчеләр башлаган изге эшкә Парижда бәя бирергә мөмкиннәр. Изге Болгар һәм Свияжск шәһәр-утравын ЮНЕСКО исемлегенә кертү өчен, документларны Париждагы Бөтендөнья мирас үзәгенә тапшырганнар инде.» (Вәлиева Э. Болгарның үз барсы бар // Ватаным Татарстан, 2012, 20 март). Ни генә булса да, әлеге проблема игътибарга лаек, әмма аны хәл итүгә авторитетлы кешеләр алынган, М.Шәймиевнең шәхесе генә дә күп мәсьәләләрне хәл итәргә, бөтен ишекләрне ачарга мөмкинлек бирә, шуңа

күрә вакытлы матбугатта бу хакта зурдан кубып сөйләшү үзен аклады микән? Әле бит безнең дөрестән дә көн кадагында торган милли-мәдәни мәсьәләләребез байтак. Гаммәви мәгълүмат чаралары иң беренче чиратта әнә шуларга игътибар итәргә тиеш иде.

Әйтик, милли мәдәниятебез ядкарьләрен, тарихи мирасыбызны саклап калуны яктырткан мәкаләләр матбугатта бик аз. Күренекле шәхесләребезгә багышланган музейларның аянычлы хәле республикабызны бизәми бит. Ерак китәсе юк, ел саен макталган, милли шагыйрь булып кабул ителгән Тукай музеен төзекләндерү эшләре «Тукай елы»нда тормышка ашырыла алмаганны, 2012 елда моңа зур өметләр баглау мөмкин дә булмас иде.

Язма мирасыбызны саклап калу да зур проблема булып тора. Китапханәләрнең дәүләт тарафыннан тиешле дәрәҗәдә финансланмавы мәдәнилегебезнең түбәнәюенә дә өлеш кертә. Әнә шул хакта язмалар күбәйсә, бәлки, дәүләт эшлеклеләренең дә игътибары артыр иде.

Күп кенә мәкаләләрнең «янгыннан соң чаң кагу» кебек яңгыравы да ачык. Инде күпме тарихи-мәдәни истәлекләребез юкка чыгарылган, җимерелү алдында тора. Мөмкин булганнарын саклап калу юнәлешендә эшкә вакытлы матбугат ныклап тотынса, гаять әһәмиятле хезмәт булыр иде. Төрле журналистик тикшеренүләр, тематик басмалар дөнья күреп, язмаларның нәтиҗәләре буенча шул эшләргә җаваплы кешеләр белән сөйләшүләр оештырылса, бәлки, нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек туар иде. Халкыбыз нәкъ менә шундый рухтагы язмаларга мохтаҗ.

Гомумән, вакытлы матбугатны җентекле күздән кичерсәк, 2012 нче ел гаммәви мәгълүмат чаралары өчен «Мәдәни мирас елы»ннан бигрәк, «Универсиадага әзерлек» елы булды кебек.

Региональ матбугатта наркомания темасының яктыртылуы

А.А.Әгъзәмова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
Л.Р.Сабирова)

Татарстан Республикасында бүген наркотик кулланучы 17 меңнән артык кеше бар. Әмма бу рәсми күрсәткеч кенә. Чынбарлыкны күзаллау өчен әлеге санны 10 га тапкырларга кирәк. Наркомания белән авыручылар саны ел саен 600-700 кешегә арта (Хөснуллин И. Үлем хәзер кыйммәт тормый // Ватаным Татарстан, 2011, 9 ноябрь).

Наркомания – чорыбыз афәте. Бу яман чирне җиңәр өчен гаммәви мәгълүмат чаралары да үз көчләрен өсти. Журналистика җәмгыять фикерен формалаштыруда, социаль проблемаларны хәл итүдә зур ярдәм күрсәтә. Журналистика бу очракта пропаганда һәм профилактика функциясен үти һәм ул наркоманиянең нәрсәгә китерәчәген өйрәтергә, сөйләргә, язарга тиеш.

2001 елда журналистлар өчен наркомания проблемасын яктырту тарафыннан төп принципларны үзенә алган беренче документ дөнья күрә. Бу «Наркотиклар куллану проблемасын һәм профилактиканы яктырткан вакытта Россия электрон һәм басма гаммәви мәгълүмат чаралары журналистларының җаваплылыгы» турында Декларация.

Гаммәви мәгълүмат чараларының, шул исәптән, матбугатның төп функциясе һәм максаты – җәмгыятьне тулысынча мәгълүмат белән тәэмин итү.

Наркомания проблемасын яктыртуда региональ матбугатның төп максаты – аудиториядә наркотик маәтдәләргә карата тискәре мөнәсәбәт булдыру.

Бүгенге көндә наркомания проблемасын матбугатта яктыртуда жанрларның ике зур төркеме беренче урынны алып тора: хәбәри һәм аналитик жанрлар**.** Хәбәри жанрлар наркомания буенча укучыга, гомумән аудиториягә соңгы хәбәрләрне җиткерсәләр, аналитик жанрлар бу проблеманы яктыртуда башка рольне үти. Алар укучыга проблеманың асылын, аның чишү юлларын, сәбәпләрен күрсәтергә тырыша.

Вакыйга/факт турындагы хәбәрне укучыга оператив ирештерү функциясен башкаручы *хәбәри жанрлар* вакытлы матбугатта киң кулланыла торган иң әһәмиятле жанрлардан исәпләнә. Теләсә кайсы газетаның бер генә саны да алардан башка чыкмый. Нинди генә матбугат органында эшләмәсен, нинди генә темага язмасын, хәбәри жанрга һәр журналист мөрәҗәгать итә. Әлеге темалар арасында наркомания дә искәрмә түгел. Региональ матбугатта, гомумән матбугатта, наркомания проблемасы хәбәри жанрлар аша еш яктыртыла.

Оператив хәбәр итү функциясе хәбәри жанрларны бер төркемгә туплап өйрәнергә мөмкинлек бирә, аларга хас уртак билгеләрнең сәбәпче булып тора.

Бу уртак билгеләрнең иң беренчесе, күзгә ташлана торганы – мәгълүматлылык. Журналистика теориясендә мәгълүмат билгеле бер максатлардан чыгып сайлап алынган, социаль әһәмияткә ия булган факт яки фактлар җыелмасы дип аңлатыла. Димәк, хәбәри жанрлар, кагыйдә буларак, социаль әһәмияткә ия булган яңалыкны хәбәр итә. Наркомания проблемасы, чыннан да, социаль әһәмияткә ия булган темалар рәтенә керә.

Икенче мөһим билге – оперативлык. Вакыйга яки факт турындагы язма газета битендә тиз арада дөнья күрмәсә, үзенең актуальлеген югалта. Оперативлык – мәгълүмати язмаларның һәм матбугат органының кыйммәтен билгеләүче иң мөһим фактордан санала. Ул, үз чиратында, хәбәри жанрлар өчен характерлы булган тагын бер уртак сыйфатны билгели: материалларның күләме җыйнак.

Документальлек һәм төгәллек – хәбәри жанрларның аерылгысыз билгесе. Аларда сүз конкрет урын һәм вакыт, конкрет вакыйгалар турында бара. Шуңа күрә бу жанрда иҗат итүче аеруча төгәл һәм объектив булырга тиеш.

Хәбәри жанрлар төркеменә хәбәр (хроника-хәбәр, аңлатмалы хәбәр, тойгылы хәбәр, хат-хәбәр), хисап (кыска хисап, киңәйтелгән хисап, стенографик хисап, проблемалы хисап), репортаж (вакыйгалы репортаж,

тематик репортаж, проблемалы репортаж, тәнкыйди репортаж), интервью (интервью – монолог, интервью – диалог, интервью формасында белгеч киңәшләре, интервью «түгәрәк өстәл», интервью – зарисовка, интервью – сораштыру, пресс-конференция).

Хәбәр – газетадагы иң киң таралган жанр. Вакытлы матбугат белән бер ук чорда барлыкка килсә дә, ул бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмаган. Ул, кагыйдә буларак, мөһим бер факт-вакыйганы тиз генә укучыга хәбәр итү максатында кулланыла һәм гадәттә «нәрсә?», «кайда?», «кайчан?» дигән сорауларга җавап бирә. Жанрның күләм ягы чикле: язмалар күп очракта бер яки берничә абзацтан артмый.

Әлеге жанрга мисал итеп «Шәһри Казан» газетасында басылган «Татарстанда зур күләмдә героин табылган» дигән хәбәрне китерә алам. Әлеге материалда Татарстанның наркоконтроль хезмәткәрләренең Мәскәүдәге хезмәттәшләре белән уздырган операция вакытында 175 кг героинны кулга төшергәннәре турында хәбәр ителә. Күләм ягыннан хәбәр жанрына туры китереп язылган әлеге материал тулысынча «нәрсә?», «кайда?», «кайчан?» сорауларына җавап бирә. Әлеге хәбәрнең баш исеме дә бөтен текстның кыскача эчтәлеген атап бирә.

Наркомания темасына багышланган күп кенә конференцияләр, җыелышлар, киңәшмә, утырышлар, пресс-конференцияләр үткәрелә. Әлеге сөйләшүләргә корылган вакыйгаларны матбугатта яктыртучы жанр – *хисап.* Хисап теләсә нинди вакыйга турында түгел, ә, кагыйдә буларак, сөйләшүгә корылган вакыйга турында сөйли.

Хисап текстның хәбәр кебек җыйнаклары да, шактый күләмлеләре дә очрый. Монысы инде куелган максатка бәйле. Аерым бер вакыйга җәмгыятебез тормышында никадәр зуррак әһәмияткә ия булса, матбугат битләрендә ул шулкадәр киңрәк яктыртыла.

«Шәһри Казан»да басылган «Наркотикны телефон аша сата башлаганнар» дигән хисап Эчке эшләр министрлыгы уздырган брифингка корылган. Кыска хисапка кертер идем мин бу язманы. Чөнки автор Ч.Нәҗипова вакыйганың иң мөһим этапларын гына оператив рәвештә хәбәр итә, әлеге брифингтан укучы өчен кирәкле дип тапкан бер цитата гына китерә: «Хәзерге вакытта традицион наркотиклар (героин һ.б.) кисәк кенә кими башлады. Аларга алмашка, синтетик наркотиклар ясау өчен, яңа психоактив матдәләр ала башладылар. Безнең белгечләр ел башыннан 48 төргә якын яңа психоактив матдә теркәделәр, шуларның 7 се закон тарафыннан тыела». Шулай ук статистик мәгълүмат, саннар кулланып эш итә.

Күп кенә очракларда газета укучыны наркомания турында яңалыклар гына канәгатьләндерми. Факт һәм вакыйгаларның асылына төшенергә, наркомания проблемасының сәбәпләрен ачыкларга, наркомания авыруы белән чирләүче кешеләр белән сөйләшергә, күп кенә проблемаларны чишәргә дә туры килә. Әлеге максатларда журналист тарафыннан *аналитик жанрлар* кулланыла.

Аналитик жанрларда эшләү зур тырышлык та, тирән белемнәр дә таләп итә. Үзеңә кирәкле фактларны туплау өчен күп урыннарда булырга,

документлар өйрәнергә туры килә. Кайбер язмаларны атналар гына түгел, айлар буе эшлисең. Проблеманы тәмам чишкәнче, язган темаңа кабат-кабат әйләнеп кайтырга, берничә язма әзерләргә дә туры килә.

Аналитик жанрлар төркеменә керүче төп жанрлар - *рецензия, күзәтү, мөхбирнамә, мәкалә, журналист тикшерүе*. Анализга корылган *хатларны* (ачык хатны) да бу төркемгә кертергә була. Хисапның һәм интервьюның шулай ук аналитик характердагылары очрый.

Аналитик жанрларны башка төр журналистик текстлардан аерып торучы төп асыл сыйфат – аларның дәлилләүгә корылуы. Аналитик жанрның кайберләре (теоретик мәкалә, мөхбирнамә, күзәтү) күбрәк мантыйкый исбатлауга таянса, икенчеләрендә (ачык хат, рецензия, публицистик мәкалә) психологик дәллиләү өстенлек ала.

Наркомания проблемасын яктыртуда аналитик жанрлар арсында зур урынны *мәкалә* жанры алып тора.

Мәкалә – журналистикадагы мөһим жанрларның берсе, ул чынбарлыктагы күренешләрне анализлау нигезендә иҗтимагый әһәмияткә ия булган проблема күтәрелүе, бу проблеманы чишү юлларын күрсәтеп дәлилле йомгак-нәтиҗәләр ясалуы белән характерлана. Бер үк күренеш мөхбирнамәнең дә, мәкаләнең дә объекты булып тора ала. Автор мәкаләдә күренешне тормышның башка яклары белән бәйләнештә анализлый, аны масштаблы нәтиҗәләр ясау, гомумиләштерү һәм типиклаштыру өчен файдалана.

Наркомания темасына мәкалә жанрында күбесенчә «Ватаным Татарстан»да язалар. Мисал итеп Р.Фәтхрахмановның «СПИДка каршы көрәш», «Хирыслык хирыслыкка ялгана, яки Порнобәйлелек турында» дип исемләнгән мәкаләләрен, Ф.Арсланованың «Сыендыручы учак» язмасын китерә алам. Әлеге материалларда иҗтимагый әһәмияткә ия булган проблема – наркомания проблемасы күтәрелә, «Сыендыручы учак»та наркомания белән авыручы яшь балалы әниләрнең киләчәге, бүгенгесе турында языла, бу проблемаларны чишү юллары күрсәтелә, дәлилләр китерелә, тормыштан мисаллар да урын алып тора. Әлбәттә, бу мәкаләләргә укучы берничек тә битараф кала алмый.

Фәнни мәкаләмнең төп максаты итеп мин үзебезнең региональ матбугатта наркомания проблемасына багышланган материалларны жанр ягыннан тикшерүне куйган идем. Моның өчен мин Казан шәһәрендә чыга торган ике газетаны кулландым: «Ватаным Татарстан» һәм «Шәһри Казан». Әлеге газеталар башкалар белән чагыштырганда наркомания проблемасын күбрәк яктырта һәм жанр ягыннан тикшерүе дә җиңелрәк һәм конкрет нәтиҗәләр ясарга да мөмкинлек зуррак.

Язмаларны жанр ягыннан анализлау өчен мин газеталарның 01.09.2012 - 08.03.2013 дәвәрендә дөнья күргән саннарын карап чыктым, түбәндәге нәтиҗәләргә килдем һәм аларны таблица рәвешендә күрсәтәм:

№1

Газета исеме	**Саны**	**Материал исеме**	**Материалның жанры**

«Ватаным Татарстан»	22.02.2013	«Сыендыручы учак» Ф.Арсланова	Аналитик жанр Мәкалә
	08.03.2013	«Чирен яшергән – үлгән» И.Хөснуллин	Аналитик жанр Аналитик интервью
	05.02.2013	«Тикшерү – уен эш түгел» И.Хөснуллин	Аналитик жанр Аналитик хисап
	23.01.2013	«Хирыслык хирыслыкка ялгана, яки Порнобәйле-лек турында» Р. Фәтхрахманов	Аналитик жанр Мәкалә
	27.12.2012	«СПИДка каршы көрәш» Р.Фәтхрахманов	Аналитик жанр Мәкалә
	30.11.2012	Рәсми хәбәрләр	Хәбәри жанр Хәбәр
	21.11.2012	«Дөньяви мәктәп хикмәтләре» Р.Фәтхрахманов	Аналитик жанр Мәкалә
	19.09.2012	«Бер дә күңелле түгел»	Хәбәри жанр Хәбәр

№2

Газета исеме	**Саны**	**Материал исеме**	**Материалның жанры**
«Шәһри Казан»	13.12.2012	«Эзләрсең – таба алмассың»	Хәбәри жанр Хәбәр
	11.12.2012	«Наркотикны телефон аша сата башлаганнар» Ч.Нәҗипова	Хәбәри жанр Хисап
	30.11.2012	«Татарстанда зур күләмдә героин табылган» Ф.Мотыйгуллин	Хәбәри жанр Хәбәр
	16.11.2012	«Балалар алкогольдән агулана»	Хәбәри жанр Хәбәр
	04.12.2012	«Бу ни хәл, җәмәгать?» Р.Сальмушев	Аналитик жанр Мәкалә
	30.10.2012	«Йөрәге янмаса, тәмәке дә пыскытмый» Ф.Мотыйгуллин	Аналитик жанр Мәкалә

Шундый нәтиҗәләргә килергә мөмкин: региональ матбугатта наркомания проблемасына багышланган язмалар күбесенчә аналитик яисә хәбәри жанрларда иҗат ителә. Аналитик жанрда мәкаләләр зур урын алып торса,

хәбәри жанрларда интервью, хәбәр, хисап та очрый. Шунысы да игътибарны җәлеп итте: «Ватаным Татарстан» газетасы, «Шәһри Казан» белән чагыштырганда, наркомания проблемасын күбрәк яктырта һәм материаллар аналитик жанрда иҗат ителә, ә «Шәһри Казан»да күбесенчә хәбәри жанрда язылган материаллар очрый. Авторларга килгәндә, Ф.Мотыйгуллин, И.Хөснуллин, Р.Фәтхрахманов бу темага актив яза.

Татар теле дәресләрен милли информацион технологияләр кулланып укыту

Ф.В.Вафин, Арча районы Яңа Кенәр
махсус гомумбелем интернат-мәктәбе укытучысы

XXI гасыр кешенең көндәлек тормышына мәгълүмати электрон технологияләрнең күпләп үтеп керүе белән башланып китте. Кәрәзле телефоннарга, электрон системалы көнкүреш машиналарына, компьютерларга хәзер беркем дә шаккатмый. Алар гап-гади, көндәлек кулланыш кирәк-яраклары буларак кабул ителә. Яшәешне электрон технологияләр чолгап алган заманда, укучыларга белем бирү процессы да үзгәрешсез кала алмый. Төрле электрон дисклардан, интернет челтәреннән әзер, бирелеше ягыннан үтемле эшләнгән мәгълүматны кыска гына вакыт эчендә күчереп алырга күнегеп килүче укучы өчен, аның кабул итү мөмкинлегенә туры килгән яңа, белем бирүдә заманча мәгълүмати технологик чаралар уйлап табу - бүгенге мәктәпнең төп бурычы булып тора.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, ул телебезне саклап калу булса, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын, иҗади эшли белүен таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык - бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш-үзгәрешне тәэмин итә.

Соңгы елларда илебез мәктәпләрендә күп предметлардан белем бирүдә компьютер техникасы һәм башка мәгълүмати технологияләр кулланыла. Чөнки гадәти укыту алымнары иҗади эзләнүгә тулысынча ачылырга ирек бирми, ә хәзер илгә киләчәген алдан күрә, планлаштыра белгән һәм шуны тормышка ашыру юлларын ачык төсмерләгән шәхес кирәк. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез белә. Ул бүгенге базар икътисады шартларында югалып калмаска, тәнкыйди уйлый һәм мөстәкыйль

карарлар кабул итә, ярдәмләшеп эшли һәм аралаша белергә тиеш. Мәктәпләрдә шундый шәхес тәрбияләүгә нәкъ менә яңа информацион педагогик технологияләр куллану ярдәмгә килә.

Мәгълүмати технологияләрне укыту-тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты. Укучы эшчәнлеген компьютер технологиясе ярдәмендә тирәнтен, төптән үзгәртү зур әһмияткә ия.

Мәгълүматлаштыру белем бирү процессына зур йогынты ясый. Ул белем бирү процессын үтемлерәк итәргә, белемне кабул итү тизлеген арттырырга, зур күләмдәге материалны аңлап, тирәнтен үзләштерергә ярдәм итә. Башта информацион технологиянең эчтәлеген ачыклап китик. Белем бирүдә информацион технология – компьютер техникасы һәм төрле программа чаралары ярдәмендә мәгълүматны әзерләү, саклау, эшкәртү һәм җиткерү процессы ул.

Белем бирүдә кулланыла торган информацион технологияләр берсен икенчесеннән аерып булмый торган ике өлештән тора: беренчесе – техник чаралар (компьютер техникасы һәм шуңа бәйләнеш чаралары); икенчесе – билгеле максатта кулланылган төрле программа чаралары.

Әгәр укытучы дәресне оештырганда компьютер кулланырга уйлый икән, ул югарыда әйтелгән чараларның мөмкинлекләрен һәм куллану тәртибен белеп эш итәргә тиеш.

Компьютер - укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Интерактив такта куллану дәресләрне тагы да кызыклы итәргә ярдәм итә.

Ни өчен татар теле дәресләрендә компьютер техникасы куллану кирәк, информацион технология чаралары кулланып, дәрестә нинди мәсьәләләрне чишеп, хәл-итеп була? Шушы сорауга җавап биреп карыйк.

Беренчедән, укучыларда туган телне өйрәнүгә кызыксыну барлыкка килә. Балалар мәктәптә укытылган башка фәннәр арасында туган телне дә компьютер, Интернет кулланып өйрәнергә мөмкин икәнлеген күрәләр. Бу исә телнең абруен күтәрүдә зур этәргеч булып тора. Электрон белем бирү сайтында цифрлы белем ресурслары (ЦОР) урнаштырылган. Монда татар телен өйрәнү өчен 18 дәрес темасы бар. Һәр темага лексика, грамматика, диалоглар һәм аудирование күнегүләре урнаштырылган. Татар телен өйрәнү өчен онлайн-дәреслек күптөрле уеннар, биремнәр, кроссвордлар белән дә тулыландырылган.

Соңгы зур яңалык – мультимедиалы интерактив «Бала» китапханәсе барлыкка килү. Монда татарча мультфильмнар карарга мөмкин. Әлегә – алар 36, ләкин аларның саны гел артып тора. Бала китапханәсендә мультикларны караганнан соң, белемне тикшереп карау өчен кызыклы биремнәр дә бирелә.

Мондый интерактив белем бирү чаралары баланың фикерләү сәләтен үстерә, эстетик тәрбия бирә, информацион культура тәрбияли, укытуның

сыйфатын күтәрә, предметара бәйләнеш булдырырга ярдәм итә, укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уята.

Туган тел дәресләрендә информацион технологияләр укытучыга нинди методик мөмкинлекләр бирә? Шуларны карап китик.

– Дәрес материалы, тема ачык итеп күз алдына килә. Мәсәлән, «Кыш» темасына текстлар укыганда, укучыларның күз алдында кышкы табигать, карга күмелгән авыл урамнары, көрт баскан басу-кырлар, кар бөртекләре пәйда була;

– укучыга үз белемен үзе тикшерергә мөмкинлек туа. Тест формасындагы биремнәр нигезендә экранга карап үз-үзләрен тикшерәләр һәм үз эшләрен бәялиләр;

– индивидуаль белем бирелә;

– дифференциаль белем бирелә;

– мультимедиа һәм интернет аша зур күләмле мәгълүмат алырга өйрәтелә;

– мәгълүматны каталоглар һәм белешмәләр кулланып эшкәртергә өйрәтелә;

– укыту процессында кирәк булган материалларны тупларга өйрәтелә.

Туган телне укыту процесында информацион технологияләр куллану махсус программалар белән эш итә белүне күз алдында тота. Алар түбәндәгеләр: электрон дәреслекләр, контроль ясаучы тестлар (мондый тестларны, дәрес материалына яраклаштырып, укытучы үзе дә төзи ала), информацион-белешмә программалар (сүзлекләр, энциклопедияләр), күрсәтмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар).

Презентация формасында эшләнгән слайдларны дәресләребездә еш кулланабыз. Сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик уңайлы. Г.Тукай, М.Җәлил кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре, грамматиканы өйрәнү өчен эшләнгән әзер презентацион программалар да бар.

Хәзерге көндә электрон белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора. Республикабыз мәктәпләренә төрле предметлардан компьютерлар өчен эшләнгән гамәли укыту программалары кайтартылды. Татар теле дәресләрендә куллану өчен «Минем беренче сүзлегем» һәм «Татар теле-2002», «Татар телле Заман», «Татар теле – 5-11» (2009) h.б дип аталган компакт-дисклар чыкты. Дөресен әйтик, бу дисклар гына безнең ихтыяҗларны канәгатьләндерми.

Мондый программаларны куллану укытучы хезмәтен җиңеләйтә, дәрескә хәзерләнү өчен күп вакытын янга калдырырга ярдәм итә, укучыларның белем алу омтылышын үстерә.

Бүгенге көндә мәктәпләрдә зур мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар, җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Без бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшебездә кулланырга тырышабыз.

Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, анысын да истә тотарга кирәк, чөнки мондый дәрескә әзерлек

укытучыдан күп вакыт та таләп итә. «Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый» дигән сүзне дә еш ишетергә туры килә. Бу сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эшләү ул укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле күнегүләр, чаралар белән үрелеп барырга тиеш.

Дәрестә вакытлы матбугат материаллары белән эшләү

М.Д.Гарифуллина,
Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге
2 нче гимназиясе мөгаллиме,
Татарстанның атказанган укытучысы

Халык күпчелек мәгълүматны телевизор экраннарыннан, Интернет челтәреннән алган бүгенге чорда яшь буынны басма сүзгә карата ихтирамлы итеп тәрбияләү мәктәпнең мөһим бурычы булып тора. Бу уңайдан дәресләрдә газета-журнал материаллары белән эшләү әһәмиятле урын тота.

Вакытлы матбугат белән даими танышып бару бер яктан мәктәп баласының дөньяга карашын киңәйтүдә, мәгълүматын баетуда зур роль уйнаса, икенче яктан, балаларның сөйләм культурасын үстерергә дә ярдәм итә.

Шуны истә тотып, мәктәптә газета-журнал материалларына ешрак мөрәҗәгать итү зарур. Бигрәк тә татар теле дәресләрендә моның өчен мөмкинлекләр зур. Мәсәлән, публицистик стиль телебездә, матур әдәбият стиле кебек үк, киң кулланылышка ия һәм дәресләрдә әлеге стильнең үзенчәлекләрен матбугат мисалларында өйрәтү аеруча нәтиҗәле.

«Лексика» бүлеге буенча дәресләрне тулысынча газета мисаллары ярдәмендә үткәрергә мөмкин. Чөнки газетадагы теләсә нинди язмада, хәтта кечкенә генә хәбәр текстында да телдәге төрле катлам лексикасын очратырга була. «Телнең сүзлек составы һәм аның үзгәрүе» темасын өйрәнгәндә, теоретик материалны аңлатканнан соң, укытучы балаларга теге яки бу газетадан кечерәк кенә күләмле текстны сайлап алып яздыра. Шуннан соң укучылар текстка анализ ясыйлар: татар теленең үз сүзләрен, алынма сүзләрне һәм халыкара сүзләрне махсус таблицага урнаштыралар.

Газета-журнал текстларын шулай ук татар телендә сүзләрнең ясалыш төрләрен өйрәнгәндә файдаланырга мөмкин. Укучылар андый текстлардан татар телендә сүз ясалышының барлык төп төрләренә карата да мисаллар таба алалар.

Вакытлы матбугат материаллары белән эшләгәндә, балаларга газетаның үзенә генә хас, үзенчәлекле лексикасы булуы турында әйтергә кирәк. Чөнки гаммәви мәгълүмат чаралары тормышыбызга көннән-көн киңрәк үтеп керә барган хәзерге заманда газета өчен генә хас булган сүзләр, әйләнмәләр белән

укучыларга еш очрашырга туры килә. Бу төр лексик катламны газетизмнар дип атыйлар. Укучыларны әлеге төр берәмлекләрне таный белергә өйрәтергә кирәк.

Әлбәттә, газета теле укучы өчен үрнәк түгел. Әмма тормышта төрле очракта төрлечәрәк сөйләшергә кирәк була. Әйтик, рәсми обстановкада (мәсәлән, җыелышларда) күп очракта иҗтимагый-сәяси терминнарны кулланып сөйләргә дә туры килә. Шуңа күрә укучылар андый терминнарның мәгънәләрен кече яшьтән аңлап үсәргә, аларны үз сөйләмнәрендә актив куллана белергә тиешләр. Ә мондый термин һәм әйләнмәләр иң күп кулланыла торган өлкә – ул вакытлы матбугат, аерым алганда, газета. Татар теле дәресләрендә, сәясәт, икътисад, фән, мәдәния т һәм башка өлкәләрдә кулланыла торган сүзләрне классификацияләп, таблицалар төзү, дөнья хәлләре һәм ил яңалыклары турындагы информацияләрдән файдаланып, диктант һәм изложениеләр яздыру да уңай нәтиҗә бирә.

Класс сәгатьләрендә татар телендә чыга торган газета-журналларга күзәтү ясау максатка ярашлы. Моны укучылар үзләре башкарса, бигрәк тә нәтиҗәле була. Бу күзәтүләрне махсус график буенча һәркем сөйләсен. Гомумән, мондый күзәтү газетадагы яңалыкларны гына укып чыгуга кайтып калмаска тиеш. Аны алып баручы дөнья һәм ил яңалыклары турында сөйләсен, ул яңалыкларга карата үзенең фикерләрен дә белдерсен. Фикер алышуда барлык укучыларның да актив катнашуына ирешү мөһим. Аңлашылмаган сүзләрне, терминнарны язып бару өчен, һәр укучының махсус дәфтәр тотуы да зыян итмәс. Чөнки ул сүзләрне белү аларга киләчәктә, җәмгыять тормышында активрак катнаша башлагач кирәк булыр.

Хәер, иҗтимагый-сәяси терминнарны, газетизмнарны куллана белү укучыларга мәктәптә үк (мәсәлән, мәктәп газеталарын чыгарганда) кирәк. Мәктәп басмасын чыгару, мәктәп сайтын яңарту укучылардан газета теле үзенчәлекләрен аңлап эш итүне сорый. Ләкин күп очракта укучыларга мондый әзерлек җитенкерәми. Шулай итеп, укырга кызыксыз, шаблон җөмләләр белән чуарланган мәктәп басмасы яки сайт дөньяга чыга. Шуңа күрә укучыларның газета жанрларына хас тел һәм стиль үзенчәлекләрен белүләренә ирешү бик мөһим. Аларны өйрәнүне татар теле түгәрәкләрендә, «Яшь хәбәрчеләр клубларында» оештыру уңай нәтиҗә бирә. Моңа төрле жанрлардагы газета материалларын иҗат итү күнегүләре башкару юлы белән генә ирешергә мөмкин. Шуны онытмаска кирәк: хроника-хәбәр, хисап кебек жанрлар стандарт әйләнмәләргә, газетизмнарга һәм терминнарга бай була, репортажга җөмләләрнең кыска, ләкин шул ук вакытта эмоциональ булуы, сөйләмнең беренче заттан алып барылуы хас, тасвирнамә һәм очерк кебек жанрларда образ тудырырга ярдәм итүче чаралар – фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр, метонимия һәм башка бик күп төрле сурәтләү чаралары актив кулланыла. Гипербола, антитеза һәм оксюмороннарны исә фельетон һем памфлетта күпләп табарга мөмкин; интервью жанрында сөйләү стиле элементлары киң урын ала.

Укучылар мондый үзенчәлекләрне конкрет материаллардан табып күрсәтә, теге яки бу тел чарасының ни өчен кулланылуын да әйтә белергә тиешләр. Мәсәлән, интервью жанры сөйләү стиле элементларыннан киң

файдалана, дидек. Ни өчен шулай? Чөнки интервью – кәгазьгә төшерелгән әңгәмә. Ул гади сөйләмгә, җанлы әңгәмәгә охшарга тиеш. Сөйләү стиле, иң беренче чиратта, интервьюның синтаксик төзелешендә чагылыш таба:

«– Ә чаңгыда йөрү белән күптән мавыгасызмы?

– Әйе. Балачактан. Җиденчене тәмамлагач, унынчы класска кадәр күрше авылга йөреп укырга туры килде. Җәен – велосипедта, кышын – чаңгыда.» («Ватаным Татарстан» газетасыннан.)

Интервьюда әнә шундый ким җөмләләр еш кулланыла. Бу вакытта җөмләнең иясен, хәбәрен яисә башка кисәген әңгәмәдәшнең алдарак әйткән фикереннән, хәтта журналист биргән сораулардан да эзләргә туры килә. Мисалдан күренгәнчә, ким җөмләләр куллану сөйләмне җанландыра, аңа әңгәмә рухы өсти. Аларда өстәлмә конструкцияләр һәм инверсияләр куллану да шушы ук функцияне үти.

Интервью жанрында сорау җөмләләр, туры сөйләм һәм автор сөйләме кулланылышы да үзенчәлекле.

Интервью жанрын формалаштыруда, синтаксик элементлардан тыш, лексик һәм морфологик чаралар да актив катнаша. Бу жанрдагы материалларда китап сүзләре, газетизмнар, рәсми әйләнмәләр һәм терминнар да була. Чөнки интервью публицистик стильгә караса да, гомумән, газета өчен хас булган барлык үзенчәлекләрне дә берләштерә. Морфологик яктан анализ ясаганда, интервьюларда зат алмашлыгы һәм фигыльнең, башлыча, беренче затта кулланылуы күзгә ташлана.

Биредә без интервью жанрының кайбер үзенчәлекләренә генә игътибар иттек. Газета жанрларыннан тел дөресләрендә файдалану мөмкинлекләре дә күп төрле. Аларны ачыклау, анализлау укучыларның сөйләм культурасын күтәрергә, телне практик куллана һәм андагы бетмәс-төкәнмәс байлыклардан файдалана белү күнекмәләрен нык ытуга ярдәм итә.

Татар телен өйрәнүнең барлык этапларында, барлык классларда да вакытлы матбугат материалларына игътибар итәргә кирәк. Лексиканы гына түгел, морфология һәм синтаксисны өйрәнгәндә дә газета-журналлардан нәтиҗәле файдаланырга була. Морфологияне өйрәнгәндә, мәсәлән, газета материалларыннан һәр сүз төркеменә караган мисалларны күпләп табарга мөмкин.

Ә стилистиканы үзләштергәндә, публицистик стильгә мөрәҗәгать итү, аны язмалар мисалында өйрәнү аеруча зарур.

Вакытлы матбугат материаллары белән эшләүне елдан-ел катлауландыра, аны куллануның формаларын һәм алымнарын төрләндерә һәм җанландыра бару максатка ярашлы.

Шулай итеп, газета-журналлар татар теле дәресен тормыш белән бәйләүнең, аны тагын да кызыклырак, җанлырак итүнең үтемле бер чарасы булып тора.

Татар мәгарифен үстерүдә Интернет челтәренең әһәмияте

Р.М.Гатауллин, Татнетны үстерү фонды директоры,
«Белем.ру» ҖЧҖ директоры,
«Белем.ру» һәм «Татар иле» интернет-проектлары җитәкчесе

Интернет челтәренең үсеше һәм мәгариф учреждениеләрен Интернет челтәренә тоташтыру мәгариф өлкәсенә сизелерлек үзгәрешләр кертте. Белем бирү процессында да, мәгариф системасы белән идарә итүдә дә Интернет бүген төп рольләрнең берсен уйный башлады. Ә татар мәгарифендә Интернет челтәренең тоткан урыны нинди? Алар арасында нинди бәйләнеш? Интернет челтәре үсеше белән бергә татар мәгарифе үсеше дә күзәтеләме?

Татар мәгарифе алдында торган кыенлыклар һәркемгә диярлек мәгълүм. Татар телендә белем бирү системасының үз стандартлары, үз нормативлары юкка чыгып бара. Глобализация чорында татар теленең әһәмияте дә киметелеп күрсәтелә, мәгариф системасын рус теленнән бигрәк инглиз теле колачлап килә. Инде бүген Россиянең югары уку йортлары, шул исәптән Казан вузлары да, рейтингларда беренче урыннарны алу өчен, үз профессорларына инглиз телен өйрәтәләр. Студентларга белемне инглиз телендә бирүне максат итеп куйган вакытта татар мәгарифенең үсешенә нинди өмет багларга соң?!

Нәкъ әлеге мәсьәләдә татар мәгарифенә Интернет челтәренең (төгәлрәк әйткәндә, Интернет челтәренең татар сегментының - Татнетның) күрсәткән ярдәме алыштыргысыз зур. Әлеге сегмент, иң беренче чиратта, татар мәгърифәтчеләре көче белән ныгып килә, алар булдырган интернет-ресурслар, үз чиратында, татар мәгарифен үстерүгә зур ярдәм күрсәтәләр. Инде бүген татар мәгарифе өлкәсендәге сайтлар Татнетның 25-30%ын тәшкил итә (http://tatarile.org/catalog/tt).

Бу урында Татнетны һәм Интернет челтәрендә татар мәгарифен ныгыту өстендә эш алып барган кайбер мөгаллимнәрнең исемнәрен һәм аларның интернет-проектларын әйтми калу мөмкин түгел:

- Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы (http://tarkhanova.ru),
- Җәлилова Гөлназ Илсур кызы (http://gzalilova.narod.ru),
- Шакиров Булат Мәхмүт улы (http://meshabash.ru),
- Акбирова Ләйсән Рәүф кызы (http://lyaysan.ru),
- Богапова Зөһрә Фәриҗан кызы (http://tatardeti.blogspot.com),
- Әюпов Ильфар Ильдар улы (http://qushlawich.ru),
- Шәвәлиев Дилүс Мирзасалих улы (http://dilus-19.web-box.ru),
- Мөхәммәдиева Дилә Мирмөҗәһит кызы (http://yashel-bishek.ucoz.ru),
- Вафин Фәрит Вәдүт улы (http://vafin.mugallim.com),
- Мәтҗанова Раушания Гаяз кызы (http://raushania.ucoz.ru),
- Сәрвәрова Рәдинә Миннерәсил кызы (http://sarvarova-r.ru),
- Шәрипов Илназ Илшат улы (http://sharipov.jimdo.com) h.б.

Татнет каталогында татар мәгарифе темасын яктырткан сайтлар саны даими артып килә. Инде быел «Белем җәүһәрләре» дөньякүләм файдалы интернет-проектлар бәйгесендә катнашырга теләк белдереп, яңа сайт

авторларыннан гаризалар килде. Шундый сайтлар арасыннан Әхмәтҗанова Әлфия Фарух кызы (http://alfija.jimdo.com) һәм Мәҗитова Айгөл Локман кызының (http://mazitova-aygul.jimdo.com) сайтларын билгеләп үтми мөмкин түгел.

Интернет челтәре аша татар мәгарифен саклап калуда һәм үстерүдә Белем.ру (http://belem.ru) порталының өлеше зур булуына күңел аеруча шат. Җиде елга якын диярлек портал укытучыларны заманча технологияләр һәм мәгариф өлкәсендәге яңалыклар белән таныштырып килә, белем бирү ресурслары белән тәэмин итә, мәгариф өлкәсендәге белгечләр өчен үзара аралашу һәм тәҗрибә уртаклашу мәйданы булып тора.

Белем.ру порталы кысаларында оештырылган «Белем җәүһәрләре» интернет-проектлар бәйгесе (http://konkurs.belem.ru) инде биш ел дәвамында укытучыларны, укучыларны һәм татар интернетчыларын мәгариф һәм мәдәният өлкәсенә караган файдалы һәм сыйфатлы интернет-проектлар булдырырга этәрә, әлеге өлкәдә аеруча яхшы интернет-проектларны билгеләп килә.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт театры (http://kamalteatr.ru) һәм Татнетны үстерү фонды (http://tat-i.net) ярдәме белән оештырылган «Айның иң яхшы ресурсы» акциясе исә порталның аеруча сыйфатлы белем бирү ресурсларын ачыкларга, порталны сыйфатлырак ресурслар белән тулыландырырга һәм күпсанлы кулланучыларының игътибарын әлеге файдалы ресурсларга җәлеп итәргә ярдәм итә.

Яңа «туган» татар сайтлары «Татар иле» татар социаль челтәренең (http://tatarile.org) веб-каталогына урнаштырылып барыла. Бүгенге көндә әлеге каталогта 700 гә якын татар сайты турында мәгълүмат урын алган, бу сайтлар татар телендә белем биргән һәр укытучыга төп мәгълүмат чыганагы булып тора ала. «Татар иле» проекты нәкъ менә кулланучыларны татар дөньясына алып кереп китә торган төп проект буларак гамәлгә ашырылды да инде!

«Татар иле» интернет-проекты кысаларында бүгенге көндә 12 сәхифә эшләп килә, аларның һәрберсе дә татар мәгарифе үсеше өчен файдалы проектлар. Проектның төп өлеше – «Аралашу» бүлеге (http://tatarile.org/aralashu) – социаль челтәрдән гыйбарәт. Әлеге проект кысаларында кулланучылар, теркәлеп, үз сәхифәләрен һәм төркемнәрен булдыра, дуслар һәм танышлар таба, фикер алыша һәм мәгълүмат белән уртаклаша ала. Аралашу проекты кысаларында укытучылар төзегән «Мөгаллимнәр» төркеме актив эшләп килә, әлеге төркемдә 50 гә якын укытучы үзара тәҗрибә уртаклашалар. «Татар иле»ндә «Белем.ру»ның да рәсми төркеме бар; укытучылар өчен «Шәһри Казан» газетасының рәсми төркеме, «Бала тәрбияләү», «Гыйбрәтле хикәяләр», «Гыйбарәләр, акыллы сүзләр, уйлар уйнавы», «Иҗади һәм интеллектуаль бәйгеләр», «Китап уку», «Күңелле татар теле», «Методик берләшмә», «Татар теле сафлыгын саклау», «Татар шәхесләре» һ.б. төркемнәр файдалы һәм кызыклы булыр, дип уйлыйм.

«Татар иле» кысаларында Татар энциклопедиясе (http://tatarile.org/maglumat), Татар китапханәсе (http://tatarile.org/kitap),

Истәлекле даталар (http://tatarile.org/date), Видеогалерея (http://tatarile.org/video), Аудиогалерея (http://tatarile.org/audio), Фотогалерея (http://tatarile.org/photo) кебек мәгълүмати ресурслар бар. Татар энциклопедиясе сәхифәсе хәзерге вакытта үз эченә 2 том татар энциклопедиясен сыйдырган, китапханәдә онлайн режимда 400 гә якын китап укып була. Бу проектлар Татар энциклопедиясе институты һәм Татар милли китапханәсе белән берлектә башкарылды.

Проектның медиа бүлекләре исә, Министрлар Кабинетының Баш архив идарәсе, «Татаркино», Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Яңа гасыр» телевидениесе, татар театрлары һ.б. оешмалар ярдәме белән берлектә төзелеп, медиаресурслар белән баетылды. Монда татар спектакльләрен, мультфильмнарны, документаль һәм нәфис фильмнарны карарга, XX гасырның 50 нче елларынан башлап дөнья күргән татар җырларын тыңларга һәм җыр текстлары белән танышырга, татар рәссамнарының картиналарын карарга һ.б. мөмкин. Күп кенә укытучылар (Яшел Үзән, Кукмара, Саба, Сарман, Мөслим һ.б. районнардан) әлеге ресурсларны дәресләрдә инде файдаланып та киләләр.

Татар телен өйрәнергә теләгән кулланучыларга «Татар иле» проекты үзлектән онлайн режимда татар телен өйрәнергә мөмкинлек бирә (http://tatarile.org/tatartele). Мәскәү, Санкт-Петербург, Ярославль калалары, Саха Республикасы, Германия һ.б. чит ил һәм төбәкләрдән кулланучылар әлеге ресурстан аеруча еш файдалана, көн дә татар телен өйрәнүчеләр саны инде 100 гә якынлашты. Әлеге ресурсны мәктәптә рус балаларына татар телен өйрәткән вакытта да уңышлы кулланырга мөмкин.

Гомумән алганда, «Татар иле» көн дә яңа кулланучылар таба һәм ныгый бара, аны алып баручылар («Белем.ру» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Татнетны үстерү фонды һәм аның каршында эшләп килгән Татнет волонтёрлары) ресурсның мәгълүмат белән баетылуы һәм яхшыруы өстендә эшләп килә. Бүгенге көндә проект республикабызның дәүләт җитәкчелеге һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының турыдан-туры ярдәме белән эшли.

Сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү – четерекле мәсьәлә. Бүгенге көндә лаеклы ялда булган мөгаллимнәребездән Совет чорының торгынлык елларында класска бер яисә берничә китап белән дә күп санлы укучыларга белем һәм тәрбия бирүләре турында еш ишетергә туры килә. Алар фәннәрне туган телебездә укытканнар, шуңа да карамастан, һәркем укырга һәм язарга өйрәнгән, әлеге балалардан академиклар һәм галимнәр үсеп чыккан, алар алларына куйган максатларына ирешә алганнар. Бу галимнәрнең күбесе хәзер дә үз туган телләрендә матур итеп аралаша.

Чит илләрдә яшәп көн күргән ватандашларыбыз да татар телендә камил дәрәҗәдә диярлек аралаша һәм туган телләрен балаларына, оныкларына өйрәтеп килә. Бүгенге Интернет челтәре безгә хәзер алар белән өйдән чыкмый гына дуслашырга һәм туган телдә аралашырга мөмкинлек бирә. «Татар иле»ндә ерак илләрдә һәм төбәкләрдә яшәгән ватандашларыбызның туган телләрендә Татарстан татарлары белән дуслашып аралашканнарын күреп күңел сөенә.

«Татар иле» кысаларында безнең балалар да шулай туган телләрендә аралашып, татар теленең бөтен дөньяга таралган һәм киң кулланылышта булуын күреп үссәләр, бу бик яхшы булыр иде.

Бер яктан караганда, Интернет челтәре безнең күзебезне ача. Интернет челтәрендә татар телендә ресурслар да шактый күп, әлеге ресурсларны кулланып, хәтта япон, якут, немец, рус егетләре-кызлары да татар телен өйрәнәләр һәм безнең белән бер дә читенсенми татарча аралашалар. Япон егете Юто Хишияманың татар телендәге язмаларын «Татар иле» кулланучылары көн дә зарыгып көтеп алалар, аның язмаларына карата дистәләгән лайклар куялар. Шул ук вакытта, Татарстанның үзендә татар телендә аралашу күпләр өчен әле дә зур киртә булып тора. Ул гына да түгел, күп кенә балалар туган телләрен инде ата-аналары белән аралашырлык дәрәҗәдә дә белми. Ата-аналар балаларын рус мәктәпләренә бирә, татар гимназияләрендә рус сыйныфларын ачтырып йөри. Халыкның үзаңы шулкадәр бозылган ки, ике татар кешесе үзара рус телендә аралаша, татарча китапларны мәктәп курсы кысаларында гына укый, мәгълүмат алу өчен татар чыганакларыннан (татар газета-журналлары, радио һәм телевидение, Интернет h.б.) файдаланмый диярлек.

Шуңа күрә татар мәгарифен саклап калу һәм ныгыту өчен, дәүләт җитәкчелеге дәрәҗәсендә халыкның дөрес үзаңын формалаштырырга, тиешле мотивация һәм стимуллар булдырырга кирәк. Тулы дәрәҗәдә татар телендә эшли торган Электрон Хөкүмәт, Электрон Мәгариф системаларын булдыру, Хөкүмәт дәрәҗәсендә оештырылган барлык эшләрнең ике дәүләт телендә эшләп китүен тәэмин итү безнең Хөкүмәтебез көченнән килердәй эш. Элмә такталар, төрле стендлар, урам һәм тукталыш исемнәренең дәүләт телләрендә булулары зарури эш. 2007-2008 нче елларда татар телендә дә эшләп киткән Хөкүмәт порталы (http://prav.tatar.ru/tat) министрлыклар һәм ведомстволар, муниципалитетлар (районнар) дәрәҗәсендә эшләгән сайтларга да бүгенге көндә яхшы үрнәк булып тора, халыкны ике дәүләт телендә тиешле мәгълүмат белән тәэмин итеп килә.

Шуның белән беррәттән, Интернет челтәрендәге ресурсларга гына ышанып калу, балаларны татар телендә белем алу өчен Интернет челтәренә генә юнәлтү дә дөрес эш түгел. Укучы балаларның теләсә кайсы фәнне татар телендә – үз туган телендә – Татарстан Республикасының Конституциясе белән билгеләнгән дәүләт телендә өйрәнү өчен бар мөмкинлекләре – дәреслекләре, методик ярдәмлекләре, башка төр әсбаплары (шул исәптән – электрон рәвештә) булырга тиеш. Бу башлангыч һәм урта белем дәрәҗәсендә генә түгел, ә югары белем бирү дәрәҗәсендә дә хәл ителергә тиешле мәсьәлә. Фәнни дәрәҗәдә татар теле үсеш кичермәсә, гади сөйләм телендә татар телен саклап калу һәм үстерү күпкә кыен булачак. Шуңа күрә, нәкъ менә хәзер югары белемне татар телендә бирү, татар фәнен үстерү һәм ныгыту өстендә җитди адымнар ясау кирәк! Татар телендә фәнни хезмәтләр алып барган галимнәр бүген телнең һәм мәгарифнең киләчәген билгели. Гуманитар өлкәдә генә түгел, ә башка өлкәләрдә дә!

Әйе, һичшиксез, Интернет челтәре татар мәгарифен үстерүдә гаять зур ярдәмче булып тора. Әлеге ярдәмне күрергә, аңларга һәм дөрес итеп файдалана

белергә генә кирәк. Әлеге ресурсларны, әлеге мөмкинлекләрне халыкка ирештерергә һәм тәкъдим итәргә кирәк! Татар мәгарифе бүгенге көндә яхшы пиар көтә! Татар мәгълүмат чаралары бүген «сары матбугат» булудан беразга гына булса да туктап, үз укучыларына татар мәгарифен рекламаларга, татарча белем алуның дәрәҗәле булуын тәкъдим итәргә тиеш. Ә без, үз чиратыбызда, моның чынлап та шулай булуын тәэмин итик!

Тәрбия чарасы буларак спорт

А.А.Гафиятов, КФУ аспиранты, «Татарстан – яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең спорт тапшырулары җитәкчесе (фәнни җитәкче – филология фәннәре докторы, профессор В.З.Гарифуллин)

Бүген спорт тормышыбызга шулкадәр үтеп кергән ки, яшәешебезне аннан башка күзаллап та булмый. Кайчандыр спорт белән шөгыльләнү хобби, ягъни мавыгу дип кенә каралса, бүген ул профессионаллардан торган бербөтен система буларак бәяләнә. Спорт индустриясендә атлетлар гына түгел, аларның тренерлары, табиблар, югары уку йортлары белгечләре, стадион, спорт сарайлары хезмәткәрләре һәм хәтта җанатарлар да «әйләнә». Әйе, бездә хәзер яраткан командалары артынна башка шәһәрләргә, хәтта чит илләргә йөрүче профессиональ җанатарлар да бар. Татарстанны да бүген нәкъ менә атаклы спортчылары, «Ак барс», «Рубин», «УНИКС», «Зенит», «Динамо-Казан», «Синтез» кебек командалары аркылы беләләр. Чыннан да, бүген спорт тормышыбызда әһәмиятле урын алып тора. Үзеннән-үзе «ни өчен?» дигән сорау туа. Моның җавабы гади: бер-берсе белән узышу, көчле, батыр булу теләге биологик зат буларак кешенең генына ук салынган. Шуңа күрәме, Борынгы Грециядә беренче Олимпия уеннары узыдырыла башлаганчы ук, төрле илләрдә яшәүче халыкларның үз ярышлары (уктан ату, йөгерү, йодрык сугышы, таш күтәрү, көймәдә йөзү, атта чабу h.б.) барлыкка килгән.

Татар халкының ерак гасырлардан килә торган милли бәйрәме – Сабантуе да, нигездә, спорт ярышларыннан, төрле көч сынашулардан тора. Галимнәр фикеренчә, ул да Олимпия уеннарына кадәр барлыкка килгән. Шулай булгач, республикабыз спортының тарихы да берничә мең ел белән исәпләнә.

Кызганычка каршы, халкыбызның милли бәйрәмнәре, шул исәптән спорт тарихы да ныклап өйрәнелмәгән һәм язылмаган. Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли архивы фотосурәтләре фонды берничә мең кадрдан тора. Әмма алар, нигездә, XX гасыр уртасыннан бүгенге көнгә кадәр төшерелгән фотосурәтләр. Югыйсә башкалабыз Казанда беренче спорт түгәрәкләре XIX гасыр ахырында ук оеша. Мәсәлән, шахмат клубы 1884 елда ачыла. Ул СССРда Петербург, Харьков һәм Ташкенттан соң дүртенче клуб була. 1912 елда Казанга булачак дөнья чемпионы Александр Алехинның килүе билгеле. «Камско-Волжская речь» газетасында әлеге вакыйга уңаеннан зур-зур язмалар дөнья

күргән, анда атклы шахматчының көндәшләре, ничек уйнавы, җиңү һәм җиңелүләре хакында бик тәфсилләп язылган.

Спорт тарихы ил тарихыннан, республика тарихыннан аерылгысыз. Безнең илдә: «Спорт чын-чынлап Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына чәчәк атты», - дип әйтергә яраталар. Әмма бу алай түгел. Мәсәлән, Казан чаңгычылар клубы, «Яхт-клуб», «Сокол», «Беркут» спорт җәмгыятьләре 1908-1912 елларда барлыкка килә. Казанда тимераякта узышу буенча беренче чемпионат 1912 елда уздырыла, стартка сигез спортчы чыга. Чаңгычылар арасында Казан университеты студентлары шул чакта ук дан тота. 1915 елда Сечень һәм Геркан фамилияле ике студент Казаннан Сембер шәһәренә чаңгы походы оештыра. Соңрак әлеге поход массакүләм төс ала.

Революциягә кадәр Россиядә спортның үсеп китә алмавы физик культура кадрларының аз булуына, укытучы һәм инструкторларның нигездә чит илләрдә укып кайткан белгечләрдән торуына бәйле. Мәсәлән, зур территорияне биләп торган Казан губернасында бу елларда махсус дипломга ия нибары егерме биш физкультура укытучысы испәләнә, аларның да егерме бере Праганың атаклы Сокольский җәмгыятендә укыган була. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң берничә ай үтүгә, 1918 елның апрелендә, кырык яшькә кадәрге эшчеләрне һәм уналты яшьтән башлап үсмерләрне мәҗбүри рәвештә хәрби сәнгатькә өйрәтү хакында декрет дөнья күрә. Хәрби өйрәнүләрнең нигезе итеп физик күнекмәләр алына. Бигрәк тә халык арасында киң таралган чаңгы спорты буенча өйрәнүләр массакүләм төс ала. Всеобуч (гомуми белем бирү) оешмасы тарафыннан «Наставление по обучению лыжных частей» һәм «Положение об отдельных лыжных ротах-командах» дигән китап-брошюралар чыгарыла, яшьләрне чаңгыда шуарга өйрәтү өчен иң көчле чаңгычы-инструкторлар чакырыла. Боларның барысы да хакимиятнең бу эшкә зур әһәмият бирүе хакында сөйли. Бу вакытта илдә Гражданнар сугышы баруын да онытмыйк. 1919 елның ахырында Казанда Үзәк хәрби-спорт клубы оеша. Ул бөтен Идел буе төбәгендә беренче була һәм физкультура-спорт үсешендә зур роль уйный. 1920 елның кышында Казанда ике зур чаңгы базасы ачыла (берсе Кабан күле буенда, икенчесе «Рус Швейцариясе» дип аталган Үзәк паркта була). Өстәвенә, һәр өяз шәһәренә чаңгы буенча инструкторлар чакырыла, укучылар чаңгы белән тәэмин ителә, әлеге спорт төре мәктәп программасына кертелә. Алгарак китеп булса да, тагын шунысын да әйтик: чаңгы буенча Татарстан беренчелеге тәүге тапкыр 1921 елның 12 мартында Казанның Үзәк ял һәм мәдәният паркында үткәрелә. Ярышларны оештыручылар тарафыннан бары бер генә дистанция – егерме биш чакрымга узышу тәкъдим ителә, катнашучыларның саны өч дистәгә дә тулмый, әмма, безнеңчә, республикабызның чаңгы спорты тарихы әнә шул датадан башлап исәпләнергә тиеш.

Республикабызның спорт тарихы исә 1920 елның 25 июненнән башлана, чөнки шул көнне Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү хакындагы декретка кул куела.

1921 елның гыйнварында Казанда Всетатспорт оешмасына нигез салына (аны хәзерге Спорт министрлыгының башлангычы дип атарга мөмкин). Әлеге оешма республикадагы барлык спорт секцияләрен, түгәрәкләрен берләштерә, ярышлар оештыра, спорт инструкторлары әзерли, мәктәпләр, пионер һәм комсомол оешмалары, завод-фабрикалар белән тыгыз элемтәдә тора.

1928 елда илдә беренче җәйге Бөтенсоюз спартакиадасы үткәрелә. Анда катнашу өчен, республикабыз атлетлары иң элек үзебездә сайлап алу ярышларын үтәргә тиеш була. Кадрларны сайлау эшен 1926 елда Татарстанда оешкан «Динамо» җәмгыяте тормышка ашыра. Әлеге җәмгыять республика спорты үсешенә бик зур өлеш кертә: «Динамо»да тәрбияләнгән спортчылар авыр атлетика, фехтование, самбо, дзюдо, ирекле һәм грек-рим көрәше, волейбол, чаңгы спорты, җиңел атлетика буенча СССР, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында һәм Универсиадаларда катнаша, дистәләрчә медальләр яулый. Бөтен ил буенча ГТО, «Ворошиловча атучы» значокларына норматив кертелә, физкультура институтлары һәм техникумнары ачыла, алар чыныккан, таза-сау яшьләр тәрбияләүне максат итеп куя.

1931 елда Казанда беренче физкультура техникумы, 1949 елның мартында Казан дәүләт педагогика институтында физик тәрбия факультеты ачыла. Соңрак Әлмәттә физкультура техникумы, Чаллыда физкультура институты оеша, һәм республика спортына кадрлар әзерләү эше массакүләм төс ала.

Әле берничә ел элек кенә Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясенең барлыкка килүе, 2013 елда Казаныбызда Универсиада үтү, ел саен диярлек бездә аерым төрләрдән Европа, дөнья чемпионатлары уздыру Казанны Россиянең спорт башкаласына әйләндерде.

Республика спорты тарихын язучылар арасында без Дамир Шәрәфетдинов, Илдус Илдарханов, Мәгъсүм Гәрәев, Борис Марихин, Владимир Болдаевский, Атлас Гафиятов, Александр Медведев кебек күренекле журналистларны күрсәтә алабыз.

Кечкенә генә күзәтүдә республикабызның спорт тарихын тулысынча чагылдыру мөмкин түгел. Чөнки спорт үзе бик күп төрләрдән тора, һәркайсының тарихы бар. Бүген Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы үткәрә торган ярышлар календарена йөзгә якын спорт төре кертелгән.

Әдәбият

1. От Афин - до Рима. М. Советская Россия, 1960.

2. Олипийское созвездие. Справочник. М. Физкультура и спорт, 1974.

3. Җир шары алкышлый (төз. Д.Шәрәфетдинов). Казан, Тат.кит.нәшр., 1976.

4. Звезды спорта (справочник). М. Физкультура и спорт, 1979.

5. Правофланговые спорта Татарстана, Казань, Тат.кн.из-во, 1997.

6. Гафиятов А. Сабантуй мәйданыннан – Олимпия уеннарына, Тат.кит.нәшр., 2011.

Татар телендәге блоглар: ачышлар һәм перспективалар

Л.Р.Закиров, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Л.Зәйни)

Башлыча блогларны уртак кызыксынулы кешеләрне берләштерү максаты белән ясаганнар. Кагыйдә буларак, андагы мәгъүмат шәхси яки мәгълүмати характерда, шуңа да андый сайтлар гадәти көндәлекнең электрон версиясен хәтерләткән. Тора-бара челтәрдәге көндәлекләрнең функциясе киңәйгәннән-киңәя барган.

Блогның берничә билгеләмәсе бар. Инглизчәдән «blog» сүзе «вакыйгаларның виртуаль көндәлеге» дип тәрҗемә ителә. Ә тулы билгеләмәсе: блог – махсус программа ярдәмендә шәхси биттә язулар, сурәтләр һәм мәгълүматның башка төрен тиз арада урнаштыру.

Блог алып баручы кешене блогер дип, ә челтәрдәге барлык блоглар кушылмасын блогосфера дип атыйлар. Рус блогсферасында бүгенгә 1 миллион 150 мең блог исәпләнә, әмма шуларның нибары 46 проценты даими яңартыла. Моннан тыш, сәгать саен рус сегментында йөзләгән яңа блог пәйда була. «Яндекс» статискасы буенча, рус телле блоглар нигездә 14 блог-сервиста алып барыла, алар арасыннан «зур дүртлек»не аерып чыгаралар (50 меңнән алып 350 меңгә кадәр көндәлек) Livejournal.com (rafis-kashapov.livejournal.com, 1000kvmm.livejournal.com/), Liveinternet.ru, Diary.ru (acma.diary.ru/), (nuria88.diary.ru/), (rafiskashapov.diary.ru/) һәм чагыштырмача яңа җирлек – Blogs.mail.ru.

Кагыйдә буларак, блоглар мондый сыйфатларга хас:

- Блог ул – Интернеттагы сайт (бит яки «бит»ләр җыелмасы).
- Блогтагы язулар хронологик тәртиптә урнаштырыла.
- Блог гадәттә бер кеше тарафыннан һәм беренче заттан алып барыла.
- Блогта еш кына авторны кызыксындырган сайтларга сылтамалар урнаштырыла.
- Блог даими яңартыла: көн саен яки атнасына берничә тапкыр.
- Кайбер блогларда язуларга комментарий калдырырга була.
- Блогтагы язулар буенча авторның шәхесен күзаллау мөмкинлеге туа.
- Блогны, гадәттә, профессиональ журналист яки язучы түгел, ә һәвәскәрләр алып бара.

Авторлар санына карап, блогларны шәхси, төркемле (корпоратив, клуб…) һәм җәмгыяви төргә (ачык) аералар. Эчтәлеге буенча – тематик яки гомуми.

Блогларның төре

Авторлар саны буенча

– Шәхси блог – бер кеше алып бара (кагыйдә буенча, блог җитәкчесе).

– Тәхәллүсле – уйлап чыгарылган кеше яки псевдоним тарафыннан алып барыла.

– Блог-подделка – танылган шәхес исеменнән алып барыла.

– Төркемле яки социаль блог – блог җитәкчесе яки модераторы тәгаенләгән кагыйдә буенча билгеле бер төркем тарафыннан алып барыла.

– Корпоратив блог – бер оешманың хезмәткәрләре алып бара.

Тематика буенча

Гадәттә, шәхси блоглар шәхси характерда була. Әмма шәхси, төркем, корпоратив блоглар белән беррәттән, тормыш даирәләренә багышланган махсус блоглар да бар: сәяси, көнкүреш мәсьәләләре, сәяхәт, мәгариф, мода, музыка h.б.

Мультимедиа ягыннан

Фотоблог – фотолар җыелмасы, артблог – блог авторының рәсемнәре тупламасы, музыкаль блог – музыкаль композицияләр җыелмасы, видеоблог h.б.

Блогларның функциясе

2005 елда блоглар тупланган иң эре мәйдан – «Живой журнал» блогерлары арасында үткәрелгән сораштыру барышында блогларның түбәндәге функцияләре ачыкланган.

Коммуникатив функция

Бу функция аеруча еш телгә алына. Күп кенә авторлар блогны үзләренә кызык кешеләр белән аралашу өчен алып бара яки укый. Беренче чиратта, бер әйтелгән сүзне күп кешегә ирештерү мөмкинлеге туа. Мисал өчен, паркка чыгып керүең турында унлап танышыңа сөйләүдән ни мәгънә, моның урынына блогка язма урнаштырасың, сәяхәттән фотолар эләсең. Һәркем аны үзенә уңайлы вакытта укыр яки, кызыксыз дип табып, бөтенләй укымас. Ләкин бу ситуация проблема да китереп чыгарырга мөмкин. Әйтик, реаль тормышта күрешсәләр, ике блогер, фантазияләре чамалы булса, сөйләшер сүз таба алмаячак. Укучылар да, язучылар да блог кулланудагы коммуникатив мотивациянең ике юнәлешен аерып чыгара – танышлар белән аралашу һәм яңа танышулар булдыру.

Үз-үзеңне таныту функциясе

Кайбер авторлар блогларын үз иҗатларын башкалар белән уртаклашу һәм фикер алышу өчен алып бара (проза, шигърият, фотоларга бәйле блоглар).

Күңел ачу функциясе

Күп кенә кешеләр блогларны вакытларын күңелле үткәрү өчен алып бара, укый һәм комментарий калдыра. Андый кешеләрнең, гадәттә, буш вакыты күп була. Мисал өчен, яшь әниләр блогерларның саллы өлешен тәшкил итә – аларга блогларына язарга азык җитәрлек.

Кайберәүләр вакыт кытлыгы аркасында, кешеләр белән җитмәгән аралашуны блогтагы аралашу белән кайтара. Блогерларның механизмы шуңа көйләнгән дә: һәркем үзенә уңайлы вакытта, ешлыкта һәм күләмдә аралаша.

Мемуарлар функциясе

Кәгазь көндәлек кебек, блог та мемуарлар функциясен башкара. Тормышның иң истә калырлык мизгелләрен теркәгән язуларның киләчәктә кирәк булуы ихтимал. Автор үз-үзе белән коммуникацияләү чарасы булдыра.

Рефлексия яки үз-үзеңне камилләштерү функциясе

Бу функция блогерларга үзләре дә шундый булырга омтылган үзгә «Мин» образына ирешү мөмкинлеге бирә. Кайберләре ассызыклаганча, башка кешеләр уку сәбәпле, алар көндәлекне алып баруны дәвам иттерергә һәм фикерләрен дә нигезлерәк итеп формалаштырырга, шул рәвешле тирә-як үзгәрешләрне яхшырак аңларга мәҗбүр.

Психотерапевтик функция

Кайберәүләр блогны башлыча «эмоцияләрне тышка чыгару», «нервыларны тынычландыру» максатын күздә тотып алып бара. Традицион көндәлекнең бу функциясе күп кенә авторлар тарафыннан берничә тапкыр билгеләп үтелә. Блог алып баручы бөтен дөньяга үз тормышыннан зарлана да башкалар аны тынычландыра, киңәшләрен бирә башлый. livejournal «ru_psychology» һәм шушыңа охшаш башка төркемнәрдәге даими диалогларның эчтәлеген анализласак, аралашуда транзакциянең шушы төренең аеруча еш очравын күзәтергә була.

Югарыда язылган иң эре дүрт блоглар тупламасында татарча блогларны эзләргә керештек. Livejournal.com сайтында тулы канлы ике блогка гына тап булдык (rafis-kashapov.livejournal.com һәм 1000kvmm.livejournal.com), Liveinternet.ru сайтында татарча блоглар юк, Diary.ru сайтында өчәү – acma.diary.ru, nuria88.diary.ru, rafiskashapov.diary.ru, Blogs.mail.ru сайтының өске өлешендә болай дип язылган: «2013 елның 23 декабреннән яңа постлар урнаштыру һәм комментарийлар язу туктатыла. 2014 елның 3 мартыннан Blogs.mail.ru проектының барлык битләре дә ябылачак».

Татар телендәге блоглар башка төрле рәвештә дә очрый – сайт халәтендә. «Мөгаллим язмалары. Фәрит Вафинның шәхси сайты: педагогика, публицистика, иҗат» (vafin.mugallim.com/). Шуның өстенә, Фәрит Вафинның аерым блогы да бар (mugallim.blogspot.ru/), ул анда видеоязмалар элеп бара. Рөстәм Зарипов блогы (rustemzaripov.blogspot.ru/), Булат Хаков сайты (bulathakof.ucoz.ru/), Марат Кәбиров сайтында блог калыбын хәтерләткән «Куен дәфтәре» сәхифәсе бар (maratkabirov.com/the-newsblog.html). Шуңа да карамастан, мөстәкыйль татарча блоглар да ара-тирә очрый. «Алма бөртеге язмалары» (xn----7sbafklb6bj7bw61r.xn--90aexm0e.xn--p1ai), Сөмбел Гаффарова блогы (http://sombel.ru/).

«Татар заманы» электрон басмасында да (tatartime.com) 15ләп тематик блог бар: сәясәтче блогер, мәгърифәтче блогер, тарихчы блогер, калган авторлар блогер дип кенә тамгаланган.

Татарча блогларның күбесе гомуми блогның таләпләренә туры килә: язмалар хронологик тәртиптә урнаштырыла, бер кеше тарафыннан һәм беренче заттан алып барыла, блог авторлары үзләрен кызыксындырган сайтларга сылтамалар да урнаштыра. Әйтик, Сөмбел Гаффарова блогында уң якта сылтамалар дигән аерым сәхифә бар (7 сайтка сылтама куелган). Марат Кәбиров блогында да «Файдалы сылтанмалар» дигән аерым сәхифә бар, анда иҗатка кагылышлы сайт адреслары тупланган. Татарча блогларның барысында да шәрехләүләр калдыру мөмкинлеге бар. Әйтик, Сөмбел Гаффарова блогында 6 гыйнвар көнне 17:58 дә Гөлүсә мондый шәрехләү язган: «Сөмбел, үз исемегез белән чыкмаса да, «Сөембикә»дә басылган бала тәрбияләү буенча язмаларыгызны бирегә урнаштыра алмассыз микән? Журналларны актарганчы, бар да кул астында булыр иде дим…» (Авторның язу рәвеше сакланган). Автор Гөлүсәгә ике сәгатьтән соң җавап язган: «Гөлүсә! Ок! урнаштырырмын 😀» Өстәвенә, блогта языл ган һәр комментарий турында уң яктагы «Яңа фикерләр» баннерында хәбәр чыга. «Алма бөртеге язмалары» блогында да шәрехләүләр бар: һәр постта 3-4 комментарий. 2012 елның 19 гыйнвар язмасында Алма бөртеге Яңа елны ничек каршылавы турында яза. 4 кеше комментарий калдырган. Шуларның берсе (20.01.2012, isemsez: «Кит аннан шуны карыйсыңмы?! бер караган булдым охшамады, Шерлогы да әллә нинди, хатынша гына бер ир ат. Матур язасың. Мәкаләләреңне укып һичтә чатта балаланып утыруыңны күз алдына китереп булмый)))» (Авторның язу рәвеше сакланган). «Татар заманы» блогларында комментарийлар гаҗәеп күп. Әйтик, Илдус Әмирхановның «Татарстанга һәм милләткә каршы сугышны туктатыйк» язмасына 19 комментарий язылган. Тагын шуны да искәртү мөһим: блогларның күбесе социаль челтәрләргә тоташкан.

Блогны, нигездә, һәвәскәрләр алып бара дигән сүз татар телендәге блогларда акланмый. Сөмбел Гаффарова – профессиональ журналист, Марат Кәбиров – язучы, Булат Хаков белән Мөнир Вафин – республика матбугатларының даими хәбәрчеләре. Кызганыч, татарча блогларда төп шарт үтәлми: контент, ягъни эчтәлек даими яңартылмый. Әйтик, Сөмбел Гаффарова соңгы язмасын («Яшел сыер») 13 февральдә, Мөнир Вафин үз сайтында соңгы язмасын 18 февральдә, ә блогында видеоны соңгы тапкыр 2013 елның 14 августында урнаштырган. «Татар заманы» блогерлары язмаларында көн кадагындагы проблемалар урын алган. Әмма, ни кызганыч, соңгы постлар 2013 елда урнаштырылган. Ни сәбәпледер, алар хәзер яңартылмый. Марат Кәбиров, блогында сирәк язса да, соңгысы 13 гыйнварда эленгән. Алма бөртегенең соңгы язмасы «Хурлык!» дип атала. «Гарьлек, хурлык! Оятсызлык! Мин хәзер просто котырып утырам! Рамил хәзрәт Юнысны Колшәрифтән алганнар: islamnews.ru/news-121841.html. Язмага ышансак, Рамил хәзрәтне Болгарда куелачак хәшәрәт һәкәлгә каршы чыкканы өчен эшеннән алганнар. Оятсызлык, билләһи!» – дип тузынган блогер. Рамил хәзрәткә теләктәшлек белдерептер, Алма бөртеге дә эшчәнлеген туктатып, юкка чыкты. Бу – аның соңгы язмасы – 2012 елның 3 апреле.

Татарча блогларны төркемләсәк, авторлар санын караганда, блоглар тупланган сайтлардан кала, барысы да шәхси. Контент ягыннан, Фәрит Вафинның блогы башкаларныкыннан аерыла, анда видеолар тупланган, димәк, аның битен видеоблог дип атыйбыз.

Блогның төп функцияләре бергәлектә генә кулланыла. Әйтик, коммуникатив белән үз-үзеңне таныту функциясе татарча гына түгел, гомумән, башка блогларда да янәшә йөри. Әйтик, кеше сәбәпсез генә бөтен дөнья белән уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен уртаклаша алмый. Һәрхәлдә, ниндидер этәргеч булырга тиеш. Әгәр кеше блог алып бара, димәк, аны башкалар да укысын дип тели.

Татарча блоглар арасында күңел ачу функциясе «Алма бөртеге» язмаларында күзәтелә. Беренчедән, блогның исеме шаян рухта. Икенчедән, язмалар көн кадагындагы түгел, ә көнкүреш темага. Уң яктагы сәхифәләр исемелегендә «кәмит» бар. Язмаларның исемнәре дә юмор-сатирага тартым. Әйтик, «Свежий карчык», «Кем мескен дә, кем өстен?».

Мемуарлар функциясе өлешчә Марат Кәбировның «Күңел дәфтәре»ндә чагыла. «Шәхси статистика» постыннан өзек (03.07.2012): «Шул дәвер эчендә бер роман тәмамланган, өч роман башланган: берсе – башланган да ташланган, икесе тәмамлану алдында. Әдәбият һәм дәвер темасына эсселар – бер китапка җитәрлек. Биш хикәя, унбишләп көлкеле монолог, шигырьләр (шуларның кырыклабы җырга әйләнгән, башкарыла), бер пьеса, эстрада»йолдызларының» концертлары өчен унлап сценарий язылган. Алты йөзгә якын концерт алып барганмын, йөзләп очрашуда катнашканмын. Болары – тел очында торганнары гына, чынлабрак санасаң, тагын берничә әйбер табарга мөмкиндер. Унга якын журналистка интервью биргәнмен, унлабын кире борганмын».

Рафис Кашапов ике ресурста да блог алып бара, әмма «Живой журнал»дагысына игътибарны күбрәк бирә. Ике телдә дә яза, әмма рус телендәге постлары күбрәк. Гомумән, язмалары милли темага һәм илдәге-дөньядагы сәяси вәзгыятькә карый. Соңгысы – 23 февральдә – «Поздравляем народ Украины с победой на Евромайдане» дип атала. Язманың нәрсә турында барганы исеменнән үк аңлашыла. Рафис Кашапов һәр язмасын фотолар белән баета. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе дә «Живой журнал»да актив эшчәнлек алып бара. Мәдрәсәнең һәм республиканың дини тормышы киң планда яктыртыла, һәр постта фото бар (http://1000kvmm.livejournal.com/490.html). Әмма ни Рафис Кашапов, ни мәдрәсә постларында комментарийлар очрамады.

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен Фәрит Вафин сайты зур табыш һәм ярдәмлек. Сайтында файдалы сылтамалар да, сценарийлар да, башка укытучыларның да сайт адреслары күрсәтелгән, хәтта балаларга IslamFlash порталы баннеры да эленеп тора.

Татар телендәге блоглар төрле рәвештә һәм төрле кыяфәттә эшләп килә. Аларның беренчел функциясе – татар теленнең кулланылыш даирәсен киңәйтеп, милли телне яңа яссылыкта кулланып булуны раслау. Әмма бер төрле темаларга, әйтик, милләт, азатлык, педагогикага артык бирелеп, укучының

канәгать булып бетмәве мөмкин. Шуңа да татар телендәге блоглар тематика ягыннан төрләндерү чигенә җитте.

Әдәбият

1. Смирнов Д.В. Что такое блог? / URL: http://spectator.ru/internet/content/blog_is (Дата обращения: 10.01.2014).

2. Блог // Открытая энциклопедия «Википедия» / URL: http://ru.wikipedia.org/wiki/%C1%EB%EE%E3 (Дата обращения: 15.01.2014).

Яңа технологияләр һәм татар матбугаты

А.Ш.Зиннурова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
Л.Р.Сабирова)

Телевизор барлыкка килгәч, радио бетә диделәр. Әле дә яши. Мобиль телефоннар кулланыла башлагач, өйдәге «шалтыравык» юкка чыгачак дисәләр дә, өй телефоныннан башка яшәмибез. Инде интернет басып алгач, басма матбугатка санаулы көннәр калды дигән сүз чыкты. Күңелгә коткы салып, Франциядәге газета-журналлардан берничә мең кешене эштән кудылар. Бөтен дөнья буйлап шау-шу купты, бер-бер артлы газета-журналлар ябыла башлады. Көнбатышка йөз тоткан ил буларак, бу әкәмәт безгә дә килеп җитмәсме? Татарстандагы басма матбугатның хәле дә шулай мөшкелме?

Яңа технологияләр барлыкка килгән саен, матбугат та үзгәрә, яңа төсмер ала. Дөрес, аудитория дә заман белән беррәттән атлый, шуңа да таләпләре үсә генә бара. Буыннар алмашы белән, журналистика да үзгәрә. Бүген журналистиканы үстерү, пропагандалау өчен заманча технологияләр, глобаль челтәрләр бар. Беренчедән, басма матбугат булса, икенчедән, электрон матбугат формалаша. Минем уйлавымча, һәр икесенең дә үз урыны бар. Басма матбугат һәрвакыт булган һәм булачак, ә электрон форма безгә алга үсәргә җирлек тудыра. Дөнья барыбер үзгәрә. Яшь буын электрон мәгълүмат чараларын бик актив куллана, һәм без аларга булышырга тиешбез.

Тикшеренү объекты – замана казанышы – интернет һәм татар матбугаты; тикшеренү предметы – интернетның ни рәвешле басма татар матбугатына тәэсир итүе.

Хәзер дөньяга компьютер, интернет заманы килде. Анда нинди генә сайтлар, нинди генә блоглар, сәхифәләр юк икән?! Шунысы куандыра: интернет челтәрен яулаучылар арасында безнең татарларыбыз да байтак хәзер. Дөрес, яңа технологияләр яхшы яктан гына тәэсир итми. Әйе, бу яктан тәнкыйтьләүләр булды булуын, әмма прогресс үзенекен көйли.

Интернетта хәзер буш татар доменнары күп. Соңгы арада интернет челтәрендә Татарстан өчен махсус домен төзү турында да сүз бара. Күпләрнең күңеленә хуш килгән tt домены инде кулланыла икән. Информацион

технологияләр өлкәсендә эшләүче яшьләр, бу хакта уйланып, вәзгыятьне үзгәртү өлкәсендә тырышлык куйсыннар иде.

Әйтик, «Матбугат.ру» сайтын мин бик уңышлы дип саныйм. «Матбугат.ру» порталы татар интернет җәмәгатьчелегенең фикерен өйрәнү өчен файдалы. Мәсәлән, язманы укучылар санына карап, без теге яки бу милли-социаль төркемнәр өчен нинди темалар, авторлар кызыклы, нинди язу формалары отышлырак икәнен ачыклап барабыз. Бу, билгеле, редакция сәясәтенә, газета эчтәлегенә дә йогынты ясамый калмый. Мәсәлән «Ватаным Татарстан» газетасының әлеге порталда үз сайты бар. Газетада чыккан мәкаләләргә карата чыккан кайтавазлар атна саен «Интернет-кайтаваз» рубрикасы астында газета битләрендә дә басылып чыга. Бу рубрика үзе үк «Ватаным Татарстан»да иң популярлардан санала һәм фикер алышуларга, бәхәсләргә нигез булып тора. «Басма матбугаттан ераклашкан яшьләр аудиториясен matbugat.ru сайтында «эләктереп» була», - дип язган иде ул чакта «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире урынбасары булган Илдар Миргалимов [1]. «Матбугат.ру» сайтын халык күп укыймы? Әлеге сорауга җавапны шул сайттан эзләргә булдым. Ай саен ким дигәндә 30 мең компьютердан 300 мең тапкыр ачып карыйлар. 3 меннән артык комментарий языла.

«Ватаным Татарстан» редакциясе, «Матбугат.ру» проектының уңышка дучар булачагын алдан күреп, аның белән иң беренче булып хезмәттәшлек итәргә алынган.

«Матбугат.ру» порталы татар интернет җәмәгатьчелегенең фикерләвен өйрәнү өчен файдалы. Мәсәлән, язманы укучылар санына карап, теге яки бу милли-социаль төркемнәр өчен нинди темалар, авторлар кызыклы, нинди язу формалары отышлырак икәнен ачыкларга мөмкин. Бу, билгеле, редакция сәясәтенә, газета эчтәлегенә дә йогынты ясамый калмый. Мәкаләләргә карата чыккан кайтавазлар «газета – укучы» икеяклы элемтә чарасы буларак бик мөһим.

Интернет челтәрләрдә кешеләр төрле псевдонимнар астында комментарийләр калдыралар. Монда бер-берсен мыскыллау да юк түгел. Татарларга да бу хас икән. «Матбугат.ру»да да шундый очраклар булгалый. Бу инде милләтебезнең мәдәниятен түбәнсетү, аска тәгәрәү. Фәнис Мөхәммәтов «Чүп оясы ясамыйк» дип яза: «Матбугат. ру»да кайберәүләрнең ямьсез телдә язышулары да бернинди кысаларга сыймый. Мондый текстлар гадәттә: «Чәй куеп тор, килеп җитүгә сине кочагыма алырмын», «Әйдә урманга киттек, фәлән-төгән итәрбез» кебек тозсыз сүзләр белән башлана. Аннан соң ниләр язылганын үзегез дә чамалыйсыздыр...

Дөрес, сайтны оештыручылар мондый эчтәлекле язмаларны күреп алуга, яшен тизлеге белән юкка чыгаралар. Әмма алар күреп алганчы да күпме вакыт узган, күпме кешенең күңеле рәнҗетелгән була. Сайтка төрле яшьтәгеләр, шул исәптән балалар да керүен онытмаска иде» [2].

Бүгенге тормышны заманча технологияләрдән башка күз алдына китереп булмый. Интернет, газета-журналлар яшәешебездә төпле урын алып тора.

Ләкин күпчелегебез әлеге мәгълүмат чаралары ярдәмендә яшьләрдә милли үзаң тәрбияләү мөмкинлеген күз алдына да китерми. Ә бит ватанпәрвәрлек, милләт өчен горурлык хисләрен уяту бүген бик авыр. Тарих битләрендә татарның үзенчәлеге, бай мәдәни мирасы киләчәктә дә алтын хәрефләр белән язылсын өчен, без бу өлкәдә бүген үк тырышлык күрсәтергә тиеш.

Татар яшьләре туган телдә басыла торган газета-журналлар укырга тиеш. Моның өчен исә туган телебез рус теле шикелле үк гомуми кулланылышта булсын иде. Телебезгә ихтыяҗ тудырырга, яшьләрне кызыксындырырга кирәк. Мисал өчен, дөнья пәрәвезендә татар теле тоткан мәйданны киңәйтеп җибәрсәң, начар булмас иде.

Шуны да онытмаска кирәк: яшьләр өчен кызыклы мәгълүмат дөньяның теләсә нинди телендә булырга мөмкин. Тәрҗемә белән шөгыльләнү исә аларның барысын да колачларга ярдәм итәчәк. Мәсәлән, интернет челтәрендә махсус портал оештырып, анда чит ил язучыларының татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрен урнаштырырга мөмкин. Бу эшкә теләк белдергән һәркемне җәлеп иткән очракта, яшьләр үзләренә ихтыяҗ барлыгын, тарихта эз калдырырга мөмкин булуын тоемлаячаклар. Үзләрен «волонтёр » дип санаучы яшьләр татарлар арасында да бар бит.

Дөнья пәрәвезе кулланучылары арасында бүген электрон энциклопедия – википедия зур популярлык казанды. Милләттәшләребезнең тырышлыгына күрә әлеге кулланмада татар бүлеге дә эшләп килә. Ләкин башка телләр белән чагыштырганда, андагы мәкаләләр саны искиткеч аз. Татар яшьләре өчен исә бу өлкә эшкәртелмәгән кыр шикелле, мөмкинлекләребез чикләнмәгән. Әлеге мәкаләләрне интернетка һәркем урнаштыра ала, бары тик кулланылган чыганакларны гына күрсәтергә кирәк. Ә бу исә википедия төзүдә катнашучылар башкаларга мәгълүмат бирүдән тыш үзләренең дә милләт, тел, ил турындагы белемнәрен баетачак, дигән сүз. Кыскасы, бер атуда ике куянны тоту белән бер. Дөрес, бар нәрсәне татарчалаштырып, үз куышыңда ябылып яту да ярамас: телебез, милләтебез турындагы мәгълүматны чит телләргә тәрҗемә итү зарур. Инглизләр йә булмаса французлар да безнең хакта белергә, дөресрәге, без үзебезне аларга танытырга тиеш.

Интернет тормышыбызның аерылгысыз бер өлешенә әверелсә дә, телевидениенең тәэсирен инкарь итеп булмый. Нәкъ шуның өчен көне-төне татарча гына «сөйләүче», татарлар яшәүче бар илдә дә спутник ярдәмендә эшләүче телевидение булдыру проблемасы бүген аеруча нык тора. Киләчәктә татар теле проблемасын, татарлар тормышын яктыртучы, һәм иртә-кичен үз телебез дә генә бара торган канал булдыру зарур. Бу очракта инде рейтинг-фәлән дигән сылтау белән татар тапшыруларын эфирдан кысрыклау күренеше күзәтелмәс иде. Киләчәктә исә әлеге канал нигезендә яшьләр, ә бәлки балалар өчен аерым татар телевидениесе ачу мөмкинлеге дә туар иде. Урыс телендәге каналлар арасында спортка, хайваннар дөньясына, мәдәнияткә генә багышланган каналлар бихисап, безгә дә алардан калышырга ярамый.

Тагын бер алга китеш – онлайн газеталар оператив рәвештә чыга. Аларда мәгълүмат даими яңартыла, кереп караучылар саны югары, күп кенә онлайн газеталар профессиональ дизайнга ия.

Бүгенге көндә яңа информацион технологияләрнең синтезы күзәтелә.

Онлайн газеталарга күзәтү ясап үтик.

«Intertat.ru» турында әйтеп китәргә кирәк. Аның тышкы кыяфәте генә түгел, эчке төзелеше – язмаларны бирү рәвеше, укучылар белән аралашу мөмкинлекләре дә үзгәрде.

Газета яңа форматта Татарстан яңалыклары белән генә түгел, Россиядә, дөньяда күзәтелгән мөһим вакыйгалар белән дә таныштырып бара. Барыбызга да таныш икътисад, сәясәт, дин, җәмгыять, милләт, мәдәния т, спорт темалары хәзер тагын берничә рубрикага бүленеп, өлкәгә кагылышлы язмаларны табу уңайлырак ителде. Сез газета тормышына, редакция проектларына һәм коллектив эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүматны да таба аласыз. Бу хакта Баш биткә кереп укып була.

Безне тагын бер кызыклы яңалык көтә. Бу татар басмаларында әле гамәлгә кертелмәгән әйбер – хәзер укучыларыбыз газетаны үзләренә уңайлы итеп көйли ала. Димәк, һәрбер укучы, фантазиясенә һәм теләгенә карап, яратып укый торган рубрикаларны урыннары белән алыштыра, аларны төп биткә чыгара, кирәк санамаганнарын яшерә, рубрикадагы мәкаләләр санын үзе теләгән күләмдә калдыра ала. Көйләүләрне рубрика исеме язылган юлда урнаштырылган тамгалар ярдәмендә башкарып була.

Тагын бер бик мөһим яңалык – укучылар, махсус теркәлү узып, яңартылган, кызыклы үзгәрешләр кертелгән газета тормышында катнаша – фикер алыша, сораштыруда тавыш бирә ала. Иң актив һәм тугры дусларны «Интертат дуслары клубы» берләштерәчәк.

Электрон басмада, гадәттәгечә, укучыларның да язмаларына урын бирелә. Алар «Укучыларыбыз яза» рубрикасында чыгачак. Яңа рубрикалар да өстәлгән.

Фотография тормышыбызга бик нык үтеп керде. Аеруча фотоның газета-журналлар битенә үтеп керүен әйтеп китергә кирәк. Журналистикада аерым бер тармак – фотожурналистика яши. Фотолар җәмгыять аңына үтеп керергә ярдәм итә.

Матбугат битләрендә басылганда, фотографиянең текст белән тыгыз бәйле булуы мөһим.

Фоторепортажда катнашучыларның хис-кичерешләрен, эмоцияләрен сүз ярдәменнән башка күреп була. Укучыга мәгълүмат җиңел барып ирешә. Моннан ун-унбиш еллар элек кенә фоторәсемнәр ясау никадәр мәшәкатьле, зур түземлелек, чыдамлык сораучы эш иде. Ә хәзер! Кеше саен фотоаппарат, дигәндәй. Хәтта телефон белән дә төшерәләр. Фото ясауның бернинди дә катлаулылыгы юк. Фотоелъязманы алып бару да җиңел.

Бүген техника алга киткән дөньяда яшәве гаять күңелле. Мобиль репортер төшенчәсе еш кулланылышта йөри. Интернет челтәрендә игъланнар журналистика өлкәсенә катнашы да булмаган кешеләрне «мобиль репортер»

булырга өнди. Кулларында планшет, сыйфатлы кәрәзле телефон булган һәрбер кеше мәгълүмат җыя ала дигән нәтиҗә килеп чыга.

Яңартылган электрон газетада хәзер яңалыклар, язмалар тагын да күбрәк, мөмкинлекләр зуррак.

Бүгенге көндә күпчелек газета-журналларның электрон версиясе бар. «Безнең гәҗит», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре» һ.б.

Ә менә «Бердәмлек» газетасының интернетта аерым үз сайты юк. Шуңа күрә дә «Бердәмлек» газетасы журналистлары интернетны башка юл белән яуларга булды. 2011 елның мартыннан башлап бүгенге татар дөньясының иң популяр булган, иң киң таралу тапкан «Матбугат.ру» интернет сәхифәсендә, аның администрациясе белән килешү төзеп, «Бердәмлек»тә дөнья күргән, күп катлам укучыларда кызыксыну уятырдай язмаларны урнаштырып торалар[3].

Шуны әйтергә кирәк: Интернет пәйда булу белән, телгә игътибар кимеде. Компьютерлаштыру телләргә, бигрәк тә татар теленә бик нык тәэсир итте. Әйтик, «ВКонтакте», «Одноклассники» һәм башка социаль сайтларда утыручылар татарча уку-язуны онытып бара, дисәң дә була. Яшьләр рус телендә генә языша. Хәтта татар сүзләрен дә урыс хәрефләре белән яза. Анда өтер, нокта кебек тыныш билгеләрен куймыйлар да, ике нокта, нокталы өтерләрне әйтәсе дә юк. Шулай ук баш исемнәрне дә кечкенә хәрефтән язу күренеше бар. Мәктәп баласы компьютерда кичләрен татарча сөйләмне урыслаштырып язгач, мәктәптә татар теленнән диктантны да начар язачагы билгеле. Инде «ә» хәрефе урнына «э» языльганына күз дә ияләшеп бара.

Интернет киң таралган булса да, күп кенә татарлар аның белән ничек кулланырга икәнен белеп бетерми. Ягъни, бөтендөнья «пәрәвезендә» татар китапларын, татарча мәкаләләр булганын күпләр ишетеп тә белми. Шулай да, электрон китапханә зур дип әйтеп булмый. Барлык кирәкле китапларны да таба алмыйсын.

Җитдирәк сайтларга килгәндә, әйтик шул ук матбугат.ру, ватантат.ру, анда әле татар сөйләме яши. Барлык яңалыклар да саф татарча, дөрес итеп языльып бара. Алай да, комментарийларда урыс сүзләрен кыстырганнары, җөмләнең теләсә кайсы җиренә өтер, сызык куйганнарын күреп була. Урам сөйләме дә еш очрый, ләкин аларны сайт хуҗалары шунда ук юкка чыгарырга тырыша.

Интернет – дөнья казанышы, аның аша татар халкын тагын да күпләп җыеп булса да, нәкъ менә Интернетта татар сөйләменә игътибар җитеп бетми әлегә. Күп кенә татар теле укытучылары фикеренчә, телебез әдәби сөйләмнән ераклаша.

Татар журналистларыбызның интернетка карата үз фикерләре бар. Шуларга тукталып китик.

Туфан Миңнуллин исән чакта болай дип әйтеп калдырган: «Интернетны мин якыннан ук белмим. Гадәттә, оныкларым ачып күрсәтә. Безнең ил интернетка бик үк әзер түгел дип уйлыйм. Шуңа күрә интернетта пычраклык күп, аралашу культурасы аксый. Миңа үземә карата «Матбугат.ру»да языльган

комментарийларны кәгазь битенә күчереп бирәләр. Әмма, гадәттә, мин аларны карап та тормыйм. Керпе, Динозавр дип ниндидер исемнәргә качып язучыларны өнәп бетермим. Шулай да татар басма матбугатын интернетка чыгарырга кирәк. Бу бигрәк тә фикер алышу өчен мөһим, дип уйлыйм» [1].

Татарстанның халык язучысы, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Равил Фәйзуллин түбәндгечә яза: «Без «Казан утлары» язмаларын «Матбугат.ру»га куеп барабыз. Комментарийлар да шактый була. Шулай ук «Ватаным Татарстан»да басыла торган «Матбугат.ру» комментарийларын кызыксынып укып барам. Газетадагы язманы уку гына түгел, ә укучылар кайтавазын да ишетү күңелле. Шулай да интернетка карашым шактый каршылыклы. Беренчедән, Шөпшә, Иркә, Усал дип аноним язуларны яратмыйм. Элекке замандагы аноним донослар кебек булып китә. Икенчедән, техник революциянең бер ягы яхшы, икенче ягы хәвефле. Әнә хәзер WikiLeaks сайты тирәсендә дөньякүләм шау-шу купты. Бер яктан файда, икенче яктан зыян. Менә кесәмдә электрон карта бар хәзер (кесәсеннән чыгарып күрсәтә), шунсыз эш урыныма керә алмыйм. Коридорда бар җирдә видеокамералар. Күзәтәләр. Алар бар да файдагамы соң? Әйтик, Тукай Җаекка самолет белән очкан булса, үз әсәрләрен яза алыр иде микән? Кыскасы, Кеше бер яктан төзи, икенче яктан җимерә, үз казанышларының колына әйләнә. Бер шигыремдә мондый сүзләр бар иде. Алар бүген дә бик актуаль:

Кеше ник дип өзә икән,
Үзенә иң газиз кылны...

Ә интернет ул яшь буын казанышы. Мәсәлән, минем 9 яшьлек улым компьютерны миңа караганда яхшырак белә. Без хәзер таш гасыр кешеләре булып калдык инде. Интернет ул яшь буынныкы. Ул аның бәхете дә, бәхетсезлеге дә...» [1]

Газета-журнал бетәчәгенә ышанасы килми. Хәзер бит бөтен дөньясы компьютерлаштырылган. Көне буе монитор каршында утырганнан соң, яңалык, дөнья хәлләре турында да монитордан укып утырасы килер микән? Миңа калса, эштән арып кайткач диванга сузылып, кыштыр-кыштыр газета актарудан да тәмле нәрсә юк.

Чыганаклар

1. «Матбугат.ру» газета һәм журналларны хезмәттәшлеккә чакыра (+бонус) / URL: http://matbugat.ru/news/?id=3558 (Мөрәҗәгать итү датасы: 19.03. 2013).

2. Мөхәммәтов Фәнис. Чүп оясы ясамыйк / URL: http://matbugat.ru/news/?id=5350 (Мөрәҗәгать итү датасы: 19.03. 2013).

3. Әһлиуллин Рәфгать. «Бердәмлек» – «Матбугат» сайтында / URL: http://matbugat.ru/news/?id=5846 (Мөрәҗәгать итү датасы: 19.03. 2013).

«Tamle tel» аша тел өйрәнү мөмкинлекләре

Л.Р.Нәсыйхова,

"Салават күпере" журналының
баш мөхәррир урынбасары

Сәясәтчеләр авызыннан «Хәзерге заман җәмгыятен модернизацияләү процессының өстенлекле юнәлеше булып мәгариф системасын мәгълүматлаштыру тора» дигән сүзләрне еш ишетәбез. Күп очракта мондый сүзләргә инде игътибар да бирмибез кебек... Дөрестән дә хаклыбыз микән?

Белем бирү системасын мәгълүматлаштыру дигәндә, без балаларга белем бирүнең барлык этапларында да заманча технологияләрне куллануны күз алдында тотабыз.

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы булган «Салават күпере» журналы редакциясе инде 20 елдан артык мәктәпкәчә һәм башлангыч мәктәп яшендәге балалар өчен эшли. Бу яшьтәге балалар яңа белем алуга омтыла, фикерләү сәләте оригиналь була. Заманның һәм, әлбәттә, балаларның әлеге «таләпләре» безнең редакцияне «Tamle tel» iPad-проектын тормышка ашыруга этәрде.

Хәзерге нәниләрнең әти-әниләре (шартлы рәвештә, 22-32 яшьлек кешеләр) компьютер технологияләрен көнкүрештә һәрдаим кулланалар. Шуңа күрә алар тудырган балаларга да «Android», «iPhone», «iPad» кебек «яңа буын» уенчыклары кирәк. Бүгенге нәниләргә интернет челтәрендә эзләп табылган онлайн уеннарны уйнау берни дә тормый. Ләкин интернет киңлекләрендә спам, реклама дип аталган һәм бала өчен бик үк кирәкле һәм файдалы булмаган «чүп-чар» да бик күп бит. Нишләргә соң?

Җавап бик җиңел табыла. Яңа технологияләрне белем алуда ярдәм булырлык итеп җайлаштыру, безнең очракта – «Tamle tel»не куллану. Биредә «Салават күпере» журналы геройлары – урман малае Шүркә, чибәр кыз Елмай, шук-шаян Шалай, тылсымчы Матуркай һәм «Яшь ТНВ» каналындагы «Күчтәнәч» тапшыруында яшәүче Йомшаккай баланы өч телдә сөйләшергә мөмкин булган серле дөньяга чакыра. Барлык биремнәр дә уен аша үтәлә. Ә уен-биремнәр, үз чиратында, тавыш ярдәмендә тагын да җиңелрәк кабул ителә. Биредә баланың күрү һәм ишетү аша кабул итү активлыгы үсә.

Белгәнебезчә, туган тел – иң «тәмле, баллы, татлы» тел. Шуңа күрә туган татар телен өйрәнү дә һәр бала өчен файдалы гына түгел, ә бик кызыклы, «татлы» да, «тәмле» дә булырга тиеш. Шуның белән беррәттән, рус һәм инглиз телләре нигезләренә дә төшенү заман таләпләренә ярашуга тагын бер адым булып тора.

Балалар белән беренче мәртәбә очрашудан соң шундый нәтиҗә ясалды. Беренчедән, ачык төсләр белән ясалган рәсемнәр баланың кәефен күтәрә. Икенчедән, уен вакытында сабыйның инде яратып өлгергән геройлары сөйләшә дә әле – элемтә, аралашу мөмкинлеге туа. Өченчедән, алар белән уйнарга да мөмкин! Балаларның әлеге электрон әсбапка уңай реакциясен күргәннән соң, «Tamle tel»нең, чыннан да, яңа буын проекты, ягъни XXI гасыр балаларын өйрәтү һәм үстерүнең яхшы ысулы икәне расланды.

«Tamle tel» – Татарстанда балалар өчен махсус эшләнгән һәм татар теле һәм башка телләрне өйрәнү барышын кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль иткән беренче һәм әлегә бердәнбер проект. Нәкъ менә бу яшьтә сабый зиһене яңа белем-күнекмәләргә аеруча сизгер, фикер йөртүе стандарт калыплардан азат һәм үзенчәлекле. Проект материалын уен рәвешендә тәкъдим итү дә уңышлы. Бала белән үткәргән вакыт әти-әни өчен дә кызыклы һәм файдалы булачак.

Уен элементларын җәлеп итү һәм актив куллану үсеп килүче буынның танып белү, иҗади һәм эмоциональ активлыгына этәргеч булып тора. «Tamle tel»дәге биремнәр гади һәм яшь буенча җайлаштырылган: биредә игътибарны үстерүгә, әйберләрне сан, сыйфат, мәгънә ягыннан сайлап, аерып алуга һ.б. нигезләнгән төрле биремнәр урын алган. Уеннар аша бала уку, язу, санау, рәсем ясау кебек беренчел күнекмәләрне бер үк вакытта татар, рус һәм инглиз телендә үти, буш вакытын тулыландыра. Шул ук вакытта берничә мөһим психологик-педагогик функцияне башкара. Бирегә эстетик стиль тәрбияләү (мисал өчен, «Елмайны киендер» уены) белән беррәттән, сүзлек запасын баету, авазларны дөрес әйтә белү (мәсәлән, «Кем? Кайда?», «Тиз-тиз-тизәйткеч!» уеннары) һ.б. керә. Һәр санда аерым бер теманы ачуга юнәлдерелгән уеннар, биремнәр берләштерелгән.

Шулай ук «Урман табышмаклары», мәсәлән, уенында бирем урман җәнлекләре турында шигъри формада язылган табышмаклардан гыйбарәт. Биредә сөйләмне үстерү һәм аерым авазларны әйтүгә (логопедия) зур игътибар бирелә. Бу гамәл сүзләрне тыңлау һәм бала тарафыннан аерым авазларны кабатлауга нигезләнгән.

«Биектә-биектә» уенында исә чагыштыру күнекмәләренә, игътибарны арттыруга басым ясала. Филологик яктан чыгып караганда, һәр уенда өйрәнү өчен сайланган теманы ача торган сүзләр дөрес һәм урынлы сайланган.

Өйрәнергә тиешле яңа сүзләрнең чагылышын бала рәсемдә генә күреп калмый, ә ничек әйтелергә тиешлеген параллель рәвештә өч телдә ишетә дә. Бу исә материалны яхшы үзләштерү, игътибар туплау һәм күзаллауны активлаштыру өчен мөһим. Димәк, «Tamle tel» – ул татар, рус һәм инглиз телләренең матурлыгы һәм байлыгын чагылдыручы проект.

Гамәли яктан караганда, мәгълүмати технологияләрне куллану белем бирүне сыйфатлы оештырырга, балаларның иҗади сәләтен үстерүдә ярдәм итәргә, балаларны танып белү процессына тартып торырга, милли традицияләр нигезендә тәрбияләргә булыша.

Һәр сан-ярдәмлек интернет челтәренә – киң кулланылыш өчен куелганчы, проект авторлары тарафыннан апробацияләнә. Моның өчен авторлар махсус рәвештә берничә мәктәпкә һәм балалар бакчасына барып, балалар белән һәр уенны уйнап карый: балаларның һәр биремне ничек кабул итүен, аңлау-аңлап җиткермәвен, уеннарның уңышлы һәм җитешсез якларын ачыклый, һәр баланың һәм укытучыларның әлеге әсбапка карата фикерләрен ишетә. Моннан тыш, авторлар психологлар һәм филологлар белән дә хезмәттәшлек итә. Нәкъ менә соңгылар фикеренчә, «Tamle tel» – ул балалар бакчалары һәм башлангыч

мәктәпләрдә кызыклы дәресләр алып баруда беренче ярдәмче, әти-әниләрнең бала белән бергә уку, уйнау, күңел ачу, буш вакытын файдалы итеп үткәрү чарасы да.

Чыганак

Тәмле тел / URL: http://salavatkupere.ru/tamle-tel.html (Мөрәҗәгать итү датасы: 10.02.2014).

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүдә татар матбугатының әһәмияте

Г.Н.Нигъмәтҗанова, Казан шәһәре Киров районының
татар телендә тәрбия һәм белем бирүче
321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасының
югары категорияле өлкән тәрбиячесе

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белемне Кол Галиләрдән, Җәлилләрдән, Тукайлардан безгә мирас булып калган татар телендә бирергә тырышабыз. Татар теле ана теле булып, ана сөте белән безнең йөрәгебезгә, аң-зиһенебезгә сеңгән, туган телебез буларак формалашкан. Ә туган тел төшенчәсенә бик зур мәгънә салынган. Ул әти-әни, туган җир, ватан сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә бөек, изге сүз. «Ана теле аша үзләштерелгән идеялар, белем һәм күнекмәләр хәтергә көчлерәк сеңә. Баланың ана телен үзләштерүе һәм аны актив куллануы шул телдә тәрбия һәм белем алуы аның һәрьяклы үсеше өчен уңай шарт булып тора.

Бөек Тукаебыз язганча, яшибез без рус белән, тел, шөгыль вә әхлак алмашып. Безнең 321 нче «Торнакай» татар балалар бакчасында балаларга тәрбия һәм белем бирү тулысынча татар телендә алып борыла. Шулай ук бакчабызга башка милләт балалары да йөри. Безгә, тәрбиячеләргә, аларның милли үзенчәлекләрен, ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып эш итәргә кирәк.

Яшерен-батырын түгел, элеккеге елларда балаларга саф татар телендә тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә күп кенә кыенлыкларның берсе булып, татар телендә методик кулланмаларның җитешмәве булды. Педагогларга шөгыль материалларын русчадан татарчага тәрҗемә итәргә туры килде. Бу алардан икеләтә көч, вакыт таләп итте. Ләкин без бу авырлыклардан югалып калмадык. Бар булган көчебезне куеп иҗади эш итәргә өйрәндек. Балаларга татар телен өйрәтүдә зур уңышларга ирештеләр.

Хөкүмәтебез җитәкчеләре, мәгариф хезмәткәрләре, бик күпләгән танылган шәхесләребез бу өлкәдә күп көч куйды. Балаларны татар телендә методик кулланмалар, ярдәмлекләр белән тәэмин итүдә татар матбугаты да үзенең зур өлешен кертте. Чөнки замана көннән-көн алга бара, инновацион яктан үсеш ала. Мәгариф өлкәсе дә заманадан артта калырга тиеш түгел. Без

укыту-методик комплексларын мәктәпкәчә яшьтәге оешмаларда тәрбия һәм белем бирү процессын замана таләпләренә якынайтучы иң мөһим чара, дип саныйбыз. Соңгы вакытта мәктәпкәчә яшьтәге оешмалар укыту-методик комплекслары белән тәэмин ителделәр (болар – күрсәтмә материаллар, аудио-видео язмалар, методик кулланмалар, татарчага тәрҗемә ителгән мультфильмнар бирелде). Алар педагоглар өчен зур ярдәмлек булдылар, балаларның сөйләм телен үстерүдә, һәрьяклап үсешләре өчен уңай шартлар тудырдылар.

Педагогларыбыз китапларны, аудио-видео язмаларны үзләренең педагогик эшчәнлекләре барышында актив, даими һәм эзлекле рәвештә кулланалар. Бу методик кулланмалар, аудио-видео язмалар, күрсәтмә материаллар һәрберсе игътибарга , мактауга лаеклы. Бигрәк тә З.К.Вәлиеваның «Балачак аланы» хрестоматиясенә тукталып үтәсем килә. Балаларга ана телен өйрәтүдә төп алымнарның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына таяну. Нәкъ менә шушы хакыйкатьне истә тотып, әлеге хрестоматиядә балаларның яшь үзенчәлекләре буенча билгеләнгән бүлекләр халык авыз иҗаты әсәрләре белән башланып китә.

Язучыларыбыз тарафыннан иҗат ителгән серле әкиятләр һәм тәрбияви эчтәлекле хикәяләр дә сабыйларга олы бүләк булды. А.Алиш, Җ.Тәрҗеманов, Р.Батулла, Р.Вәлиева, Ф.Яруллин, С.Сәүбанова һ.б. язучыларның кызыклы һәм мавыктыргыч әкиятләрен тыңлап, балалар уңай һәм тискәре сыйфатлары аеруча, әкият геройларының уй-хисләренә, эш-гамәлләренә дөрес бәя бирә белергә өйрәнәләр.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга эстетик тәрбия бирү һәм аларда әхлак сыйфатлары булдыруда татар балалар шигърияте зур әһәмияткә ия. Эчтәлеге белән сабыйлар күңеленә якын, аңлаешлы шигырьләрнең нинди тәрбияви көчкә ия булуы, баланың сөйләмен баетуда, зиһенен үстерүдә иң тәэсирле тәрбия чарасы икәне һәркемгә мәгълүм. Татар халкының бөек шагыйрьләре Г.Тукай, герой шагыйрь М.Җәлил, табигать «җырчысы» Х.Халиков, нәниләр дөньясында «үз» кешегә әверелгән Ш.Галиев, Р.Мингалим, Р.Вәлиева, М.Фәйзуллина һ.б.ның шигырьләре балаларда туган ил, торган җир, туган телгә мәхәббәт тәрбияләүдә ярдәм итә. Аларда патриотлык һәм интернациональлек, үз илең белән горурлану хисләре тәрбияли.

Хәзерге заман татар шагыйрьләре Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Ф.Яруллин, Э.Шәрифуллина, Р.Корбан, Л.Лерон әсәрләре балаларның кеше белән табигать арасындагы бәйләнешләр турындагы күзаллауларын киңәйтә, әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалашуга ярдәм итә.

Балаларыбызны татарча сөйләшергә өйрәтүдә татар матбугаты да үзенең зур өлешен кертә. Бүгенге көндә балалар һәм тәрбиячеләр өчен төрледән-төре газета-журналлар басылып чыга: «Сабыйга», «Сабантуй», «Салават күпере», «Ачык дәрес», «Көмеш кыңгырау», «Мәгариф», «Күчтәнәч» басмалары безнең якын дустыбызга әверелделәр. Бигрәк тә «Салават күпере» журналы белән тыгыз элемтәдә эшлибез. Әлеге газета-журналларның һәр санын көтеп алабыз, бергәләп кычкырып укыйбыз, искиткеч матур рәсемнәрен карыйбыз, төрле

биремнәрен үтибез, башкаткычларны чишәбез. Әлеге журналга үзебез иҗат иткән шигырләрне, әкиятләрне тәкъдим итәбез. Аларны бик еш кына яраткан журналыбыз битләрендә бастырып чыгаралар. Күп кенә педагогларыбыз үзләренең актив эшчәнлекләре нәтиҗәсендә «Салават күпере» журналының грамоталарына һәм дипломнарына ия булды. Бүгенге көндә татар матбугатының мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирүдә әһәмияте аеруча зур. Чөнки матбугат хезмәткәрләре замана таләпләренә җавап бирердәй алымнарга мөрәҗәгать итәләр. Бала тәрбияләү өлкәсендә иң актуаль булган мәсьәләләрне кузгаталар, дөньяга бала күзе белән карыйлар, сабыйларыбызның эчке дөньясын аңлый, тоя беләләр. Шуңа күрә дә без, балалар бакчасында эшләүчеләр, татар матбугатының бала тәрбияләүдәге ролен вакытында чыккан якты кояшка, вакытында яуган шифалы яңгырга, вакытында искән җилгә тиңләр идек.

Белем һәм тәрбия чарасы буларак «Безнең гәҗит» газетасы

А.А.Нургатина, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты,
доцент Р.Л.Зәйни)

Бүгенге көндә татар матбугатында газета-журналлар күп. Алар төрлесе-төрле аудиториягә карап, укучыларын табып, татар матбугатын баетуга өлеш кертә. Һәрберсе укучылары өчен көрәшә, матбугат чарасының үз аудиториясе күңеленә үтеп керүен тели. Шуңа да төрле алымнар белән укучылар санын арттырырга тырыша. Ә инде газета-журналның даими үз укучылары булу – ул нәтиҗәлелек дигән сүз. Шуның белән берлектә газета әле укучылар өчен тәрбия чарасы да булып тора. Газета укучылар күңеленә тәэсир итми калмый, кем гыйбрәт ала, кем исә хаксызлык табып, газетага хатлар юллый. Укучыларның газетада хат аша аралашулары – үзенә бер тәрбия чарасы. Матбугат чарасына якын булулары, алар белән элемтәдә торулары нәтиҗәсендә укучыларның фикерләре югалмый, аларны матбугат тыңлый, ишетә, күрә дигән мөнәсәбәт туа.

«Безнең гәҗит» басмасы укучы хатларыннан төзелә дисәң, ялгыш булмас. Дини темаларга хатлар өчен «Иманга юл» сәхифәсе булдырылган, четерекле көнкүреш темаларга караганнары өчен «Әйтер сүзем бар», «Әйтсәм әйтим» дип исемләнгән сәхифәләр газета битләрен бизи. «Гыйбрәт ал», «Яралы язмышлар», «Җан авазы» сәхифәләре исә тормышта урын алган тетрәндергеч вакыйгалар турында яза. Газета укучыларының кызыклы хикәя-повестьлары «Татарча сериал» сәхифәсендә дөнья күрә.

«Безнең гәҗит»нең укучы хатларыннан төзелгән кушымталары да бар. Фән аңлатып бирә алмаган хәлләр турында хикәяләрне «Могҗизалы дөнья» туплый. Укучылар үзләренең тәҗрибәләрен дә уртаклашырга ярата. Андый хатлар «Мыштым гына» кушымтасында дөнья күрә. Каләм чарларга яратучы

укучыларның хикәя-повестьлары «Татарча сериал» сәхифәсе белән берраттан «Серләр гәҗите»ндә дә туплана. Газетаның «Сорагыз!» сәхифәсен дә укучылар белән аралашуның бер алымына кертергә була.

Редакциягә хатлар бик күп килә. Кайбер язмалар укучылар күңеленә эз салып, кайтаваз хатлар берничә санга сузыла. «Әгәр хат алмый торсак та «Безнең гәҗит»не ике елга якын шушы булган хатлар белән генә чыгара алыр идек», – ди газетаның баш редакторы Илфат Фәйзрахманов. Газетада хатлар бүлеген Зөлфия Фәйзрахманова җитәкли. Редакциягә килгән хатларны җентекләп тикшереп, төзәтеп газета битләренә чыгарып кына калмый, кайбер укучылар белән хат та алыша.

Газетада укучылар арасында конкурслар да уздырыла. Күптән түгел «Алар бездән мәрхәмәтлерәк» дип исемләнгән бәйге игълан ителде. Безнең кече туганнарыбыз белән булган хәлләр турында язмалар редакция почтасына килә дә башлады инде. Бәйге тәмамлангач, катнашучыларга истәлекле бүләкләр тапшырылачак.

«Безнең гәҗит» редакциясендә телефон тынып тормый. Кайбер шалтыратулар башка төбәкләргә командировкаларга чыгарга этәрә.

Нинди генә очрак булса да, күзгә-күз карап аралашудан да яхшысы юк, минемчә. Кешенең хис кичерешләрен телефон аша да, ул язган хат аша гына да тоеп бетереп булмый. Татарларда «хәлгә керә белү» дигәй әйтем бар. Язмаларның камил, укучылар күңеленә үтеп керүен телисең икән, син дә кеше күңеленә керә белергә, «ул» булып карарга тиешсең. «Безнең гәҗит» редакциясендә кунаклар еш була. Аларны да берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин: беренче төркем - студентлар. Камиллекнең чиге юк, диләр татарларда. Шуңа да газетада студентлар еш була, редакторның, монда эшләүче талантлы журналистларның һөнәрләренең асылына төшенер өчен киләләр. Илфат Фәйзрахманов күп очракта мастер-класслар оештыра, журналистика белән кызыксынган студентларга үзенең киңәшләрен бирә.

Икенче төркем – газетаны яратучылар. Берәүләре рәхмәт әйтергә килә. Кайберләре, язмаларны укыгач, күңел кылларына тиеп, үзләре белән булган хәлләр турында сөйләр өчен киләләр. «Безнең гәҗит»нең төзелешен карап, редакциянең эш серләренә сокланып китәләр.

Өченче төркем – тәнкыйтьчеләр. Тәнкыйть кешене үстерә, канат куя дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Гел макталып торсаң да, тупасланырга, сәләтеңне дә югалтырга мөмкинсең. Шуңа да «Безнең гәҗит»тә тәнкыйтькә бик уңай карыйлар. Газетаны һәрбер хәрефенә кадәр укып барганнарның редакциягә килүләре үзе бер сөенеч.

Дүртенче төркем – сәер, хәтта авыру кешеләр. Мисал өчен, газетага бер юлы әби кеше килә. Башына магнитлар бәйләгән карчык, «күктән минем ешлыгымны тотып алганнар, миңа сигнал җибәрәләр» дип зарлана, сигналларны туктарырга дип ярдәм сорап журналистка мөрәҗәгать итә. Редакциядә андыйларны да игътибарсыз калдырмыйлар.

Газета битләрендә басылган язмаларга да тукталыйк әле. Мисал өчен Азнакай якларына барып язылган «Пластик «коммунизм» бурычы» дигән

материал («Безнең гәҗит», 2011, 19 окт.). Язманың төп герое Азнакайдан Сәкинә апа Хәйруллина газета редакциясенә шалтыратып, үзенең финанс яктан алдануы, «төп башына» утырып калуы турында сөйләгән. «Безнең гәҗит» журналистлары бу хәлләрнең чишелешен эзләп юлга чыга.

Сәкинә апа яңа ачылган пластик тәрәзәләр сатучы фирмага бухгалтер булып керә. Берничә ел эшләгәч, фирма зур кредитлар ала. Аннан соң җитәкче, бар бурычны да Сәкинә апага калдырып, башка илгә кача. Бу эшне журналист Эльвира Фатыйхова тикшергән. Сәкинә апаның үзен күреп сөйләшә, аннан соң суд приставларына бара, юрист киңәшләрен ала. Тикшерүче буларак үз вазыйфаларын үтәп чыга. Нәтиҗә ясалып, язма газета битләрендә дөнья күргән.

Әлеге авторны тагын бер – «Саба халкы нигә зарланмый?» язмасы Саба халкының тормышы, ял итүләре хакында язылган («Безнең гәҗит», 2012, 29 февр.). Журналистны Саба районы хакимияте башлыгы авыл халкы оештырган кичәгә чакырган. Эльвира исә кичәне карап кына калмый, анда катнашучылар белән әңгәмә кора, тормыш итүләре хакында сорый. Бер командировкага килгәнсең икән, вакыйгага кагылышлы кешеләрне төрле яктан карарга, алар белән ныклы әңгәмә корырга тырышырга кирәк. Юлларда узган вакыт үкенечкә булмасын.

Газета битләрендә шактый гауга кузгаткан «Ир, хатын һәм сөяркә өчпочмагы» язмасын да искә алыйк («Безнең гәҗит», 2011, 30 март). Төп герой, хатынын хур итеп, шул ук авылдагы башка хатын белән чуала башлый. Командировкага баргач, журналист күршеләргә дә керә, җирле халыктан да бу гаиләнең нинди булуы хакында белешә. Шуннан соң гына халык фикеренә һәм тормыш тәҗрибәсенә таянып язмасын әзерли, укучылар хозурына тапшыра

Газетада журналист тикшерүе белән Эльвира Фатыйхова шөгыльләнә. «Кайсы җиргә генә барсам да, «Безнең гәҗит»не укучылар табылып тора, аннан килүемне белгәч сөенәләр,» – ди ул. Әлбәттә, газета – халык турында яза. Үзе турында язганны халык укый, кызыксына. Шуңа да «Безнең гәҗит»нең тираж күрсәткече югары дип саныйм.

Журналистикада традицион алымнар
һәм яңа технологияләр синтезы

Л.Р.Сабирова, КФУның өлкән укытучысы,
филология фәннәре кандидаты

Басма матбугатның популярлыгы көннән-көн кими. Беренчедән, финанс кризисы сәбәпле, оешмалар үз чыгымнарын киметергә мәҗбүр. Басма матбугатка дигән акчаны алар 60-70 процентка кыскартты. Икенчедән, газеталарның барысында да диярлек бер үк мәгълүмат. Шулар арасыннан иң төгәл, дөрес мәгълүмат бирүче, кызыклы матбугат чарасын сайлап алу да җиңел түгел. Өченчедән, күп газета-журналлар ябылды. Бу шулай ук язылучы санын киметә. Шәһәрдә газетаны яздырып алучылар бик аз, районнарда күбрәк,

мәсәлән, Кукмара, Балтач, Саба, Теләче, Актаныш районнарында әле күп укыйлар икән [1]. Тиражлар кимүдә иң төп сәбәп – Интернет.

Интернеттан башка тормышны күзаллау кыен. Электрон хезмәтләр, кино, музыка, аралашу – болар бар да бүген кечкенә генә авылларга кадәр килеп җитте. Һәм алардан бүген миллионлаган халык файдалана. Сер түгел, Интернет бүген – яхшы акча эшләү урыны да. Аның үз кагыйдәләре, нечкәлекләре һәм проблемалары бар. Әлеге җәһәттән «Российская газета» Россиянең элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры урынбасары Алексей Волин белән кызыклы гына әңгәмә урнаштырган иде. Ул «Ватаным Татарстан» газетаның 16 нчы санында «Интернет – ирек мәйданымы?» дигән исем белән басылды [2]. Пиратлыкка каршы закон инде ярты елдан артык гамәлдә икән. Ул ничек эшли? Бу хакта А.Волин тубәндәге фикерләр җиткерде: «Узган елның җәендә кабул ителгән әлеге закон ике индустрияне хезмәттәшлек итәргә мәҗбүр итте. Ул уңай нәтиҗәләр бирергә дә өлгерде. Бүген контент (сайтларда урнаштырылган текст, мультимедиа) хокукына ия булучыларның да, аннан файдаланучыларның да мәнфәгатьләре чагыша, алар бер-берләренә бернинди дәгъва белдермичә яши. Әйтик, кулланучылар үз акчасыннан колак какмый башлады, ә Интернет-мәйдан хуҗалары легаль контентта акча эшләргә өйрәнде.

Электрон коммуникацияләр ассоциациясе мәгълүматлары буенча, Интернеттан акча түләп кинофильм күчереп караган кулланучыларның саны алты миллионнан сигез миллионга арткан. Бөтендөнья челтәрендәге легаль контент 30 процентка үскән дигән сүз бу. Тагын бер кызык әйбер бар. Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү максатыннан үткәрелгән сораштырулар күрсәткәнчә, Россия буенча легаль контенттан файдаланган өчен түләү бәясе кимегән. Хәзер кеше аз түләп, күбрәк сатып ала башлаган. Сораштыруда биш мең Интернет-кулланучы катнашкан. Нәтиҗәдә Интернеттан алып күчерелгән яки онлайнда караган фильм өчен уртача түләү бәясе Россия буенча – 400 сумнан 380 сумга, Мәскәү буенча 580 сумнан 280 сумга төшкән».

«Күпләр Интернетка богау киертерләр дип курка. Моңа карата нәрсә әйтә аласыз?» – дигән сорауга Алексей Волин: «Интернетта бернинди дә богаулау юк. Бары тик безнең дәүләттә яши торган законнар һәм кагыйдәләр аңа да кагыла башлады. Дөрес, күпмедер вакыт Интернет үз тормышы белән яши килде, әйтерсең лә ул РФ биләмәсеннән читтә иде. Җитәр! Тәртипкә өйрәнергә кирәк. Минем бер мәртәбә дә Интернет-индустрия вәкилләреннән челтәрдәге ирекне бетерәләр дип ризасызлык белдергәннәрен ишеткәнем булмады. Чынлап торып эшли торган һәм акча таба белә торган җитди партнерларыбыз зарланмый. Гадәттә бездә ирек турында үзләрен әллә кемгә куйган һәм бер тиен дә акча эшли алмаган кешеләр генә шапырынырга ярата», – дип җавап бирде [2].

Чит илдә дә басма матбугатның хәле көнләшерлек түгел, анда басма матбугат бетәчәк дигән фаразлар бер 15 ел элек яңгыраган иде, әмма алай булмады бит. Анда газетага язылу көн дә киосктан сатып алуга караганда күпкә отышлырак.

Гомумән, мультимедиа газетлары – ул матбугатның киләчәге. Моны конвергент редакция, ягъни журналистиканың синтезы дип тә атыйлар. Интернетта сайлап алу мөмкинлеге зур. Ләкин әлегә бөтен кеше дә сайланырга әзер түгел. Шуңа күрә кеше интернетка керү белән бераз югалып та кала.

Газет журналистына җитдирәк карыйлар. Ә интернеттан укыганда «менә интернеттан алдым», «интернетта бар иде» диләр. Аны кем, каян алып язган... Күп кенә чыганаклар буталып бетә, сайтлар бер-берсеннән күчерә. Күп очракта автор да күрсәтелми бит. Интернет журналистларны ялкауландыра дигән уй да барлыкка килә. Күп кенә эш интернет аша башкарыла бит. Мәсәлән, «ВКонтакте» аша интервью алулар очрый. Журналистлар соңгы арада җыелыш һәм башка чараларга сирәк йөри. Бу аеруча шәхси газетларга кагыла. Дәүләтнекеләр әле йөрергә мәҗбүр. Бүген иң «тере» мәгълүмат чаралары – район газеталары. Андагы журналистлар күп йөри, мәгълүматны үз аяклары белән таба. Әмма район газетларына белемле, тәҗрибәле журналистлар җитми. Шуңа күрә интернетка ике яклы карыйбыз: бер яктан ул киң мөмкинлекләр бирә, икенче яктан аларны кыса да. Кара-каршы сөйләшеп әңгәмә коруны берни дә алыштыра алмаячак. Ләкин оперативлык артыннан куып, хакыйкать, дөреслек турында онытырга кирәкмидер.

Мәгълүмат чаралары укучылар, тыңлаучылар, караучыларны җәлеп итү өчен үзара көндәшлек итә. Мондый шартларда алар яңа технологияләр һәм проектлар кулланырга, маркетинг тикшерүләре үткәрергә мәҗбүр. Ул юлга басмаган мәгълүмат чаралары мәгълүмат базарында үз урыннарын югалтачак. Бу уңайдан тагын бер күренешкә игътибар итәргә кирәк: аудитория өчен көрәш барышында электрон һәм басма мәгълүмат чыганаклары үзара хезмәттәшлек юлларын да эзли.

Интернет – ул заман технологияләренең тел үсешенә бәйле иң яңасы булса да, иң колачлысы, иң активы. Интернетнең кешелек яшәеше өчен әһәмиятле бихисап сыйфатлары арасыннан интернет һәм татар матбугаты темасына караган ике сыйфатын аерып чыгып була: беренчесе ул – аралашу чарасы булуы, икенчесе, шушы максатта тел мөмкинлекләреннән файдалануы.

Ана телебезнең интернетка үтеп керүе, анда функцияләнүе аның яшәешендә дә, киләчәк язмышында да әһәмиятле фактор дияргә нигез бар. Бу процесс, беренчедән, сайтларда татар теленең асылы, үзенчәлекләре, төзелеше, кулланылышы мәсьәләләренең бөтеньдөнья күләмендә яктыртыла алуы, шулар хакында киң колачлы фикер алышу мөмкинлеге тудыру; төбәкләрдә телне куллануның торышын күзәтү, анализлау, үрнәк йә гыйбрәтле мисалларда аны пропагандалау h.б. нигезендә, икенчедән, татар теленең байлыгын, тәэсир көчен, әдәби әсәрләрне һәм башка чыганакларның үзләрен укыта, күрсәтә, ишеттерә алу, ягъни «тере тел» мисалларын бирү ярдәмендә гамәлгә ашырыла [3].

Шунысы куандыра: елдан-ел татар телендә сайтлар арта бара. Татар сайтлары арта баруы яхшы, әмма алар әле сыйфатлы да булырга тиеш.

«Аралашуда тәэсир итү өчен табигать кешегә башлыча өч чара биргән: мәгьнәле һәм хисле сүз, мәгьнәле һәм хисле тавыш-интонация, мәгьнәле һәм

хисле хәрәкәт (ым, ишарә, сурәт, төс h.б.). Шул ук вакытта аралашуның күп кенә терләрендә шушы өч мөмкинлекне бергә, берьюлы куллануны чикләгән. Әйтик, басма матбугат аша безнең әйтү мөмкинлекләре юк, радио сөйләменә килгәндә, без бары тик ишетәбез, сөйләүчене күрмибез. Интернет безгә шул чараларны бердейлектә-синтезда файдалану мөмкинлеген ача. Бу – тәэсир итунең иң көчле чараларыннан. Тик аларны тулы файдалану тәжрибәсе, осталыгы әле бездә житәрлек өйрәнелмәгән. Шулай да эзләнү бара, иҗат омтылышлары куренә» – дип яза танылган тел белгече, галим И.Низамов [3].

Традицион журналистика hәм югары технологияләр алып килгән яңа төр журналистика бүген бер яктан каршылыклар кичерсә, икенче яктан тыгыз хезмәттәшлек итә. Ахыр чиктә эш формада түгел бит, ә эчтәлектә [4]. Комментарийлар, блоглар, газетларның интернет-версияләре... – бу журналистика, ә монысы журналистика түгел дип утырасы юк. Аларның барысы да – *мәгълүмат чыганагы.* Ә кайсын кабул итәргә, кайсын итмәскә – моны укучы үзе хәл итсен. Инновацион журналистика үсеше белән бергә хәзерге заман технологияләре hәм компьютер программаларына ия профильле факультетларда профессиональ белгечләр әзерләү мәсьәләсе дә килеп баса. Безгә, журналистика факультетында эшләүче укытучыларга, профессиональ кадрлар әзерләү турында уйларга кирәк, «контент» әзерләүче журналистларны hәм «продуктны тутыручы» техник хезмәткәрләрне үстерү хакында. Татар кафедрасында бәлки масстер-класслар оештырыргадыр: үз газетаңны интернетта ачу, яңа технологияләргә бәйле... Мәсәлән, iPad hәм iPhone белән эшләргә өйрәтү. (Әйтик, татар матбугатында "Татарстан" журналы беренче булып iPadта чыкты.)

Авторлык хокукы турындагы законны бозу хакында да уйлау сорала. Интернетта урланган, беренчел чыганак күрсәтелмәгән мәгълүматны урнаштыручы порталлар hәм сайтлар эшләп килә. Шулай итеп, алар авторлык хокукы турында законны боза. Бу исә мәгълүмат чараларының үсешен тоткарлый. Әлеге күренеш реклама бирүчеләрне тулы күләмдә җәлеп итә алмаучы мәгълүмат агентлыклары эшчәнлегендә дә чагыла.

Чыганаклар

1. СМИ Татарстана: над тиражной пропастью? / URL: www.business-gazeta.ru/article/53463/ (Дата обращения: 10.01.2014).

2. Интернет – ирек мәйданымы? // Ватаным Татарстан . 2014. 14 февр.

3. Низамов И.М. Татар социолингвистикасы хәрәкәттә. Казан: Казан. ун-ты, 2011. 2 китап. Б. 216.

4. Фатыхова Эльвира. Газета бетә, диләр... // Безнең гәҗит. 2009. 5 авг.

Мәгарифне үстерү өлкәсендә шәхси сайтларның роле

Г.И.Тарханова, Казан шәhәре Вахитов районы
96 нчы гимназиясенең

Милләтебезне агартуда, мәдәниятле һәм гыйлемле итүдә матбугат һәрчак игелекле эш башкарып килде. Патша Россиясендә ни татар матбугатын, ни мәгарифен үстерү өчен хөкүмәт бер тиен дә бүлеп бирмәгән заманнарда да татарның намуслы байлары – иганәчеләре ярдәме белән газета-журналлар чыгып торган. Татар халкы һәрвакыт белемгә омтылып яшәгән. Зыялы катлау вәкилләре белән беррәттән, бай сәүдәгәрләр һәм халыкның урта катлавы да матбугаттан файдаланган.

Совет чорында да матбугат чараларыннан файдалану гадәти күренеш саналды. Хуҗалыкның һәр тармагына багышланган газета-журналларның булуы бик тә уңайлы күренеш иде. Мондый матбугат чаралары, беренчедән, төрле һөнәр кешеләренең эшчәнлеген яктыртып, алар турында тулы мәгълүмат бирсә, икенчедән, бу өлкәдә эшләүчеләр өчен аралашу чарасы да булды.

Мәгариф хезмәткәрләренең, галим-голәманың һәм бу өлкәдә эшләүче башка бик күпләрнең гасыр дәвамында чыгып килүче «Мәгариф» журналы (безгә ул «Совет мәктәбе» дип аталган чордан бирле таныш) бүген дә чын мәгънәсендә мәгърифәт учагы булып тора. Ничә буын мәктәп укытучыларының тәҗрибә уртаклашу, гыйлем эстәү урыны булып саналган бу журналның актуальлеге кимеми, киресенчә, арта бара. Мәгариф һәм фән өлкәсендәге, укыту-тәрбия системасындагы кануннарны һәм һәр яңалыкны, укытучы-новаторларның алдынгы тәҗрибәсе һәм аларны практикада куллану кебек бик күп файдалы материалларны укытучы халкы шушы могтәбәр журнал аша белеп тора. Иҗади эшләүче укытучыларның мәкаләләре журналда даими чыгып бару да – уңайлы күренеш. Алда әйткәнемчә, «Мәгариф» журналы үз вазыйфаларын элек ничек башкарган булса, бүген дә үз кыйммәтен югалтмый, киләчәктә дә мәгърифәт нуры чәчәр.

Җәмгыятебез алга таба үсүен дәвам итә. Прогрессив үзгәрешләр мәгариф системасына да йогынты ясамый калмый. Белем бирү оешмалары эшенә тагын да югарырак таләпләр куела бара. Югары әхлаклы, мөстәкыйль фикер йөртүче, иҗади эшли белүче ирекле шәхес тәрбияләү заманның иң җитди таләпләреннән санала. Бүген укытучы укучыга белемнәр суммасын җиткерүче булып кына кала алмый, киресенчә, ул баланы мөстәкыйль рәвештә белем алырга өйрәтергә тиеш. Моңа өзлексез үсеш хәлендә булганда гына ирешеп булачак. Татарстан педагоглары үзләренең эш тәҗрибәләре белән алдынгылардан санала. Укытучылар мәгариф өлкәсендә уңышлы дип табылган инновацион технологияләрдән бик теләп һәм оста файдаланалар. Бу бигрәк тә компьютер технологияләренә карый һәм бүгенге мәктәпне моннан башка күз алдына да китереп булмый. Дәрестә үтелә торган катлаулы материалны презентацияләр кулланып аңлату, интерактив тактада күнегүләр эшләү, интернет аша кирәкле материалларны табып, төрле проектлар төзү, аудио һәм видеоресурслар куллану, электрон дәреслекләрдән файдалану гадәти күренешкә әйләнә бара. Болар бар да балаларда кызыксыну уятып кына калмый, аларны эзләнергә,

танып-белергә, сәләтләрен ачарга өйрәтә. Компьютердан һәм интернет челтәреннән файдалану бер яктан укыту эшен кызыклырак һәм файдалырак итсә, икенче яктан, ул укытучыга тагын да ныграк җаваплылык өсти, аның тирән белемле булуын да таләп итә. Без, татар теле укытучылары, ана телебезнең киләчәк язмышы өчен җаваплы, тормыштан артта калырга безнең хакыбыз юк. Һәрчак иң алдынгылар рәтендә булганда гына укучыларыбыз каршында абруебыз артыр. Моның өчен өр-яңа белем бирү технологияләреннән хәбәрдар булырга, алардан файдаланырга, бер-беребезнең эшен күзәтергә һәм тәҗрибә уртаклашырга тиешбез. Мондый мөмкинлекләр бар. Без шәхси сайтларыбызны төзеп, аның ярдәмендә дә мәгарифне үстерүгә зур өлеш кертә алабыз.

Беркемгә дә сер түгел, шәхси сайтлар белем бирү системасының алыштыргысыз чыганакларына әйләнә баралар. Бу өлкәдә актив эшләүче буларак, мин үземнең тәҗрибәм белән уртаклашырга телим.

Шәхси сайт төзү идеясе миңа 2008 елда килде. Аның сәбәпләре бик гади иде. Мәгариф системасында озак еллар эшләү дәверендә шактый тәҗрибә тупланган булып чыкты. Белем бирү өчен кирәк булган төрле методик материаллар, укучылар белән эшләнгән фәнни хезмәтләр, имтиханга һәм олимпиадаларга әзерләнү өчен кирәкле ресурслар, ачык дәрес планнары, лексик һәм грамматик материаллар һәм әдәби әсәрләргә анализ ясау үрнәкләре h.б. бик күп файдалы материалларны эшсез яткыру, күпьеллык тәҗрибә белән уртаклашмау булган байлыкны күмеп куюга тиң булыр иде. Яшь укытучыларга булышу теләге дә көчле булды, чөнки алар әледән-әле ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Тупланган материалларны «Мәгариф» журналында бастырып бетерү дә мөмкин түгел. Мин үземнең сайтымны төзергә булдым.

Сайтны төзеп кую белән генә эш бетми бит әле. Аны даими тулыландырып тору кирәклеген һәм бу эшнең бик күп вакыт таләп итүен дә аңлыйм, тик куйган максатыма ирешергә теләү омтылышы бик көчле иде. Мәктәптә белем бирүдән тыш сайт аша да бу эшне дәвам итәргә мөмкин булуына үзем дә, башкалар да тиз төшендек. Иң әһәмиятлесе – материалларның саф татар телендә булуы һәм дөрес языл уы. Сайтка урнаштырылган һәр мәгълүмат файда китерергә тиеш. Бу сайтның төп кредосына әйләнде.

tarkhanova.ru сайтында бүгенге көндә өч йөзләп ресурс тупланган. Аның «Хезмәтләрем», «Фәнни хезмәтләр», «Ачык дәрескә», «Асыл сүз», «Сандык», «Галерея», «Тормыш мәктәбе», «Видео» исемле бүлекләре уңышлы эшләп килә. Укытучылар тарафыннан иң күп файдаланыла торган материаллар – 1-11 сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбияты буенча татар һәм рус төркемнәре өчен эш программалары, дәрес эшкәртмәләре (конспектлар) һәм методик материаллар булса, укучыларны исә имтиханга һәм олимпиадаларга әзерләнү материаллары, тестлар, сочинение үрнәкләре кызыксындыра.

XVIII, XIX, XX гасырлар әдәбиятыннан өйрәнелә торган иң әһәмиятле темаларны яктырткан дәрес планнарының берничәсен санап узам: «Идегәй» дастанын анализлау», «Татар әдәбиятының үсеш үзенчәлекләре», «М. Колый иҗатына күзәтү ясау», «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән», «Дәрдемәнд

– шагыйрь, философ», «Ә. Еники әсәрләрендә кешенең күңел дөньясын сурәтләү», «Ф. Хөснинең «Сөйләнмәгән хикәя» әсәрен анализлау», «И. Юзеевның «Бакчачы турында баллада» әсәренә анализ ясау» – h.б. әдәби кыйммәткә ия ресурслар.

Дәрестән тыш чаралар белем бирү һәм тәрбия максатларын күздә тотып оештырыла. Шуны истә тотып язылган «Кирәкми безгә сугыш» инсценировкасы, «Ирекнең иреккә омтылуы» исемле балалар өчен язылган пьеса, «Акыллылар көч сынаша» темасына әдәби бәйге дә сайтта урын алды.

«Аналарны рәнҗетмәгез», «Гайбәтченең гомере кыска була», «Оҗмах капкасы кемгә ачыла», «Шомырт чәчкәседәй саф мәхәббәт» мәкаләләре тәрбия сәгатьләрендә куллану өчен актуаль материаллардан санала.

Рефератларга килгәндә, аларның сайтта иң сирәк очрый торганнары тупланган. Идел болгары ханнары турында, Мөхәммәдьяр, Ф. Әмирхан, А. Алиш, М. Мәһдиев h.б. күренекле шәхесләр иҗатына багышланганнарына сорау зур. Бу рефератлардан укучылар әдәби әсәрләр өйрәнгәндә файдалана.

Соңгы елларда бик күп публицистик мәкаләләр иҗат иттем. Алар бар да «Хезмәтләрем» һәм «Асыл сүз» бүлекләрендә урын алды. Туфан Миңнуллин, Мансур Гыйләҗев, Данил Салихов h.б. авторларның пьесалары буенча куелган спектакльләрне анализлауга багышланган мәкаләләр, Г. Исхакый әсәрләрен халкыбызга кайтаруда башлап йөрүче күренекле шәхесләребезнең берсе – Лена Гайнанова һәм милләтебезгә Тукайның биш томлыгын төзеп биргән Рәшат Гайнановка багышланган публицистик язмалар меңәрләгән укучылар тарафыннан укылды, югары бәяләнде.

Сөембикә ханбикәгә яла ягарга теләгән кайбер авторларның ялганын фаш итеп язылган «Алтынга нәҗес ябышмас» һәм «Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә» (Ярославна һәм Сөембикә елавы турында) мәкаләләре, тарихи һәм әдәби кыйммәткә ия булу сәбәпле, үзебездә генә түгел, Төркиядә һәм башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан да бик җылы кабул ителде. Татар милләтенең яшәеш үзенчәлекләренә һәм катнаш никахка багышланган күләмле мәкаләләремнән укытучылар әдәбият укытканда еш файдалана. Барлык публицистик хезмәтләрем дә иң элек «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыктылар.

Хикәяләр һәм кыска күләмле тормышчан мәкаләләремне, күзәтүләрдән чыгып язган юморескаларны, шулай ук Х. Туфан һәм Л. Салиәскәровага багышланган «Мәхәббәт ядкаре», илдәге аерым күренешләрне тәнкыйтьләп язган «Шүрәлеләр илендә», ханнар яшәгән чорны чагылдырган «Ширзад белән Гөлшад» пьесаларым сайтта урын алды. Шулай итеп, бер яктан сайт белем бирүдә файдаланыла торган методик журналны хәтерләтсә, икенче яктан, ул әдәби-нәфис һәм иҗтимагый журналга да бик якын тора. Аерма аның интернет форматта булуында гына. Бу – күп санлы файдаланучыларымның фикере. Сайтның күпкырлы юнәлештә эшли башлавы аны кулланучыларның нинди материаллар күрергә теләвенә бәйле рәвештә килеп чыкты.

«Видео» бүлегенә килсәк, анда дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда кулланыла торган әһәмиятле бер материалны әйтеп китәргә була. Габдулла

Тукайның тормышын һәм аның балалар өчен язган әсәрләрен өйрәнгәндә, укытучылар «Тукайлы балачак» фильмын кулланалар. Күп укытучылар аны эш программаларына да керткәннәр. Мин моны аларның рөхсәт сорап мөрәҗәгать итүләреннән беләм. Укучылар һәм татар теле укытучыларыннан тыш башлангыч мәктәптә дә бу материаллардан бик теләп файдаланалар.

«Тормыш мәктәбе» бүлегендә аерым язмалар рәвешендә чыга торган тәрбияви мәкаләләр, язмалар да көтеп алына. Соңгы вакытларда универсиада турында, парламент дәресләре өчен, телебезнең чисталыгын саклауга багышланган мәкаләләр, Илдар Хановның Аракчинода төзелгән Галәм храмы турындагы язмалар да укучыларда кызыксыну уятты. «Вконтакте», «Фейсбук»та аралашканда бик күпләр сайт материаллары турында фикерләрен калдыра, күбрәк ниләр белән кызыксынулары һәм тагын нинди материаллар күрергә теләүләре турында яза. Шунысы кызыклы, сайтта кайсы материалның күпме файдаланылуын даими күзәтеп барырга мөмкин. Статистикага килгәндә, шундый нәтиҗәләр ясап була: 2009 елдан алып бүгенге көнгә кадәр сайтка керүчеләр саны – 53 меңнән, ә барлык йөкләүләр, ягъни материалларны алу саны 104 меңнән артып китте. Татарстаннан тыш, Россиянең төрле регионнарында, Себердә, Украина, Казахстан һәм башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез сайт материалларыннан иң еш файдаланучылар булып торалар. Америкада, Төркиядә, Германия һәм Финляндиядә яшәүче татарлар да актив кулланучылар рәтендә. Аларны күбрәк татар тарихына, милләтебез тормышына багышланган язмалар кызыксындыра. Кулланучыларымның үтенечен исәпкә алып, кайбер материалларны латин графикасына күчерә башлаган идем, тик вакыт җитмәү сәбәпле, бу эшне әле киң җәелдереп җибәреп булмый.

Укучыларым күп төрле. Мәктәптә укучы балалар да, укытучылар һәм башка төрле өлкәдә эшләүчеләр дә үзләре теләгән материалларны урнаштыруымны сорап еш мөрәҗәгать итәләр. Кулымнан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышам. Минем сайттан файдалану бушлай. Иң әһәмиятле материалларым тупланган бүлекләргә дә барлык теләүчеләр дә керә һәм ирекле файдалана ала, чөнки сайтны төзүемнең төп максаты да укытучыларга методик ярдәм күрсәтү, әдәби-тарихи материаллар ярдәмендә эстетик-этик тәрбия бирү иде. Гомумән, кулланучылар өчен сайтның файдасы зур икәнлегенә көннән-көн ныграк ышана барам.

Үзләренең шәхси сайтларын ясарга теләүче укытучылар тагын да күбәер. Һәр укытучы үз тәҗрибәсе, иҗади хезмәтләре, уйланулары һәм табышлары белән уртаклашканда гына, безнең мәгариф системасы алга таба үсәр. Сайт ясаудан куркып торырга ярамый. Күз курка – кул эшли, диләр.

Гомуми нәтиҗә ясап, шуны әйтергә телим, үз сайтың булган очракта, бер генә материалың да эзсез югалмый, ул күпләргә файда китерә ала. Материалны файдаланган очракта, аның кайдан алынуына искәрмә ясарга кирәк, чөнки моны этика нормалары таләп итә. Минем сайтым, беренчедән, тәҗрибәмне туплау урыны булып торса, икенчедән, дәрестән тыш вакытта укучыларым белән аралашу мәйданчыгы ролен дә үти. Тагын бер файдалы ягы шунда, үзем

язган әдәби-публицистик әсәрләремне мин иң элек сайтымны кулланучылар хөкеменә тапшырам, яхшы фикерләрне дә, тәнкыйтьне дә бердәй кабул итеп алам. Шуннан соң гына газета укучылар игътибарына тәкъдим итәм. Гомумән, укыту-тәрбия эшендә мондый эшчәнлек бик тә отышлы. Сайтлардан оста файдалану укучыга тирән һәм файдалы мәгълүматны җиңел табарга мөмкинлек бирә.

«ТНВ-Планета» - халыкара иярчен мәйданында татар каналы

М.Х.Фатыйхова, КФУ укытучысы,
филология фәннәре кандидаты

Татарстанда телевидениенең барлыкка килүе һәм үсүе мәгълүмат тарату өлкәсендә генә түгел, ә республиканың барлык тормышында чын мәгънәсендә революцион вакыйга була. Ул берничә этаптан тора: Татарстан телевидениесенең Студия буларак эшчәнлеге - 1955-59 еллар; Дәүләт телевизион үзәгененең эшли башлау чоры - 1959-70 еллар; Татарстан дәүләт телевидениесе структурасының техник җиһазлар белән тәэмин ителү һәм үсеш чоры - 1970-1985 еллар; 1990-2000 еллар - милли күтәрелеш чоры, яңа форматтагы тапшырулар. 2002 елның 26 августында «Татарстан - Яңа гасыр» каналына нигез салынды.

Татарстан җитәкчелегенең соңгы елларда татарлар яшәгән илләрдә еш кына эшлекле очрашулар үткәрүе, аларның тәкъдимнәрен тыңлау бөтендөнья татарларын берләштерүче, хәбәри чыганак булырлык гаммәви мәгълүмат чарасы кирәклеген ассызыклады. Мәсәлән, Президент Рөстәм Миңнеханов соңгы елларда Австралия, Польша, Санкт Петербург, Мәскәү татарлары һ.б. төбәкләрдә яшәгән татарлар белән җирле милли-мәдәни мохтәриятләрендә очрашты. Шулар нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында 2012 елның 15 нче июненнән «ТНВ-Планета» каналына нигез салынды. 30 нчы августтан канал планлы рәвештә эшли башлады. Россия гаммәви мәгълүмат чаралары да бу вакыйгага үз бәясен бирде. «Татарстан Республикасы «ТНВ-Планета» каналын сынау чорына кереште, шул рәвешчә Рәсәй автономиясен халыкара спутник мәйданында тәкъдим итәчәк...»[1].

«ТНВ-Планета» – Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә, БДБ илләрендә, чит төбәкләрдә гомер кичерүче, Татарстанны тарихи ватан дип санаучы күпсанлы милләттәшләребезне берләштерүче мәдәни-мәгърифәтче иярчен телеканалы булып санала. «ТНВ-Планета» телеканалының максаты – Россия һәм дөнья күләмендә Татарстан республикасын таныту. «ТНВ-Планета» телеканалы ачык режимда ABS иярчене ярдәмендә кабул ителә. Аны «НТВ-плюс» («База» пакеты), «Триколор ТВ» («Оптимум» пакеты) абонентлары карый ала. «ТНВ-Планета» телеканалын он-лайн режимда интернетта да карарга мөмкин.

Яңа канал беренче адымнарын «Татарстан-Яңа гасыр» җирлегендә ясый. Әлегә иярчен ресурслары җитешми. Ләкин киләчәктә «ТНВ-Планета» каналы Россиянең «Культура» каналы шикелле мөстәкыйль булыр дип көтелә.

«ТНВ-Планета» каналы тәүлек буе эшли. Телевизион программа 8 сәгатьлек өч бүленешкә нигезләнгән. Беренче өлештә хәбәрләр тәкъдим ителә. Икенчесе - балалар өчен. Бу бүленештә тапшырулар фәкать татар телендә генә әзерләнә. Татарча мультфильмнар, әкиятләргә киң урын бирелә. Өченче - музыкаль-әдәби өлештә исә сәнгать кичәләре, концерт-тамашалар, спектакльләр карарга мөмкин.

Россия төбәкләрендә һәм башка илләрдә гомер итүче кардәшләребезнең мәдәни, әдәби тапшыруларга, татар телендәге концертларга, спектакльләргә өстенлек бирүе табигый. Моңа аларның интернет аша җиткергән хатлары да ачык дәлил. Татар Конгрессы тарафыннан үткәрелгән соңгы съездда да бу хакта бик күп әйтелде. Бөтендөнья Татар Конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров сүзләренчә, әлеге каналның максаты, беренче чиратта, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең татар теленә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү, аннан соң – Татарстанның рухи-мәдәни байлыгын җиткерү. Сигез сәгатьлек бүленеш шушы тәкъдимне истә тотып төзелгән.

«Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры Илшат Әминов сүзләренә караганда, бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләре буенча Россиядә 5,5 миллион татар яши. Аларның якынча 1 миллионы татар телен начар белә. Тапшырулар челтәрен төзегәндә, бу үзенчәлекләр дә исәпкә алынган. Шуңа күрә кайбер тапшырулар махсус рус телендә эшләнә. Мәсәлән, хәбәрләр җиткерүче тапшыру ике телдә дә «Яңалыклар» буларак та, «Новости» итеп тә рус телендә күрсәтелә.

Хәзерге көндә «Татарстан-Яңа гасыр» һәм «ТНВ-Планета» каналларының потенциаль аудиториясе 50 миллион кеше дип фараз ителә [2].

«ТНВ-Планета»ның аерым игътибарга лаек яңа проекты «Татарча сөйләшәм» дип атала. Алып баручысы Илсур Нәфыйков. Һәр тапшыру аерым бер темага багышлана. Мәсәлән – театрга бару. Ул темага кагылышлы сүзләрне берьюлы өч телдә: татар, рус һәм инглиз телендә аңлата. Бу тапшыру «Татарлар» чыгарылышының бер сәхифәсе буларак күрсәтелә.

Хәбәрләр тапшыруы татар телендә «Яңалыклар» һәм рус телендә «Новости» буларак биреп барылса да, бер-берсен сүзгә-сүз кабатламый. Икесендә дә бер үк темалар, әмма ул турыдан-туры тәрҗемә, дубляж түгел. Вакыйгалар корреспондентларның иҗат үзенчәлегенә бәйле рәвештә яктыртыла.

Нигездә яңа каналның тапшырулар челтәрен «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе журналистлары тарафыннан әзерләнгән шул ук тапшырулар тәшкил итә.

«Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе архивыннан «Ватандашлар» дигән цикл күрсәтелә, ә ул 100 сериядән тора, «Яшәсен театр!» циклы, «Халкым минем» тапшыруы да яңадан беренче сериясеннән башлап күрсәтелде. Болары нәкъ менә чит төбәктә яшәүче татарлар өчен фондтан

алынган махсус тапшырулар. Ә өр-яңа тапшыру буларак «Яңалыклар» һәм «Татарлар» тапшыруларын атый алабыз. Алар каналның нигезләмәсен әзерләгәндә үк барлыкка килгән төп тапшырулар.

«Яңалыклар-Новости» тапшыруларының баш мөхәррире Радик Фәрхуллин әйтүенчә, гомумән бу канал республикадан читтә яшәүчеләрне бары тик позитив яңалыклар белән генә таныштырырга тырыша.

«Яңалыклар» тапшыруын дүрт корреспондент әзерли. Радик Гыймаев, Люция Нотфуллина, Наилә Һидиятова, Рания Садыйкова. Шулай ук аларга «Татарстан-Яңа Гасыр» телевидениесенең корпунктларында эшләүче журналистлар ярдәм итә. Мәскәүдән, мәсәлән, Динә Газалеева, Уфадан Фәнис Фәтхи, Сембердән Рәмис Сафин. Андый хәбәрчеләр тагын Екатеринбург, Ижау, Төмән шәһәрләрендә дә бар.

«Татарлар» тапшыруын чынлыкта өр-яңа дип атап булмый, аның беренче варианты Татарстан халкы өчен Флюра Абдуллина тарафыннан әзерләнде. 2013 елның 8 апреленнән «Татарстан-Яңа Гасыр» каналында чыгучы бу тапшыру ябылды. Әлбәттә аны башка төрле исем астында бирергә дә мөмкин булыр иде. Тапшыруның яңа мөхәррире һәм алып баручысы Раил Өметбаев фикеренчә, «Татарлар» тапшырулары бер-берсен кабатламады. Чыннан да юнәлешләре бер булса да темалар төрле яссылыкта яктыртылды, Флюра Абдуллина күбрәк җирле яңалыклар турында күрсәтте, ә яңасында чит төбәктә яшәүче татарларның кайда гына яшәүләренә карамастан, материаллар шунда барып әзерләнә. Мәсәлән: «*Инде менә бер ай дәвамында без сезне Төркиядәге татар авыллары белән таныштырабыз. Бүген без сезне тагын бер салага чакырабыз. Исеме – Гүрсү. Илнең иң көньягында – Измир якларында урнашкан ул. Биредә яшәүче милләттәшләребез йөзем үстерү белән көн күрә. Хәзер барысын да үз күзләрегез белән күрәчәксез*». Алып баручы тамашачыга кайсы илләргә сәфәрләре һәм андагы вакыйгалар белән тапшыруның анонс өлешендә үк хәбәр итә [3]. Татар диаспорасы, гомумән читтә туып-үскән, читтә яшәгән татарлар турында хәбәрләрне, яңа китапларның тәкъдир ителүләрен, мәдәният, әдәбият, җәмәгать эшлеклеләренең тормышын, татар җыры фестивальләре, татар көрәше чемпионаты, Сабан туе кебек милли бәйрәмнәрне – «Яңалыклар» һәм «Татарлар» тапшырулары тамашачыга бик мул җиткерә.

Яңалыклар хезмәте җитәкчесенең эшчәнлеге дә гаять мөһим. Ул журналистлар алдында, тамашачы алдында да, эфирда күрсәтелүче мәгълүмат өчен дә җаваплы. Нинди яңалыклар экранга барасын ул хәл итә. Радик Фәрхуллин «Яңалыклар» яки «Новости» тапшыруларын туплаганда, «Татарстан-Яңа Гасыр» хәбәрләр редакциясендә эшләүчеләрнең сюжетларын да куллана. «Татарстан хәбәрләре»ндә эшләүче һәрбер корреспондентның даими рәвештә «Яңалыклар»да материалы күрсәтелә. Кайбер очракта алар үз сюжетларын «ТНВ-Планета» өчен махсус әзерли яисә Татарстан тамашачысы өчен күрсәткән сюжетына үзгәрешләр кертә.

«ТНВ-Планета» каналында «Яңалыклар» тапшыруының тематикасы нигездә чит төбәктә яшәүче татар аудиториясен күз алдында тотып сайлана. Әмма Татарстанда булган вакыйгаларга да шактый урын бирелә. Мәсәлән, 12

декабрьдә эфирга чыккан тапшыруда бер сюжет Татарстан делегациясенең Алтай республикасына визиты турында булса, Бөгелмә, Түбән Кама, Алабуга шәһәр, районнарыннан төшерелеп күрсәтелде [4].

«Яңалыклар»ның көндезге чыгарылышы белән кичкесендә зур аерма бар дип әйтеп булмый. Мәсәлән 11 гыйнварда көндезге өчтә күрсәтелгән хәбәрләр чыгарылышында Татарстан Республикасының Фәннәр Академиясе Президенты Әхмәт Мазһаров, Казан галиме Марат Идрисовнең яңа асфальт составын уйлап чыгаруы, Универсиада өчен чәчәк бәйләменә гаризалар кабул итү, Болактагы театр, Уфа музыка мәктәбендә бәйрәм, Әлмәттә мемориаль такта ачылу, «Урал сандугачы» бәйгесе турында хәбәрләр белән таныштырдылар, ә кичке алтыдагы чыгарылышта Рөстәм Миңнехановның «Роснано» җәмгыятенең гуманитар проектлар буенча директоры Леонид Гозман белән очрашуы, спорт күзәтүе һәм Свердловск өлкәсендә татар мәктәпләрен яңа әсбап һәм кулланма әдәбият белән тәэмин ителәчәге турында өстәмә сюжетлар күрсәтелде [5]. Чит төбәкләрдә яшәүче татарларның кайберләре туган телләрен белми, шул сәбәпле аларның сөйләме «Яңалыклар» тапшыруында тәрҗемә итеп бирелә. Моның өчен рус яисә инглиз теленнән тәрҗемәләр титр (йөгерек юллар) ярдәмендә язып барыла.

«Яңалыклар» тапшыруларын күзәтеп барганда, шунысы да игътибарга лаек, анда нигездә уңай хәбәр-вакыйгалар күрсәтелә, тәнкыйди, зур проблемалы мәсьәләләр хакында бәян иткән материаллар юк диярлек.

«ТНВ-Планета» каналы әле яңа тернәкләнеп килә. Үз тарихы языла гына башласа да каналның планнары зурдан. Татар тарихы турында программалар әзерләү, документаль фильмнар төшерү, татар әдипләре әсәрләре нигезендә татарча мультфильмнар эшләү киләчәктә чынга ашырыласы максатларның кайберләре генә.

Чыганаклар

1. «ТНВ - Планета» / URL: http://sat.uz/broadcasting/11113-test-tnv-planeta.html (Мөрәҗәгать итү датасы: 15.02.2013)

2. Завалишина Т. Ильшат Аминов: «Убить Билла» Тарантино не появится на ТНВ» // Бизнес ОНЛАЙН / URL: http://www.business-gazeta.ru/article/75579/ (Мөрәҗәгать итү датасы: 15.04.2013)

3. «Татарлар». ТНВ-Планета. 2013. 23 гыйнв. 11 сәг. 10 мин.

4. «Яңалыклар». «ТНВ-Планета». 2012. 12 дек. 15 сәг. 00 мин.

5. «Яңалыклар». «ТНВ-Планета». 2013. 11 гыйнв. 15 сәг. 00 мин.,18 сәг. 00 мин.

ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫНДА МӘГАРИФ БАСМАЛАРЫНЫҢ ҮСЕШЕ

Татарстанда фән-мәгариф буенча махсуслашкан гаммәви мәгълүмат чаралары

А.Ф.Галиәхмәтова, КФУ укытучысы,
филология фәннәре кандидаты

Татарстанда бүген фәнни, белем бирү өлкәсенә караган 53 гаммәви мәгълүмат чарасы (алга таба – ГМЧ) теркәлгән. Бу сан – үзләрен белем бирү юнәлешендә эшли дип саный торган ГМЧ саны. Әлеге төр мәгълүмат чараларының үзләрен (таралу формасын исәпкә алмыйча гына) берничә төргә бүләргә мөмкин: фәнни, фәнни-гамәли, фәнни-популяр, һөнәри [1, с.89]. М.Шкондин, эшчәнлек төренә карап, башка төрлерәк бүленеш тәкъдим итә: фәнни-теоретик, фәнни-техник, фәнни-произдводстсво, фәнни-гамәли, фәнни-популяр, фәнни-методик, фәнни-мәгълүмати (фәнни-рефератив) [1, с.21]. Татарстанда белем бирү юнәлешендә эшли торган ГМЧның күп өлеше уку йортлары тарафыннан чыгарыла һәм аларда фәнни-теоретик, фәнни-рефератив төрләр өстенлек итә. Алар исәбенә «Вестник ТИСБИ» (үзен фәнни мәгълүмати басма дип атый һәм фән, мәгариф, икътисад, юриспруденция h.б. өлкәләрдә мәкаләләр бирә), «Казанский социально-гуманитарный вестник» (мәгълүмати фәнни-аналитик журнал дип атала), «Казанская наука» басмалары керә. Төрле уку йортларының «хәбәрләре» (вестник) дип аталган башка гаммәви мәгълүмат чараларын да шушы төргә кертеп карарга мөмкин. «Современное искусство медицины» журналы үзен фәнни-гамәли басмалар исәбенә кертә. Фәнни-җитештерү басмаларына мисал итеп «Ветеринарный вестник», «Агрокультура» газеталарын китерергә була. Уку йортларының көндәлек тормышын чагылдырган «Дарелфөнүн», «Педагог и престиж», «Экономист», «Технологический университет» кебек газеталар шул уку йортларындагы аудиториягә юнәлдерелгән ГМЧ булып кала.

Фән-мәгариф өлкәсенә караган һөнәри гаммәви мәгълүмат чараларына килсәк, алар мәгариф хезмәткәрләрен әзерләүчеләргә, мәгариф хезмәткәрләренә һәм ата-аналарга атап чыгарыла. Әйтик, элек-электән чыгып килгән, бөтен Россия буенча тарала торган «Учительская газета», «Начальная школа» укытучылар өчен булса, «Семья и школа» журналы укытучылар һәм әти-әниләр өчен чыгарыла иде. Үзебезнең җирлеккә күчереп карасак, укытучыларның укытучылары өчен чыга торган басмаларга «Казанский педагогический журнал», «Фән һәм тел», «Образование и саморазвитие» журналларын кертергә мөмкин. Укытучылар өчен фәнни-методик «Мәгариф», «Фән һәм мәктәп», «Экология в школе», «Библиотека непрерывного экологического образования» журналлары, «Ачык дәрес», «Открытый урок», «Уроки и мероприятия» газеталары чыгарыла. Әти-әниләр өчен адресланган басмалардан «Гаилә һәм мәктәп» журналын гына атарга мөмкин.

Әлеге гаммәви мәгълүмат чараларына аерым тукталганчы, аларның чишмә башында торган, XX гасыр башында нәшер ителгән тәрбияви-педагогик басмаларны телгә алу урынлы булыр. Тәрбияви басмаларның тарихы 1908 нче

елдан – «Тәрбия» журналы нәшер ителә башлаган көннән санала. «Тәрбия», «Мөгаллим», «Мәктәп» журналларының библиографик күрсәткече Р.Мәрданов һәм И.Галләмов тарафынан эшләнеп, 1997 елда басылып чыккан иде [2].

Шуларның беренчесе – «Тәрбия» журналының 1908 елның февраленнән апреленә кадәр бары тик 4 кенә саны чыгып калган. Тышлыгына «Казанда ун биш көнгә бер нәшер улыныр, тәгълим вә тәрбиядән бер мәҗәлләдер» дип язылган. Басмада мәгариф, педагогика, әдәбият-сәнгать, төрле фәннәр (әйтик, медицина, табигать белеме) һ.б. өлкәләргә кагылышлы материаллар дөнья күргән.

Тагын бер педагогик журнал – Оренбургта 1913-14 елларда нәшер ителгән «Мөгаллим» журналы. И.Рәмиев аны «демократик юнәлештәге уку-укыту һәм тәрбия журналы» дип атый. Ике атнага бер тапкыр чыккан әлеге басмада (барлыгы тугыз сан) мәктәп-мәдрәсәләр тормышы (беренче санында ук «Мөгаллим» үзенең татар мәктәпләре турында мәгълүмат туплавы хакында җиткерә), укыту методикалары, мөгаллимнәрнең хәле, әдәбият, тел мәсьәләләре хакында яза, бик аз гына булса да, әдәби әсәрләргә дә (шигырьләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре) урын бирә. Журналның үзендә хәбәр ителгәнчә, «Мөгалим»дә тәгаллем һәм тәрбия бүлмәсе, әдәби бүлмә, фәнни бүлмә булырга тиеш. Беренчесендә гаилә һәм мәктәп тәрбиясе, мәктәпкәчә тәрбия, мәктәп-мәдрәсәләрдә ислах, педагогия һәм мәктәпләр тарихы – барысы 12 баб каралган, ул журналның иң күләмле бүлмәсе булып тора. Икенчесендә тел вә әдәбият, имла, язу мәсьәләсе, әдәби әсәрләр биреләчәге хәбәр ителә. Фәнни бүлмәдә табигать белеме, тарих, география, этнография, мантыйк кебек фәннәр һәм мәктәп-мәдрәсәләр эшенә тәнкыйть тә каралачак, диелгән.

Журналның таралу географиясе шактый киң булган: хәбәр ителгәнчә, язылу пунктлары Россиянең төрле почмакларында - Чиләбедә, Ташкентта, Харьковта, Уфада, Мәскәүдә, Касыймда һ.б. Дөнья күргән материалларга карасаң да, редакция күп шәһәрләр белән элемтәдә торган: Чистай, Әстерхан, Петербург, Җаек, Иртыш буендагы мәктәп-мәдрәсәләр турында мәгълүмат табарга мөмкин. Бу басма да 9 сан чыгу белән чикләнә, уку елы дәвамында чыгарлык булып планлаштырылган журнал икенче уку елында дөнья күрә алмый.

Педагогик журналларның өченчесе – «Мәктәп» журналы, күләме ягыннан да, эчтәлеге ягынанан да баерак, гомере дә озынрак – аның 25 саны дөнья күрә. («Мөгаллим»нең бибилиографик күрсәткечендә 138 берәмлек күрсәтелсә, «Мәктәп»тә басылган материаллар саны 231 не тәшкил итә.) Мәктәп 1913 нче елның февраленнән 1914 елның октябренә кадәр Шиһаб Әхмәров мөхәррирлегендә чыккан. Күтәргән темалары: укыту-тәрбия, мәктәптә укытыла торган фәннәр, аларның программалары, мәктәп-мәдрәсәләр тарихы, һөнәри мәктәпләр, чит илләрдәге мәктәпләр, хатын-кыз мәгарифе, татарча-русча укыту мәсьәләләре һ.б. Шулай ук иҗтимагый-сәяси тормыш та читтә калмаган, дин мәсьәләләре дә күтәрелгән. Авторлары арасында дин галимнәре, пелагоглар, әдипләр, мөгаллимнәр, рус-татар мәктәпләре укытучылары булган. Әйтик, Г.Исхакый, Һ.Атласи, М.Корбангалиев, М.Акчурина, Ф.Агиев һ.б. Әдәби

әсәрләр аз, ара-тирә Г.Тукай, С.Сүнчәләй шигырьләре очрый – бусы журналның юнәлеше белән бәйле.

Тагын бер журнал турында – Әстерханда нәшер ителгән «Мәгариф» турында да әйтеп китү урынлы булыр. Әлеге журнал, И.Рәмиев язуына караганда, 1909 нчы елда уку-укыту һәм дини әхлак журналы буларак, мулла Габдрахман Галиев тарафыннан нәшер ителә башлый (мөхәррире М.Рәхимкулов). Алучылары аз булу сәбәпле, 1910 елда да берничә саны чыгып, туктый [3].

Бүгенге «Мәгариф»нең бабасы – «Мәгариф» журналы 1918 нче елның ноябрендә Казанда Мәркәз мөселман комиссариаты янындагы «Гыйльми һәйят» органы буларак чыга башлый. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире Г.Ибраһимов була, мөселман мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев аңа ярдәм итә. Журналның беренче санында язылганча, рәсми, тәрбияви, әдәби, фәнни бүлекләрдән тора. Мәктәпне тормышка якынайту, «Гыйльми һәйят»нең чыгышлары, эшләре белән таныштыру, мәктәпкәчә тәрбия, мәктәптән соң тәрбия, гомумән, уку-укыту эшләренә багышланган мәсьәләләргә киң урын биреләчәк, диелә.

Революциягә кадәр чыккан басмаларда беренче урында милли мәгариф булса, яңа басмадан революцион, интернациональ рух бөркелеп тора. Хөкүмәтнең мәгариф, мәдәният өлкәсенә караган декретлары, положениеләре басыла. Рус журналларыннан материаллар тәрҗемә итеп бирелә, укыту программалары татар мәктәпләре өчен яраклаштырып тәрҗемә ителә. Өч саны чыккач, гражданнар сугышы белән бәйле рәвештә журнал эшен туктатып тора, 1921 елда кабаттан басыла башлый. Эш юнәлешләре конкретлаша: мәгариф комиссариаты чыгарган декретлар, инструкцияләр; гыйльми-фәнни һәм әдәби мәсьәләләр, мәктәпкә кадәр, мәктәптә һәм мәктәптән тыш тәрбия; мәгариф турында хәбәрләр һәм урыннардан килгән хәбәрләр; мәгариф комиссариаты эшләре; мәгариф хадимнәренең тәрҗемәи хәлләре; яңа китаплар белән таныштыру. Журнал мәгариф өлкәсен генә түгел, мәдәният өлкәсен дә колачлый. Соңрак «Башлангыч мәктәп», «Совет мәктәбе» исемнәрен йөртеп, бүгенге көнгә кадәр килеп җитә. Чорына карап, укыту-тәрбия проблемаларына караганда, идеология күбрәк урын алып торса да, асылда, укытучыларга хезмәт итә торган бердәнбер журнал булып кала бирде.

XX гасырның 90 нчы елларындагы күтәрелеш белән бәйле рәвештә, татар теленә игътибар арту нәтиҗәсендә, югары уку йортларында татар бүлекләре булдырылды, бу күренеш югары мәктәпләрдә татар теленең үсешенә юл ачты. Шуның белән бәйле рәвештә, татарча фәнни басмалар да чыга башлады. «Фән һәм тел» журналы – шундыйлардан. Архитектура-төзелеш университетында 1999 елдан чыга торган әлеге басманың төп максаты – фәндә һәм мәгарифтә татар теленең потенциалын куллану, татар телендә фәнни мәгълүмат туплау, мәшһүр татар галимнәренең казанышларын популярлаштыру һәм әсәрләре белән татар халкын таныштыру. Төп рубрикалары – «Тел, әдәбият һәм тарих»; «Милли мәгариф»; «Фән һәм гамәл»; «Фәнгә - хәбәр»; «Китап киштәсе».

Алда әйтеп үтелгән, рус телендә чыга торган «Казанский педагогический журнал» (1995 елдан «Профессиональное образование» исемен йөртә) белән «Образование и саморазвитие» журналлары шулай ук югары уку йортлары тарафынан чыгарылып (оештыручылары – ИППО РАО, АСО һәм КПФУ), фәнни педагогия-психология журналлары дип аталалар. Беренчесендә педагогика һәм психология дип аталган ике бүлектә галимнәр, аспирантлар, укытучылар тарафыннан мәктәп, урта һәм югары һөнәри белем бирү йортларында укыту методикасы, тәрбия, уку йортларының тарихы һ.б. темалар күтәрелә. Журнал, мәктәптән бигрәк, урта һөнәри белем бирү йортлары өчен файдалы булса кирәк.

«Образование и сомразвитие» журналы КФУда 2006 елдан нәшер ителә башлады. Оештыручысы педагогика фәннәре докторы В.Андреев булган әлеге журнал үзенең миссиясен дөньякүләм фән-мәгариф киңлегенә интеграцияләнүдә күрә, Россия һәм чит ил экспертлары тарафыннан югары бәяләнгән нәтиҗәле педагогик-психологик эшләнмәләрне бастыра. Журналда соңгы вакытта мондыйрак бүлекләр эшли: педагогик психология һәм мәгариф проблемалары, шәхеснең һөнәри яктан белемен күтәрүе һәм үзен камилләштерүе, мәктәпкәчә белем бирүнең теория һәм практикасы, хәзерге заман мәктәбе проблемалары, укытучы-практик трибунасы, яшь галимнәр мөнбәре, өстәмә һөнәри белем, кафедра тәҗрибәсе, халыкара фәнни хезмәттәшлек, галимнәр турында. Бүлек исемнәре үзләре үк журналының эчтәлеген ачып сала, аерым материаллар турында сөйләп тору кирәкмәс.

Чаллы педагогия институтында чыга торган фәнни-методик «Фән һәм мәктәп» журналы укытучыларга күпкә якынрак. 1996 елдан чыга торган журналда галимнәр, педагогларның фәнни методик мәкаләләре, укытучыларга һәм тәрбиячеләргә көндәлек кирәк булган материаллар басыла. Журналда фән, укыту методикасы, укыту эчтәлеге, башлангыч мәктәп, тәрбия эше, мәктәпкәчә тәрбия бүлекләре эшли. Анда төрле фән укытучылары да, тәрбиячеләр дә, мәктәп психологлары да үзләренә файдалы материалны таба ала. Авторлар арасында галимнәр дә, укытучы-практиклар да бар. Кызганыч, кызыклы һәм файдалы журнал укучыларын таба алмаган: тиражы 1000 гә дә җитми.

Татарстан мәгариф халык комиссариаты журналы булып башланган «Мәгариф»нең рәсми яктан оештыручысы «Татмедиа» ААҖ дип билгеләнсә дә, асылда ул мәгариф министрлыгы органы булып кала, чөнки төп аудиториясе – укытучылар. Мәгариф министрлыгы чыгара торган «Вестник образования»дә норматив документлар, боерык, карар, хатлар, гомумән, мәктәпләрдәге эшне оештыруга кагылышлы мәгълүмат басылса, «Мәгариф» укытучының көндәлек эшендә кулланыла торган методик ярдәмлек булырга тиеш. Соңгы елларда журналда заман һәм мәгариф сәясәте, туган тел һәм әдәбият, рус һәм чит телләре, мәктәпкәчә тәрбия, башлангыч мәктәп һ.б. турындагы бүлекләр булып, аерым район һәм мәктәпләрнең эш тәҗрибәсенә багышланган сәхифәләр басылса, бу елның башыннан вак бүлекләр берләштерелеп, «Мәктәп һәм дәрес», «Тәрбия – белем нигезе», «Укытучыга ярдәмгә» дигән бүлекләр булдырылган. Бу отышлырак та, чөнки «Мәктәп һәм дәрес» бүлеге үз эченә

бөтен фәннәрне дә ала, вакланып торуның кирәге калмый. «Фән һәм мәктәп»нең «Фән – укыту методикасы – практика – мәктәпкәчә тәрбия» бүлекләре бирелешенә якынайган.

«Экология в школе», «Библиотека непрерывного экологического образования»журналлары 2007 елдан Әлмәттә И.Бакиров тарафыннан чыгарыла, таралу регионы – Россия Федерациясе. Дәрес эшкәртмәләре, класстан тыш эшләр, экологияне тирәннән өйрәнүчеләр өчен олимпиада сораулары – табигать фәннәрен укытучылар өчен бик әйбәт ярдәмлек булып тора. Әлеге басмаларда балалар бакчалары өчен дә, мәктәп, югары уку йортына керергә җыенучылар өчен дә материаллар табарга була. Аерым зат тарафыннан шундый басма нәшер ителү мактауга лаек. Физик затлар тарафыннан нәшер ителүче тагын ике басма – «Ачык дәрес. Мәктәп» (2003 нче елдан чыга), «Уроки и мероприятия» газетлары (оештыручысы - А.Латыйпова) айга бер мәртәбә чыгып, дәрес эшкәртмәләре, класстан тыш эшләр өчен сценарийлар бастыра. Беренчесе – А4 форматта 48 бит, икенче 16 бит булып чыга торган әлеге газеталар татар мәктәпләрендә укытучылар өчен методик ярдәмлек буларак нәшер ителә башлаган иде. Авторлар – республиканың төрле мәктәпләрендә укытучылар. «Открытый урок» газетасы да (оештыручысы – «Хәтер» нәшрияты) шундый ук юнәлештә эшли, Татарстан республикасы территориясендә тарала.

Алда саналган гаммәви мәгълүмат чараларыннан бары тик «Казанский педагогический журнал» һәм «Образование и саморазвитие» журналларының гына интернетта электрон вариантлары белән танышырга мөмкин. «Фән һәм мәктәп»нең сайтында журналның тышлык рәсеме һәм эчтәлеге эленеп тора, берничә матреиалны PDF форматында укырга мөмкин. Уңай тәҗрибә итеп, «Первое сентября» нәшриятының эш рәвешен китерергә мөмкин. Укытучы, теләгенә карап, газета-журналларның басма вариантына яки электрон вариантына язылырга мөмкин, шунда ук мәгариф өлкәсенә багышланган хәбәрләр белән таныша ала, ил күләмендә мәгариф өлкәсендә оештырыла торган конкурс-проектлардан хәбәрдар була ала. «Учительский журнал он лайн» сайтында бирелгән методик эшкәртмәләрне куллану өчен, теркәлү узарга кирәк. Дәрес эшкәртмәләре җибәргән укытучыларга сертификатлар юллана. Берникадәр үрнәк үзебездә дә бар – ул да булса, «Белем ру» порталы. ГМЧ мөмкинлекләре белән, әлеге порталдагы кебек үк үз фикереңне калдыру, аралашу мөмкинлеге дә булдырылса, хәзерге заманга муафыйк бер эш булыр иде.

Фән-мәгариф буенча махсуслашкан, югарыда телгә алынган басмаларның бер айлык тулаем тиражы (2013 елда) 17170 тән артмый. Республикабызда 36 мең укытучы, 19 мең тәрбияче эшләвен исәпкә алсак, тиражларны үстерерлек потенциаль аудитория барлыгын күрәбез. Гаммәви мәгълүмат чаралары укучыларны кызыксындырырлык, кызыклы итәр өчен ниләр эшләргә була соң?

Фән-мәгариф буенче махсуслашкан ГМЧ заманга туры килә торган, актуаль, киләчәкне күздә тотып эшләнгән хезмәтләргә өстенлек бирергә тиеш. Эчтәлекне яхшыртырга, моның өчен материалларны сайлап алу критерийларын

үзгәртергә кирәк. Гаммәви мәгълүмат чараларында конкурстан узып, сайланып алынган иң яхшы методик эшкәртмәләр генә басылырга тиеш. ГМЧның басма вариантларына өстәмә рәвештә электрон вариантны булдырып, параллель рәвештә алар белән эшләргә, аның интерактивлыгын тәэмин итәргә кирәк. ГМЧда катнашкан мәгариф хезмәткәрләренә сертификатлар бирү мөмкинлеге каралса да начар булмас иде.

Әдәбият

1. Типология периодической печати : Учеб. пособие для студентов вузов / М. Е. Аникина, В. В. Баранов, О. А. Воронова и др.; Под ред. М. В. Шкондина, Л. Л. Реснянской. М.: Аспект Пресс, 2009. 236 с.

2. XX гасыр башы тәгълим-тәрбия журналларының библиографик күрсәткече. Казан. Милли китап, 1997. 67 б.

3. Рәмиев И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. Казан. Татар. кит.нәшр., 2001. 399 б.

4. Йөз еллык матбугатыбыз. Үткәне, бүгенгесе, киләчәге (фәнни гамәли конференция материаллары). Казан. Казан ун-ты нәшр., 2005. 144 б.

Чыганаклар

Тәрбия. 1907.
Мөгаллим. 1913. №1, №2.
Мәктәп. 1913. №1
Мәгариф. 1921. № 1-6
Совет мәктәбе. 1968. №11.

«Ватаным Татарстан» газетасында мәгариф темасының куелышы

Р.М.Галиева, КФУ доценты,
филология фәннәре кандидаты

«Ватаным Татарстан» иҗтимагый-сәяси газетасының 95 еллык тарихы бар. Газета тарихның кайсы чорын яктыртса да, республика матбугатында мәгариф тематикасына һәрвакыт билгеле бер урын бирелде. Редакция штатында мәгариф һәм фән бүлеге эшләп килде. Уку-укытуда проблемалар, милли мәктәп-гимназияләр ачылу һәм татар телен укыту төп темаларның берсе булды. Соңгы егерме ел эчендә генә дә күп кенә публицистик язмалар, мәкалә-репортажлар әзерләнде. Бигрәк тә бүгенге вәзгыятьтә (мәктәп, югары уку йортларындагы реформаларны күздә тотканда) шактый күп проблемаларга ачыклык керткән, аларны чишүдә роль уйнаган язмалар басылып килә.

Милли мәктәп-гимназияләр ачу, милли университетны булдыру, ана телен укыту мәсьәләләренә дә газета күп язды. Бәхәс мәйданында журналистлар гына түгел, мәртәбәле белгечләр, иҗтимагый оешма вәкилләре

дә үз сүзен әйтергә ашыкты. Кайбер күтәрелгән мәсьәләләр газета битләрендә генә дә сакланып калды. Бүген без туксанынчы еллардагы кебек милли мәктәп-гимназияләр, милли университет өчен җан атмыйбыз. Татар теленең дәрес буларак укытылып калуы, сәгатьләр санын саклау турында гына сүз кузгатабыз. Милли мәгарифне үстерүдә күп нәрсәне югалттык та кебек. Бүген мәгарифтәге реформалар, документлар әзерләү, электрон укытуга күчү мәшәкатьләре укытучының ана теле өчен көрәшерлек мөмкинлеген дә калдырмый. Ә бит Россия төбәкләрендәге татар теле укытучылары укытырга сәгатьләр калмавына зар елый.

Мәгариф өлкәсендә көенерлек һәм сөенерлек вакыйгалар шактый. Газета битләрендә бөтен мәсьәләләрне дә колачлап алу мөмкин эш тә түгел кебек. «Ватаным Татарстан» газетасында проблемалы, көн кадагына суга торган мәсьәләләр күп вакыт беренче бит язмасы буларак укучыга тәкъдим ителә, атна дәвамында әзерләнгән язмалар исә җомга санында «Белем һәм тәрбия» рубрикасында бирелеп барыла. Бу сәхифә ике атнага бер тапкыр чыгып килә. Даимилеген саклый.

Беренче бит язмалары, гадәттә, теге яки бу вакыйга, билгеле бер килеп туган проблема уңаеннан әзерләнә. «Татар телен белергә теләүчеләр күпме? «Ана теле» он-лайн мәктәбе җанлы дәресләр уздыра башлады» (2014, 11 гыйнв.), «Педагогик белемгә дәгъва, яки укытучыларны яңача әзерли башлаячаклар» (2014, 18 гыйнв.), «Нәрсә эшләдегез? Телләр турындагы программа үтәлеше белән кызыксынган һәркем шушы сорауны бирә ала» (2014, 1 февр.), «Балалар бакчасы ул – карават, урындык кына түгел» (2014, 4 февр.) дип аталган язмаларда шактый проблема күтәрелә, авторлар аларны чишү юлларын күрсәтә. «Балалар бакчасы ул – карават, урындык кына түгел» дигән язмада, исеменнән үк аңлашылганча, бүген бакчаларның материаль-техник базасы, яңа бакчалар төзү генә түгел, укыту-тәрбияләүгә дә зур игътибар бирелергә тиеш. Мәсәлән, ике телне өйрәтү буенча бакчалар өчен грантлар каралган һәм аларның шактый нәтиҗәле булуын ачыклаганнар. «Узган ел 20 бакча 1 миллион сум акча откан булса, быел грантка 50 бакча дәгъва кылган». Бәлки татар телен үстерүгә кызыксыну артуга китерер бу, тик чынлыкта күпчелек бакчаларда татар бүлекләре булып та, русча гына эшләүчеләр кала бирә. Материалда республика буенча нәтиҗәләр ясала, кайда, ничек? Ришвәтчелек, педагог-тәрбиячеләрнең белемен күтәрү мәсьәләләренә дә туктала автор. «Педагогик белемгә дәгъва, яки укытучыларны яңача әзерли башлаячаклар» шулай ук алдагы язмага аваздаш. Педагоглар әзерли торган югары уку йортларында укыту системасын үзгәртергә, студентларга атнасына бер көн мәктәпләрдә практика үтәргә тәкъдим итәләр. Мондый вәзгыять республикада гына түгел, Россия күләмендә күтәрелә. Укытучыларның белеме түбән булуы бер хәл, күп кенә вуз тәмамлаучы педагог-студентлар мәктәпкә килми икән, республикада хәтта укыта башлаган 800 гә якын яшь белгеч өч ел эчендә мәктәптән киткән. Шактый проблемаларны ачыклый торган язма әзерләнгән.

«Татар телен белергә теләүчеләр күпме? «Ана теле» он-лайн мәктәбе җанлы дәресләр уздыра башлады», «Нәрсә эшләдегез? Телләр турындагы программа үтәлеше белән кызыксынган һәркем шушы сорауны бирә ала» дигән язмалар ана телен үстерүне күтәрүче материаллар дип атарга була. Чынлап та, телләр турында моңарчы кабул ителгән программаларның тиешенчә эшләмәве гамәлдә яхшы күренә иде. Баксаң, аның гамәлгә ашыру механизмы камил булмавында булган икән. 2014-2020 елларга исәпләнгән телләрне саклау һәм өйрәнүнең яңа программасы кабул ителгән, җитәрлек күләмдә акча һәм күзәтүче оешмалар билгеләнгән. Программаның эшләнеше, телләр үстерелеше турында моннан соң газетада даими басылып барылырга тиеш, без өйрәнә торган «Ватаным Татарстан» газетасында гына түгел, барлык татар телле матбугат бу программаны файдаланырга тиеш, дип саныйм мин. Газеталарда бәхәс мәйданнары булдырырга, тел мәсьәләләренә тукталган түгәрәк өстәлләр, интернет-конференцияләр уздыру зарур. Бер генә белгеч тә битараф кала торган тема түгел бу. Әнә шундый җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырган, проблемалар күтәргән материалларны «Ватаным Татарстан» беренче бит язмалары итеп тәкъдим итә.

Газетаның җомга саны гадәттәгедән үзгәрәк, калын, 20 битле булып чыга. Җомга санында «Белем һәм тәрбия» сәхифәсе соңгы өч ел дәвамында чыгып килә. Рубрика билгеле бер җирлектән әзерләнгән материалларны урнаштыра, укытучылар, укучылар, студентлар белән сораштырулар оештыра. «Туган тел дәресләре» рубрикасын алып бара. 2013 елның 31 декабре санында «Укытучы укучыдан көчсез була алмый» дигән язмасында Сәрия Садрисламова Әтнә районы Комыргужа мәктәбе, Казанның 18 нче гимназиясе, Апас районы Тутай мәктәбе, Бөгелмә районы мәгариф идарәсе белән элемтәгә кергән. Материалны коры фактлардан тыш, конкрет авыл һәм шәһәр мәктәпләре, укытучылары белән бәйләп язылуы, билгеле бер формага китерелеп тәкъдим ителүе белән отышлы булган.

Шул ук санда «Туган тел дәресләре» рубрикасын филология фәннәре докторы, профессор Рүзәл Юсупов алып бара. Материал җиңел үзләштерелә.

«Медальләр бетә?» язмасында студентлар һәм мәктәп укучылары белән блиц-интервью үткәрелгән. «Белем һәм тәрбия» рубрикасының 2014 елгы 14 февраль санында республика мәктәпләрендәге сак хезмәте эшчәнлеге хакында сүз бара. Әлегә кадәр каравылчы хезмәте өчен акча каралмаган, ә вахталарда пенсия акчасына азрак өстәмә булыр дип өлкән яшьтәге абый-апалар утыра. Махсус сак хезмәтләреннән күпчелек мәктәп файдалана алмый, ата-аналарның да, мәктәпнең дә моңа мөмкинлеге юк, ә илдәге әледән-әле булып торган куркыныч вакыйгалар уйланырга этәрә. Сәхифәдә шулай ук «Туган тел дәресләре», «Яңалыклар», «Шәхес мәктәбе» рубрикалары урын алган.

Югарыда телгә алынган язмалар, анализланган материаллар газетада ни дәрәҗәдә мәгариф темасының яктыртылышын күрсәтә. Басмада һәр сан саен мәгариф темасына урын бирелә. Мәгариф һәм фән бүлеге мөдире, татар журналистикасы кафедрасының элеккеге студенты Сәрия Садрисламованың тырышлыгы да сизелә. Балалар бакчаларыннан башлап югары уку йортлары

һәм фән өлкәсен бер генә кеше колачлап бетерү дә мөмкин эш түгелдер. Элек бу бүлектә ике кеше эшли иде, хәзер бу эшне бер журналист алып бара.

Иҗтимагый-сәяси гомумтатар газетасында республика шәһәр һәм районнарындагы мәгарифнең торышы гына түгел, татарлар яшәгән төбәкләрдәге ана теле укытуның яки мәгариф системасындагы үзгәлекләр турында да укыйсы килү теләге кала. Газета журналистлары бик еш төрле төбәкләрдән язмалар әзерли, бер үк вакытта мәгариф һәм тәрбия тематикасын да яктыртсалар, укучылар өчен кызыклы булыр. Әлегә безгә Сингапур тәҗрибәсе генә таныш. Мәсәлән, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең балаларына туган телләрен укыту тәҗрибәсе шулай ук әһәмиятле булыр иде. Бу хакта ишетеп кенә беләбез.

Гомумән, «Ватаным Татарстан» газетасында мәгариф темасының куелышы яхшы. Әмма камиллекнең чикләре юк. Башка авторларны тартып китерү, урыннарда язмалар язу, укучы һәм укытучыларны кызыксындыру өчен төрле конкурслар, викториналар игълан итү отышлы булыр иде.

Матбугат – тәрбия чарасы
(«Мәгърифәт» газетасы, «Гаилә һәм мәктәп» журналы мисалында)

Р.М.Галиева, КФУ доценты,
филология фәннәре кандидаты

Безнең илдә педагогика фәнендәге кризисның барлыкка килүенә сәбәпләр җитәрлек. Беренчедән, үсеш алучы бала шәхесенә игътибарны аз бирү. Икенчедән, укыту һәм тәрбияләү процессындагы аерым шәхескә генә хас билгеләрне тоеп ала алмау. Әлбәттә, өченче зур сәбәп итеп кирәкле китаплар, ярдәмлекләр булмауны күрсәтергә кирәк. Педагогик процесслардагы үзгәрешләр, халык мәгарифе белән идарә итү, уку йортларындагы мөһим проблемалар турында фикер алышуның җәмәгатьчелеккә белдерелүе гаммәви мәгълүмат чаралары һәм китап нәшрияты аша алып барыла.

Газета-журнал һәм китап нәшрияты алдында зур бурыч тора. Киләчәктә татарның укымышлы, сәяси яктан өлгергән, зыялы, белемле һәм әхлаклы яшьләрен тәрбияләү. Таякның юан башы, әлбәттә, көндәлек чыгып килүче газета-журналларга төшә. Алар укучыга һәръяклап якын килеп, аны тәрбияләргә тиешләр. Бүген татар матбугаты бу өлкәдә шактый эшләр башкара. Әмма бу гына аз. Билгеле, газета-журналларда күтәрелгән проблемалар бихисап. Тик шулай да укучыны тәрбияләүне даими контрольдә тотарга тиешбез. Матбугат укучыны тәрбияли. Фәнни яктан өйрәнеп үтсәк, газета материалының үзәгендә тәрбияви вакыйга ята. Ул тәрбияви эшчәнлеккә корылган һәм өч этаптан тора: ориентлашу һәм планлаштыру; эшчәнлек планнарын тормышка ашыру; нәтиҗәлекне тикшерү, ягъни язманың нәтиҗәсе булганмы?

Гаммәви мәгълүмат чаралары шартларында тәрбияви эшчәнлек журналист яисә редакторның педагогик тәэсир итүе генә түгел, ә бәлки әти-әниләр, укытучы-дусларның кабул итү тирәлеге эшчәнлеге дә. Без аудиториягә барып җитәрлек камил әсәр тудырырга, аның максатын билгеләргә, аудиториянең хәленә карап эш итә белергә тиешбез.

Россия күләмендә укытучылар өчен чыгып килүче килүче иң зур басмаларның берсе «Учительская газета», Татарстанда «Мәгърифәт» газетасын, «Мәгариф» журналын атап булыр иде. Бүген «Мәгърифәт» газетасы «Гаилә һәм мәктәп» журналына үзгәрде. Сүзебез шушы ике басма хакында барыр. Форматның үзгәрүе эчтәлеккә зыян салмаганмы? Үзгәрешләрнең өстенлеге нәрсәдә чагылачак.

Билгеле булганча, «Мәгърифәт» педагогик басма буларак нәшер ителде. Ул билгеле бер социаль тирәлекне үз эченә алды. Газета укытучылар, укучы яшьләр һәм студентлар өчен иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис басма буларак чыгып килде. Төп максаты аң-белемгә, мәгърифәтлелеккә омтылыш тора. Илдә, дөньяда барган вакыйга-яңалыклар белән таныштырып барырга тырыша. Чөнки җиһандагы яңалыклардан хәбәрдар булмаган зыялы кеше ничек инде башкалар белән аралаша алсын. Шуңа күрә әлеге катлау кешеләре үзләре укыганны башкаларга аңлатып та бирә белергә тиешләр. «Гаилә һәм мәктәп» журналы исә үзенең башлангычында ук «Әтиләр һәм әниләр» журналы буларак үзен укучысына тәкъдим итте. «Ата-ана тәҗрибәсе», «XXI гасыр баласы», «Яшәеш», «Укыган чит илгә уза», «Йолдызлы гаилә», «Психолог киңәше», «Иманлы бала», «Сәламәтлек», «Хәрәкәттә – бәрәкәт» рубрикалары аша укучыга беренче язмаларын җиткерде.

Халыкка аңлату, аны аң-белемле итү ысуллары елдан-ел камилләшә генә бара. Газета-журналлар эчтәлеге, формасы белән укучысына ярар өчен зур көч куя. «Мәгърифәт» газетасы да соңгы елларда туктаусыз эзләнүдә булды. Проблемалы язмалар, төрле җирлекләрдән язылган актуаль мәкаләләр еш басылды. «Мәгърифәт» газетасы мәгариф системасын камилләштерүгә һәрдаим үз өлешен кертте. Газета мәгариф системасында эшләүчеләрне социаль яклау, урта мәктәп һәм югары уку йортларындагы җитешсезлекне бетерү кебек проблемаларга да еш туктала иде. Укытучыларны борчыган сорауларга җавап һәрдаим белгеч киңәшләре белән баетылып киленде. Укытучылар, укучылар, студентлар, мәктәп балалары, галимнәрнең язмаларын күпләп табарга була. Газета педагогик матбугат алдында торган берничә мәсьәләне чишәргә омтыла иде. Бу фәндә булган казанышларның нәтиҗәләрен чагылдыру, укучыларның уку һәм тәрбиядәге конкрет уңышларын, урта һәм югары мәктәпләрдәге педагогларның иҗади эзләнүләрен яктырту аша алып барылды.

Мәгариф, мәктәп тематикасын үз эченә алса да, бу ике басманы бер-берсенең дәвамы итеп карарга ярамый. «Гаилә һәм мәктәп» журналы «Мәгърифәт» газетасы колачлаган шактый темаларны кысрыклап чыгарды, бу аңлашыла да, ул берникадәр кыйбласын үзгәртте. «Гаилә һәм мәктәп» журналы ата-ана өчен кулланма буларак тәкъдим ителсә дә, педагогик басма буларак үз йөзен булырырыр дип уйлыйм.

Мәктәп тормышына багышланган журнал буларак ул татар укучысын тәрбияләү, милли мәгарифне үстерү өчен халык педагогикасын куллану кебек темаларны да алып барырга тиеш кебек. Кайчак язмалар интернет басманы хәтерләтә, артык глобальләшеп китүен сизми калу мөмкин түгел. Материалның төп геройлары турында ике җөмлә генә укып, калган ике битне коры фактлар, саннар белән тутыру да укучының гайрәтен чигерергә мөмкин. Газетада тормыштан алынган хәл-вакыйгалар тасвирланып анализланган булса, журналда исә күбрәк теге яки бу хәлгә аңлатма бирү, белгеч киңәше тәкъдим ителә. Саннар, фактлар тезмәсе өскә калкытып бирелә.

Журналда «Иманлы бала» рубрикасы бирелеп барыла. Шундый ук рубрика милли тәрбия турында булса, язмалар урнаштырылып барылса яхшы булыр иде. Чөнки татар халкы элек-электән үз баласына яхшы тәрбия, белем бирергә тырышкан. Татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри менә нәрсә дип яза: «Тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, әлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә төзәтмәк, вә хайванидән чыгарып вә инсаният дәрәҗәсенә күтәрмәк, вә тәглим бирмәк, вә үрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер».

Педагогик басма башка газета-журналлардан аермалы буларак, икеләтә функция башкара. Беренчедән, ул аудиториягә тәэсир итсә; икенчедән, шул аудитория аша киләчәк буынны тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Киләчәк буын дип сөйләгәндә, балалар бакчаларыннан алып югары мәктәптә укучылар күз алдына килә. Безнең барыбызның да мәктәп укучысынмы, студентнымы тәрбияле итеп күрәсебез килә. Уку йортларның да төп максаты – баланы белемле итеп кенә түгел, ә тәрбияле, югары зәвыклы, әхлаклы кеше итеп тә тәрбияләү. Чөнки мәктәпне тәмамлауга алар югалып та калырга мөмкиннәр. Тормыш авыр, көннән-көн катлаулана. Үз сукмагыңны булдыру өчен күп киртәләрне атлап чыгарга туры килә. Әнә шул киртәләрне атлап чыкканчы, үзең булып калырга сиңа мәктәп тәрбиясе ярдәм итәр. Баланың рухи үсешенә иң беренче орлыклар гаиләдә салынса, шул орлыклардан нечкә, саф күңелле, әхлаклы, тәрбияле баланы үстерү, аны тәрбияләү мәктәп, укытучылар җилкәсенә төшә. Шуңа күрә педагогик басма укучысын әхлакый яктан икеләтә тәрбияли. Тормыштагы вакыйгалардан үрнәк, ә кайбер очракта гыйбрәт итеп язылган язмаларны «Мәгърифәт» газетасында еш очратырга мөмкин иде. Мондый әсәрләр төрле катлаулы хәлләрдән чыгарга, эшләгән адымыңа нәтиҗә ясарга ярдәм итә. «Гаилә һәм мәктәп» журналы да, үз кыйбласына тугры калып, укучыларын тәрбияләсен иде.

Матбугатта махсуслашу
(«Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналлары мисалында)

Л.Т.Гарифуллина, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – А.Ф.Галиәхмәтова,

филология фәннәре кандидаты)

Бүгенге көндә укучыга сайланыр җирлек бар, газета-журналларның күп булуы шундый мөмкинлек тудыра. Электрон гаммәви мәгълүмат чаралары барлыкка килү басма матбугатка булган игътибарны бераз киметсә дә, тулысынча дөнья базарыннан кысрыклап чыгара алмаячак.

Газета-журнал укучы танышларымның күпчелеге махсуслашкан матбугатка өстенлек бирүен беләм. Әлеге теманы сайлап алуым да шуның белән бәйле. Махсуслашкан матбугат чаралары дип нинди басмаларга әйтәләр? Махсуслашкан матбугат дип, устав буенча, аерым бер һөнәр кешеләренә, укучы, тыңлаучы, караучыларның аз санлы контингентына кызыклы булган тематикага язмалар бастыручы (радио-, телетапшырулар әзерләүче) гаммәви мәгълүмат чараларына әйтәләр [1].

Махсуслашкан матбугат чаралары универсаль җәмгыяви-сәяси характердагы язмаларны бастыруга ориентлашмаган. Мисал өчен, мондый төр гаммәви мәгълүмат чараларына фәнни, балалар өчен, әдәби-тәнкыйди, коммерция-реклама басмалары һ.б. керә.

Махсуслашкан матбугат чаралары сайлап алу алды кампаниясе вакытында агитацион рухтагы язмаларны, рекламаны бастырмаска хокуклы.

Һәр махсуслашкан матбугат чарасын аерым карап чыгу өчен шактый вакыт кирәк булыр иде, шуңа мин әлеге язмамны «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналларына таянып эшләргә булдым.

«Мәгариф» галимнәрнең, җитәкчеләрнең, татар һәм рус, чуваш, удмурт, мари мәктәпләре укытучы һәм директорларының, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының алыштыргысыз ярдәмлеге санала. Журналның тиражы 9100 данә (2014 елның 1 нче саныннан). Төп максаты – белем бирү һәм тәрбия өлкәсендә яңа методика һәм технологияләр белән таныштыру, мәдәният һәм әдәбият өлкәсендәге яңалыкларны тарату, укучы һәм укытучыларның сәламәтлеген кайгырту, сәламәт яшәүгә бәйле сорауларга җавап бирү, РФ һәм ТРның «Мәгариф турында»гы законнарын тормышка ашыруда булышу һ.б. тора. «Фәнни стиль» сүзен ишеткәч, гадәти кеше өчен аңлаешлы булмаган язмалар күзалдына килә. Әмма «Мәгариф» журналындагы фәнни стиль үзенчәлекле – аны һәркем аңлый ала.

Шулай да, биредә укытучылар куллана торган терминнар күп: «педагогик практикумнар», «педагогик өчпочмак», «тематик консультация», «лаборатория», «интеллектуаль уен», «профильле укыту», методист», мәгариф бүлеге», «дәрес программасы», «гипотеза», «дәресләр челтәре», «класстан тыш чара» һ.б. Моннан аның нинди аудиториягә юнәлдерелгәненә тагын бер кат инанып була.

«Мәгариф» журналы укытучылар өчен конкурслар уздыра, шуларның берсе «Иң яхшы мәкалә авторлары» ярышы; укучыларны һәрдаим рус һәм татар язучылары, композиторлары, рәссамнары һәм аларның әсәрләре белән таныштырып бара. Шулай ук фәндә булган ачышлар, яңа уйлап табулар, гуманитар сорауларга җаваплар өчен дә биредә урын табыла.

2014 нче ел башында журнал үзгәрешләр кичерсә дә, аның үзалдына куелган максаты үзгәрмәгән: ул һаман да укытучыларга укыту эшендә ярдәмлек булып тора. Үзем укып бетергән мәктәптәге әдәбият укытучым «Мәгариф» журналы турында: «Хәзер инде укучыларым да укытучы булып, үзләрен тәрбияләүдә ярдәм иткән «Мәгариф»кә язылалар. Ул тулы бер гасырны тоташтырды», – ди.

Чыннан да, укытучылар белән гасыр дәвамында бергәләп атлап барган «Мәгариф»нең педагогика өлкәсендә өлеше зур: ул ТРның барлык районнары мөгаллимнәренең тәҗрибә уртаклашу, аралашу мәйданчыгы булып кала бирә.

2013 нче елның август аеннан «Мәгърифәт» газетасы урынына «Гаилә һәм мәктәп» исемле яңа журнал дөнья күрде. Әлеге журнал һәм «Мәгариф» бер үк редакция тарафыннан чыгарыла, баш мөхәррире – И.Ф.Миргалимов, «Ватаным Татарстан» газетасы мөхәрриренең элеккеге урынбасары.

«Мәгариф» журналы укытучыларны берләштерүче, аларга юнәлдерелгән басма булса, «Гаилә һәм мәктәп», исеменнән күренгәнчә, ата-аналарны, әби-бабайларны һәм мәктәпне тоташтыручы басма. Аларның чыгу вакытлары да төрле: «Мәгариф» – ай башында, «Гаилә һәм мәктәп» ай ахырында чыга. Журналның үзалдына куйган максаты беренче санда И.Ф.Миргалимовның мөхәррир сүзендә ачык күренә: ««Гаилә һәм мәктәп»нең төп миссиясе – ата-аналарга, әби-бабайларга, гомумән, үсеп килүче яшь буынны физик һәм рухи яктан сәламәт итеп күрергә теләүчеләргә төпле киңәш бирү, аларның тәҗрибә уртаклашуын оештырып җибәрү, журнал битләрендә белгечләр белән очраштыру. Журналны укыгач, үзегез дә аңларсыз: без хәтта иң кыен һәм катлаулы темаларга да ачыктан-ачык сөйләшергә әзер».

«Гаилә һәм мәктәп» журналы заманча форматта, төсле булып чыга. «Милли мәгариф», «Актуаль тема», «Бушлай консультация», «Укытучы гына түгел», «Репортаж», «XXI гасыр баласы», «Гыйбрәт», «Сәламәтлек», «Ата-ана тәҗрибәсе», «Киңәш-табыш», «Психолог киңәше», «Хәрәкәттә – бәрәкәт», «Иманлы бала», «Остаханә» исемле сәхифәләре бар. Тиражы – 5-7 мең данә. Яшь чикләве – 14+.

«Мәгариф» журналы уку-укыту өлкәсендә махсуслашкан булса, «Гаилә һәм мәктәп» ата-аналарга тәрбия серләрен өйрәтүдә махсуслашкан. Шуңа күрә бу ике журналны үзара чагыштыру мөмкин түгел.

2014 нче елның гыйнвар аенда журнал үзгәрешләр кичерә: И.Ф.Миргалимовны «Мәгариф»кә баш мөхәррир итеп алалар, «Гаилә һәм мәктәп» Г.Р.Закирова баш мөхәррир итеп билгеләнә. Мөхәррире үзгәрү журналның йөзен үзгәртми, ул баштагыча чыгуын дәвам итә.

«Мәгариф» кадәр 100 еллык тарихы булмаса да, 6 ай дәвамында чыгучы «Гаилә һәм мәктәп» үзенең позициясендә нык тора. Һәр яңа санда язмалар ата-аналарны да, яшүсмерләрне дә уйланырга мәҗбүр итә, аларны борчыган сорауларга җаваплар бирә. Җенси тәрбия, психолог киңәше, табиб фикере ише сәхифәләр аеруча кызыклы, чөнки мондый төр сораулар четерекле булып кала бирә. Татар гаиләсендә ата-ана һәм бала ачыктан-ачык җенси темага сөйләшми күтәрми, ә бу исә аяныч нәтиҗәләргә китерә. «Гаилә һәм мәктәп» бу мәсьәләне

ничек хәл итергә икәнлеген аңлата, бала белән җенси темаларга ничек дөрес аралашырга кирәклеген өйрәтә.

Әлеге журналда ата-аналар өчен тагын бер файдалы мәгълүмат ул – афиша. Ялларны кайда үткәреп була, кайсы театрга яисә музейга барырга – барысы да бирелеп барыла.

Гомумән, журнал балаларны да, ата-аналарны да тәрбияли дисәм, дөрес булыр. Ул чын дәрәҗәсендә психологик терәк.

Матбугатта махсуслашу – журналның мөхәррире үзалдына куйган катлаулы максат, дияр идем мин. «Мәгариф» журналы сыман бер гасыр дәвамында төрле чор һәм төре яшьтәге, төрле милләттәге укытучыларны берләштереп тору, үзенең югалмас, тотрыклы йөзен булдыру җиңел эш түгел. «Мәгариф» уку-укыту өлкәсендә Татарстан Республикасының милли җәүһәренә әйләнгән.

Август аенда нәшер ителә башлаган «Гаилә һәм мәктәп» журналының да киләчәге шундый тотрыклы булса, балаларны тәрбияләүдә уңышка ирешеп булыр иде. Замана гел алга омтыла, аның бу омтылышында ата-аналарга да, балаларга да җиңел түгел. Кичә кыйммәткә ия булган нәрсәләр бүген кыйммәтен югалта ала, шуңа күрә гел яңалыклар үзәгендә булып тору кирәк. Яңа журнал бу мәсьәләдә зур эшләр башкара.

«Мәгариф»нең элгәре буларак «Мәктәп» журналы

В.З.Гарифуллин, КФУның
татар журналистикасы кафедрасы мөдире,
филология фәннәре докторы, профессор

Моннан йөз ел чамасы элек, XX йөз башының икенче дистә елында, демократик хәрәкәтнең яңа дулкыны барлыкка килә, милләтне берләштерү мәсьәләсе кабат көн кадагына баса. Татарның алдынгы вәкилләре халкыбызны берләштерүнең иң мөһим чарасы мәгарифне үстерү белән бәйле икәнлеген бик яхшы аңлый. Бу уңайдан татар җәмәгатьчелегенең дөньяви милли мәктәп оештыруга булган омтылышы тагын да көчәеп китә. Мәгарифне үстерүгә кагылышлы сораулар хакында фикер алышу, милли мәгарифне реформалаштыру һәм үстерү юнәлешендә булган тәҗрибәне уртаклашу өчен Казанда «Мәктәп» журналы гамәлгә куела.

Билгеле булганча, журналның беренче саны 1913 елның 21 февралендә «Сабах» ширкәтендә дөнья күрә. Журнал, 1914 елда да дәвам итеп, барлыгы 25 саны дөнья күрә .

Журналның мөхәррире – татар халкы, аның мәдәнияте-мәгърифәте өчен җан атып йөргән мөхтәрәм зыялыларның берсе Шиһаб Шәрәфетдин улы Әхмәров. Ул үзе мөгаллимлек иткән чагында, дөньяви фәннәр буенча уку китаплары җитмәвен күреп, мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслек төзи. «Сабах» басмаханәсендә баш мөхәррир булып эшләгәндә, басмаханәләр белән

кызыксынып, «Матбагачылык тарихы» исемле тирән эчтәлекле хезмәтен яза. Шиһаб Әхмәров үзе дә журнал мөхәррире генә түгел, яхшы журналист булып таныла. «Мәктәп»тә аның «Гимназия хакында» (1913, №2), «Сүз һәм эш»«« (1914, №1), «Бәйрәм вә балалар» (1914, №3) исемле мәкаләләре басыла .

Шиһаб Әхмәровның үз гаиләсендә татарның бөек композиторы Салих Сәйдәшевны (ул Салихның җизнәсе була) тәрбияләп үстерүе дә әлеге шәхеснең милләтебез үсешенә зур өлеш керткән олы җанлы милләтпәрвәр булуын тагын бер кат ассызыклый.

Журналны чыгаруда күренекле әдип, галим һәм педагог-журналистлар, Россиядәге атаклы мәдрәсәләрнең укытучылары, мәктәпләрнең иң тәҗрибәле мөгаллимнәре, Казан һәм Петербург университеты шәкертләре, башка зыялылар катнаша. Авторлар арасында шул чорның атаклы затлары Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Фәхрелислам Агиев, Фатих Сәйфи, Нәҗип Думави, Муса Бигиев, Әхмәтһади Максуди, Әхмәтзәки Вәлиди, Мәхмүтфуат Туктаров, Габделбарый Баттал, Газиз Гобәйдуллин, Шакир Мөхәммәдъяров, Габдулла Гисмәти, Мөхетдин Корбангалиев, Фәхрелбанат Сөләймания һ.б. исемнәрен күрәбез. Мондый олы шәхесләр катнашында нәшер ителгән журнал, әлбәттә, гаять киңкырлы һәм киң карашлы басма буларак таныла.

Журналда уку-укыту һәм белем-тәрбиягә кагылышлы хәбәрләр, фәнни, тарихи, икътисади мәкаләләр, мәктәп фәннәре һәм аларның программалары, мәктәп-мәдрәсәләребезнең тарихлары, мөселманнарның мәгариф эшләренә хөкүмәтнең мөнәсәбәте, сәнәгать һәм һөнәр мәктәпләре, дини мәсьәләләр, хатын-кыз мәгарифе, чит илләрдә мәгариф, дәреслекләр, яңа китаплар, матбугат яңалыклары, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре, тел белеме проблемалары күтәрелә. Шулай ук танылган шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре һәм хезмәтләре биреп барыла. Менә шундый киң тематик диапазонлы басма булганга күрә дә ул татар зылылары арасында тиз арада зур абруй казанып өлгерә.

Бу елларда татарлар тормышында ысулы җәдит мәктәпләре шактый үсеш алган. Көн тәртибенә шул мәктәпләрне ныгыту, аларда укыту-тәрбия сыйфатын күтәрү, яңа тип мәктәпләр булдыру бурычлары килеп баса. Журнал мәктәп-мәдрәсәләрнең үткәнен, бүгенгесен, киләчәген төрле яклап яктырта. Мәшһүррәк мәдрәсәләр турында очерклар циклы бирә. Башлангыч мәктәпләрнең хәлен җентекләп тикшерә. Кызларга кирәк кадәрле белем һәм тәрбия бирү хакында кайгырта. Татар мәктәпләрен Европа илләрендәге мәгърифәт күзлегеннән тикшерү, Америкадагы тәрбия һәм белем бирү системасы, Төркиядәге яңа мәктәпләр белән чагыштырып карау да кызыклы. Укытуда чит илләрнең алдынгы тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү безнең бүгенге басмаларыбыз өчен дә актуаль булып тора.

Журнал, мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту-тәрбиянең барышы белән бергә аларның финанс хәлләрен, мөгаллимнәрнең хәл-хокукларын, аларны хәзерләү мәсьәләләрен дә куя.

«Мәктәп» журналы программа, дәреслекләр, уку китаплары хакында фикер алышулар оештыра, мөгаллимнәргә үзара хәбәрләшү өчен юл ача,

аларның сорауларына җавап бирергә тырыша. Ягъни редакция укучылары белән тыгыз элемтәдә тора. Бу – шулай ук басманың үрнәк алырдай лаеклы сыйфаты. Журналда шулай ук педагогика фәне, аның нигезләре бәян ителә, бу фәннең психология белән бәйләнеше нигезләнә, укыту-тәрбиягә яңача карашлар, үзен аклаган уңышлы алымнар, тәҗрибәләр тәкъдим ителә. Бу уңайдан Мөхетдин Корбангалиевнең «Иптидаи мәктәптә укыла торган фәннәр» исемле методик күрсәтмәләр циклы аерым бер игътибарга лаек.

Журналда даими рәвештә табигать дәресләре, авыл хуҗалыгы, физик тәрбия дәресләрен үткәрү алымнарына багышланган мәкаләләр дә бирелә.

«Мәктәп» журналының милли тәрбиягә игътибары аеруча зур. Бигрәк тә ул татар теле, әдәбияты, тарихын өйрәтү мәсьәләләрен җентекләп тикшерә. Тел, имла, әдәбият берлегендә, мәктәп һәм әдәбият, гомумән, мәдәният үсешендә милләтнең берлеген һәм көчен күрә.

Журналның 1914 елгы 3 санындагы «Тәрбиядә берлек» язмасында Гаяз Исхакый мәктәпләрнең татар халкын берләштерүдәге ролен ассызыклап күрсәтә. Милләтебезнең сибелеп һәм бик таркау яшәве мәктәп программаларында да бик ачык чагыла, ди ул: «Бүгенге көндә Идел буе мәктәпләре үзләренең әлифбалары, гыйлем хәлендәге намаз-фарызлары, сөннәтләре берлә бер төрле булсалар да, рухи җаны берлә кырык төрледер. Аларның бер бүлегендә, милли шагыйрьләребез, мөхәррирләребезнең фикерләренә, уйларына зур әһәмият бирелеп, татар әдәбияты илә таныш егетләр хәзерләргә ярдәм ителә; бер төрлесендә, гарәп шигырьләре, фарсы көйләре көйләтелеп, нә Тукай, нә милли әдәбияттан бер нәрсә бирелми… Шул төрлелекне, шул башбаштаклыкны бетерергә безнең Идел буе татарларының хәзер көченнән килә».

Бу уңайдан Г.Исхакый «Мөгаллим вә мөгаллимәләребезнең бу көнге вазифалары нәрсә?» дигән язмасында (1914, №1) мәктәп алдына түбәндәге бурычларны куя: «Хәзерге мәктәпнең вазыйфасы безнең киләчәк буыныбызны аңлы, укымышлы бер татар ясап чыгарудыр. Шуның өчен андагы укыту теле, андагы тәрбия, андагы җырлар, көйләр – һәммәсе шуңарга хезмәт итәргә тиештер… Мәктәп, өч-дүрт ел укыганнан соң, тәмам татар баласы җитештерсен. Аның рухы, аның теле, аның төшенчәсе, аның тойгысы татарча булсын. Шул эшне эшли алсак, безнең милли мәктәпләребезнең нигезе бик нык җиргә утыртылган була. Безнең милли мәдәниятебез туфанда да, давылда да ватылмый, кырылмый торган тораташ була».

Исхакый бигрәк тә мәктәптә әдәбиятыбызны тиешенчә өйрәтүгә укучыларның игътибарын юнәлтә. «Әдәбият аркасында без балаларымызның күңелләрен нечкәртәбез, әдәбият аркасында балаларны уйларга, төшенергә, кеше хәленә, кеше кайгысыны үз кайгысы иттереп уйлатырга өйрәтәмез», - дип яза Гаяз Исхакый үзенең «Тукай – мәктәптә» дигән мәкаләсендә. 1914 елның 6 нчы санында басылган бу язмада мәктәпләребездә әдәбият өйрәтүнең үзәгендә Тукай фигурасы торырга тиеш дигән проблеманы күтәрә. «Тукай – яңа буынның үзенә-үзе аңлавында, үзенә-үзе дөньяга каршы карауны ясавында,

үзенең тирә-юненә тануында беренче роль тотачак шагыйремез, әдибемез, мөхәрриремездер», - дип яза ул .

Болардан тыш, тел-әдәбият, шулай ук тарих укыту хакында Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Думави, Фатыйх Сәйфи һәм башка күренекле авторларның кызыклы мәкаләләрен табабыз.

Журналның игътибарыннан дини тәрбия мәсьәләләре дә читтә калмый.

Милли мәктәп һәм милли тәрбия мәсьәләләре уңаеннан «Мәктәп» журналының «Без нинди милләт соң?» дигән темага фикер алышу оештыруы да зур кызыксыну тудыра. Язмаларда милләтебезнең «татар», «мөселман», «төрек», «нугай» дип аталуы тирәсендә бәхәс бара. Күпчелек «татар» атамасын яклап чыга. Шулай итеп, «Мәктәп» татар халкының иҗтимагый хәленә, тарихына, диненә, мәдәниятенә карата да үзенең бәясен бирә. Шул ук вакытта ул мөгаллимнәр өчен фикер алышу һәм хәбәрләшү бурычын да үти

Журнал беренче чиратта педагогик һәм методик басма вазыйфаларын башкара. «Мәктәп» журналы мөгаллимнәрне мәгариф өлкәсендәге яңа карашлар, дөньяви фәннәрнең эчтәлеге һәм укыту методикалары, яңа программалар белән таныштырып бара. Чит илләрдәге мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләреннән алдынгы үрнәкләр биреп бара. Журнал гомуми игътибарын яңа төр мәктәпләргә юнәлдерә, татар зыялыларына андый мәктәпләрне замана таләпләрен канәгатьләндерүче педагогика фәненә һәм гомумевропа мәгарифенең уңай нәтиҗәләренә нигезләнеп төзергә киңәш итә.

Шунысын да тагын бер тапкыр ассызыклыйк, «Мәктәп» журналы тар эчтәлекле махсус журнал булып калмыйча, киң карашлы басма буларак бөтен татар дөньясына киң таныла. Ул татар рухи-мәдәни һәм мәгариф тормышын һәрьяклап колачларга, милләтебез өчен иң актуаль проблемаларны күтәрергә тырышкан.

Бүгенге «Мәгариф» журналы нәкъ менә шул юнәлештәге үзгәрешләрне кичерә: аның укучылар һәм авторлар даирәсе киңәя, язмаларда публицистик һәм аналитик башлангыч көчәя, тематик юнәлешләр диапазоны арта. Әйтик, журнал актив рәвештә чит ил мәгариф системаларының алдынгы тәҗрибәсен пропагандалауга тиешле игътибар бирә башлады, милләтебезне саклап калу, үстерү юлындагы киртәләрне тирән анализларга сәләтле авторларны үзенә тартты.

Бу инде чын мәгънәсендә үзенең элгәре булган «Мәктәп»нең традицияләрен лаеклы дәвам итү дигән сүз!

Басма һәм электрон гаммәви матбугат чаралары

Ә.Т.Гыйлаева, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты,
доцент Р.Л.Зәйни)

Бүген мәгълүмат кыры гаять бай һәм күпкырлы. Журналист иҗатының да яңадан-яңа төрләре, заман технологияләре белән бәйле алым-чаралары барлыкка килеп тора. Интернет челтәренең, электрон массакүләм мәгълүмат чараларының көчле үсешенә карамастан, бүген тормышыбызны элеккечә үк газета- журналлар һәм китаплардан башка күз алдына китереп булмый. Хәзер Татарстанның басма матбугаты гражданлык җәмгыятенең йогынтылы институтлары буларак үсә. Басма сүзгә ышаналар, аңа колак салалар. Татарстан иң күп укучы һәм мәгълүмати яктан тәэмин ителгән Рәсәйнең иң көчле республикаларының берсе булып исәпләнә.

XX гасыр азагында безнең тормышыбызга уникаль һәм өметле мәгълүмати чыганакларның бөтендөнья глобаль системасы – интернет килеп керде, мәгълүмати агентлыкар, күп кенә басмалар, реклама агентлыклары пәйда булды. Федераль һәм региональ көнүзәк газеталарның электрон версияләре нәкъ менә интернетта барлыкка килде. Электрон версиянең өстенлеге шунда ки, үзеңә кирәк булган мәгълүматны төсле фотолар, шул вакыйгадан алынган тавыш һәм видео белән карарга мөмкинлек бар.

Мәгълүмат технологияләре киң колач ала барган чорда дөньяда шундый тенденция бара: электрон массакүләм мәгълүмат чараларының үсеше, басма матбугатның электрон версияләре барлыкка килү вакытлы матбугатның тиражын киметә. Аудиториянең дә әкренләп басма матбугаттан интернетка күчүе күзәтелә.

Соңгы елларда татар телендә чыгучы газета-журналлар саны күзгә күренеп артты. Шәхси газеталар күбәйде. Араларында берничә саны гына чыгып калганнары да бар, әлбәттә. Аннан-моннан материал күчереп бастыру, күпсанлы «йолдызлар», имеш-мимеш, аш-су һәм файдалы киңәшләр тирәсендә «әйләнү» белән мавыгучылары да күп. Шулай булса да татар матбугатының үсештә булуы шиксез. Исеме һәм абруе булган, дәүләт чыгара торган матбугат чараларында да бизәлеше һәм эчтәлекләре ягыннан үзгәрешләр күзгә чалына.

Газеталар чынлап та күп, аларның барысын да яздырып укып бару түгел, исемнәренә күнегергә дә өлгермисең. Хәзерге кызу заманда дөньядан калышмый мәгълүмат агышы артыннан ияреп барырга да кирәк.

Бүген һәр эре газета һәм журналны диярлек, кәгазь вариантыннан тыш, Интернетта да табып була. Язмаларны Интернетта бушка кую газетаның таралуын киметә, аны азрак кеше сатып ала. Басма матбугатка башка мәгълүмат чаралары – радио, телевидение һәм Интернет белән бер сафта бару җиңел түгел. Ләкин ил журналистикасының бай традицияләрен нәкъ менә басма матбугат чаралары формалаштыруын да онытырга ярамый.

Татарстанда бүген йорт хуҗалыкларының 62 проценты югары тизлекле интернетка тоташтырылган дип санала. Интернетның торган саен күбрәк үтеп керә баруын исәпкә алып, шәһәр-районнарда интернет басмаларны тагын да нәтиҗәле үсә баруы ачык чагыла. Басмаларның электрон версияләре мөмкинлекләреннән тулы файдалану, гаммәви мәгълүмат чараларын мультимедияле стратегиягә нигезләнеп үстерү зарурлыгы да игътибар үзәгендә.

Мисал итеп, Зәй районында чыгучы «Зәй офыклары» газетасын алдым. Атнага ике тапкыр чыгудан тыш, газетаның интернет челтәрендә электрон версиясе дә бар. Газетаның редакторы Николай Шамионов фикеренчә, укучы кәгазь вариантына күбрәк игътибар бирә. Шулай да сайтны тәүлек дәвамында яңартып торалар. Комментарийлар бик күп килгәнлеген, аларны җавапсыз калдырмауларын әйтте редактор. Онлайн режимда да бик күп язмалар куела, болар күпчелек очракта газета битенә сыеп бетмәгән материаллар. Газетаның күләме чикле, ә интернетта андый чикләр юк: тулы версияләр, күбрәк фотолар куярга мөмкинлек бар. Моның укучы өчен дә уңай ягы күп: газета килгәнен көтеп торасы юк, номер чыкканчы ук рәхәтләнеп ачып укырга була. Шулай итеп, сайт – газетаны, ә газета сайтны тулыландыра. Сер түгел, татар матбугатының укучысы күбрәк район җирендә, араларында өлкән буын вәкилләре бик күп, алар өчен әле кәгазь вариантының да әһәмияте зур.

Түбәндәге таблицада газетаның традицион төре һәм электрон формасы арасындагы уңай якларны билгеләдек.

Традицион басма	*Электрон басма*
рекламаның аз булуы;	югары тизлек;
урнашкан билгеле бер аудиториясе булуы;	бушлай (Wi-fi);
гади кулланылышта, техник мөмкинлекләрне белү таләп ителми;	интерактив;
дәрәҗәле;	сайтта үз фикереңне калдыру мөмкинлеге булу.
куркынычсыз;	
кыймммәт түгел.	

Күп кенә экспертларның фикеренә караганда, әкренләп газета- журналлар тиражын югалта баралар, ләкин бөтенләй юкка чыкмаячаклар.

Газета укучылар санының кимүе акчага гына да бәйле түгел, минемчә. Иң элек газета-журналларыбызның сыйфатын яхшыртырга кирәк. Кызыксындырам дип, тозсыз мәзәкләр яисә әһәмиятсез мәгълүматлар, сыйфатсыз әсәрләр бастыру белән шөгыльләнсәң, ерак китә алмыйсың. Алар белән югары зәвыклы укучы тәрбияләп булмый. Матбугат чыганакларының кызыклы рубрикалары да, төрле контингент укучыларның һәммәсе өчен дә яраклы материаллары да җитәрлек булсын. Мисалга «Мәдәни җомга» газетасын китерә алам. Монда бар да уйланылган: фән һәм сәнгатькә дә, мәгариф-мәдәнияткә дә, төрле жанрдагы әдәби әсәрләргә дә һәм башка күп кенә мәгълүмати материалларга да урын бирелгән. Күренекле шәхесләребез турында да шуннан укый алабыз. Кайсы санын укысаң да, үзеңә кирәкле нәрсәне алып була бу газетадан.

Татар матбугаты системасында яңа тип басмалар

Р.Л.Зәйни, КФУ доценты,
филология фәннәре кандидаты

Совет чорыннан соң Россия матбугаты элеккеге традицияләрнең иң уңайларын саклап иҗат итсә дә, бик күп үзгәрешләргә дә дучар булды. Иң беренче чиратта шәхси матбугат барлыкка килүне күрсәтергә кирәк. Икенчедән, күтәрелгән темалар һәм проблемаларның, XX гасырның 90 нчы елларына кадәр булганнары белән чагыштырганда, җир белән күк арасы булуын күреп тә, укып та беләбез. Яңалыклар моңарчы кулланылмаган жанрлар формалашуда да чагыла, монысы - өченчедән. Матбугатның базар икътисады шартларында товарга әйләнүе, шул сәбәпле тираж арттыру өчен журналистларның уңай гына түгел, тискәре, регрессив, җәмгыятьне артка тартучы темаларны күтәреп чыгуына да көн саен шаһит булып торабыз. Бу яңалыклар нигездә чит ил журналистикасыннан безнең татар матбугаты битләренә дә бәреп керде.

Үзгәрешләр арасында таблоидлашу күренешен дә аерып күрсәтергә мөмкин. *Таблоид* ул – А3 форматындагы басма. Әмма төп сыйфаты аның белән генә төгәлләнми. Инглизчәдән кергән «инфотейнмент» төшенчәсе (information – мәгълүмат, entertainment – күңел ачу) таблоидлашу процессының нигезендә ята, андый басмалар, билгеле булганча, аналитикага урын бирүне уйлап та карамый. Материаллары кыска, укучыны уйланырга этәрми, күбрәк басым зур һәм искитәрлек фотоларга ясала. Анда да фотоларның аеруча куркыныч, ямьсез күренешләрне сурәтләгәне, ягъни укуычыга тәэсир көче зур булганы сайланыла. Газета битләрендә атаклы кешеләрнең эшчәнлеге һәм шәхси тормышы турындагы ярымъялган-ярымчын мәгълүматлар, шаккаттыргыч хәлләр, куркыныч җинаятьләр, гайре табигый күренешләр турында сөйләнелә.

Болар ярдәмендә кешеләрнең яшерен тойгылары канәгатьләндерелә. Шуңа күрә дә халык ул газеталарны егылып укый, тиражларын арттыра. Тиражы зур булгач, реклама бирүчеләр өчен дә ул кирәкле басмага әверелә. Шуннан чыгып, күп кенә басмалар реклама ярдәмендә матди хәлне яхшыртыр өчен бу заманда таблоидка әйләнергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Дөресен әйткәндә, таблоидлашу ул редакция өчен ике яклы файда (әмма аудитория өчен түгел): рекламадан да керем килә, шул ук вакытта «сары» материалларны әзерләүгә күп вакыт, тырышлык һәм югары осталык дәрәҗәсе дә таләп ителми. Ә бит җәмгыятьтәге сәяси, икътисади, социаль проблемаларны күтәрүгә һәм чишүгә юнәлдерелгән мәкаләләр, журналист тикшерүләре, күзәтүләр язу күпкә зуррак чыгымнар сорар иде.

Кызганыч, бүгенге көндә инде шактый гына сыйфатлы дип саналган газета-журналлар стиленә дә инфотеймент кереп бара. Моны реклама бирүчеләр түгел, укучылар, журналистлар, редакторлар үзләре таләп итә, шулай дөрес дип таба: җитди мәгълүматны да, еш кына, кабул итү уңайлырак булсын дип, җиңеләйтә, кәеф күтәрүгә кайтарып калдыра. Шул рәвешчә, алар да таблоидлаша (инглизләр шулай ди) яки бульварлаша (монысы алманнар

термины). Таблоидлашу – басманың сыйфатын төшерү, тема төрлелеген югалту, текстка караганда, торган саен күбрәк һәм зуррак фотолар бастыру.

Татар матбугатында таблоид стиленә барысыннан да ныграк туры килүче «Кәеф ничек?» басмасы бар иде. Аның язмаларына кереп китмичә, беренче битендәге анонсларга күз салу да газетаның юнәлешен аңларга ярдәм итә. «КН хәбәрчесе: Сәнифә Рангулова дурацкий куртка сатып алды» (К.н.?, 2012, 7-13 ноябрь), «Фәнис Җиһанша Илсур Метшиннан да матуррак» (К.н.?. 2012, 19-25 дек.), «Ривкат абыйның бармакларын чабып өзгәннәр» (К.н.?, 2012, 8-14 авг.) – газетада менә шундый башисемнәр һәм шуларга туры килерлек зур-зур фотолар урын алган.

Матбугат дөньясында таблоидлашуга капма-каршы бара торган процесс та күзәтелә: таблоидлар сыйфатларын яхшырта, тирән эчтәлекле язмаларга өстенлек бирә башлый. Шул рәвешчә, таблоидлар квалоидларга әверелә. *Квалоид* – инглиз сүзе, quails һәм tabloid дигәннәреннән кушып ясалган, сыйфатлы таблоид дигәнне аңлата.

Безнең татар матбугатында чыгып килүче басмаларның шактые, таблоид булудан бигрәк, әнә шул квалоид дигән төргә туры килми микән әле. Квалоидларда Татарстандагы икътисадый хәл турындагы аналитика белән тузга язмаган мәзәкләр яки теге дөньяны сурәтләгән язмалар бер-берсенә комачау итмичә яши бит.

Мисал өчен, «Татарстан яшьләре» битләрендә инде ничә еллар чыгып килүче «Абау!» сәхифәсен алыйк. Бер ирнең хатынын үтерергә ябышуы, аннан полиция килеп алып киткәч, машинада җан тәслим кылуы (Т.Я., 2014, 23 гыйнв.) яки Яшел Үзән районындагы бер картның күрше карчыгын яндырып үтерә язуы (Т.Я., 2013, 21 дек.) турындагы «җиңелчә» хәбәрләр газетаны квалоидларга якын итә. Яки «Укыдыгызмы-ишеттегезме?» рубрикасына тукталыйк. Африкадагы Свазиленд короленең 15нче тапкыр өйләнүе (Т.Я., 2014, 23 гыйнв.) яки Кытайның Дафен шәһәрендәге махсус «ферма»дан миллионнан артык таракан чыгып качуы (Т.Я., 2013, 29 авг.) турындагы хәбәрләр белән беррәттән, газетада Россиядә медицинаның торышын анализларга омтылган «Карыйсызмы-юкмы, кайтып китәм бит!» (авторы Назилә Сафиуллина; Т.Я., 2013, 21 сент.) яки Айдар Хәлимнең милләт язмышы өчен борчылып язылган «Бүген әйтелергә тиешле сүз» мәкаләләре (Т.Я., 2012, 18 сент.) уңышлы гына «күршелек» итә.

Танылган публицист В.Мамонтов квалоид турында ачыктан-ачык «сыйфатлы эчлекне сары тышка төрү» дип белдерә [8].

Квалоидлар аерым ММЧ төреме? Шул турыда фикерләрне фәнни әдәбиятта Е.Л.Вартанова [1; 2], А.А.Монастырская [3], А.В.Прытков [4; 5] В.Скоробогатько [6; 7], С.Л.Страшнов [8; 9] хезмәтләрендә табарга мөмкин. Алардагы мәгълүматларны һәм шәхси күзәтүләрне туплап, квалоидларга хас булган төп сыйфатларны күздән кичерик әле.

Беренчедән, алар тышкы яктан таблоидларга тартым. Бу рәсемнәрнең күплегендә, аларның зур форматта булуында, газета теленең халыкка якынлыгында, кайчакта әдәби телдән шактый читләшүендә чагыла. Газета

үзенчә оригиналь, новарторларча версткалана, әйтик, мәзәкләр традицион формада ахыргы биттә яки бит астында түгел, ә газетаның исеменнән дә өскә урнаштырылырга мөмкин.

Шул ук вакытта газета битләрендә социаль тормыш тирәннән өйрәнелә, мәгариф, сәламәтлек саклау, җәмгыять тормышына кагылышлы җитди язмалар басыла.

Гомумән, квалоидның күтәрмәгән-яктыртмаган темасы юк, ул махсуслашырга омтылмый, аның өчен барлык вакыйга да азык булып тора ала, газета дөньядагы бар нәрсә турында да яза алырлык басмага әверелә.

Квалоидлар өчен традицион жанр кысалары юк. Шуңа күрә дә без бүген халык аеруча күп укый торган зур тиражлы басмаларда чиста аналитик жанрдагы язмаларны авырдан табабыз. Чынбарлыкта, квалоидларга хас булганча, мондый басмаларда жанрлар арасындагы чикләр югала, алар бер-берсенә охшый бара.

Шулай ук редакциянең халык белән якыннан аралашырга омтылуы, төрле чаралар (түгәрәк өстәл, кайнар элемтә, очрашулар, лотерея, анкеталар) үткәрүе дә аны бер үк вакытта сыйфатлы матбугатка да, сыйфатсызына да якынайта. Чөнки ул очрашуларның максаты – күбрәк халыкка үзе турында игълан бирү, абунәчеләр санын арттыру, тиражны үстерү. Икенче яктан караганда, шулай аралашу халыкны борчыган проблемаларны яхшырак аңларга ярдәм итә.

Кыскартулар

К.Н.? – Кәеф ничек?

Т.Я. – Татарстан яшьләре

Әдәбият

1. Вартанова Е.Л. Северная модель в конце столетия. СМИ стран Северной Европы между государственным и рыночным регулированием. М., Изд-во Моск. Ун-та, 1997. 184 с.

2. Вартанова Е.Л. Медиаэкономика зарубежных стран. М., 2005. С. 144.

3. Монастырская А. А. Таблоидная пресса в России, 1990 - 2000 гг. : диссертация ... кандидата филологических наук : 10.01.10. Санкт-Петербург, 2003. 190 с.

4. Прытков А.В. Квалоид как тип СМИ // ВЕСТНИК ВГУ. Серия: Филология. Журналистика. 2012, №2. С. 206-210.

5. Прытков А.В. Квалоиды и развлекательно-информационные издания // Коммуникация в современном мире. Материалы Всероссийской научно-практической конференции «Проблемы массовой коммуникации» 11-12 мая 2012 г. / Под редакцией В.В. Тулупова. Воронеж, Изд-во Воронежск. гос. ун-та, 2012. С.62-63.

6. Скоробогатько В. Настоящий немецкий порядок // Журналистика и медиарынок. 2010. № 2. С. 39.

7. Скоробогатько В. Владимир Скоробогатько: Смерть – избитая тема // Школа мультимедийной журналистики. URL: http://echoschool.ru/sovety-

mediakonsultanta/vladimir-skorobogatko-smert-%E2%80%93-izbitaya-tema (Дата обращения: 10.02.2014).
8. Страшнов С.Л. Квалоид // Журналист. 2010. № 9. С. 64-65.
9. Страшнов С.Л. Квалоид как актуальное медиапонятие // Журналист. Социальные коммуникации. 2011. №1. С.82-85.

Татарстанда матбугат иреге мәсьәләләренең торышы

З.Р.Латыйпова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты,
доцент Р.Л.Зәйни)

Сүзлек буенча, сүз иреге ул – кешенең үз фикерен ирекле рәвештә җиткерә алу хокукы. Бу ирек закон нигезендә кайбер халыкара һәм россиякүләм документларда да искә алынган. Шулардан Кеше хокукларының гомуми декларациясе, Кеше хокукларын һәм ирген саклау турындагы Европа Конвенциясе, Россия Федерациясе Конституциясен атап китәргә мөмкин. Сүз иреге мәсьәләре турында фикер йөрткән вакытта, танылган алып баручы Владимир Познерның сүзләре искә төшә: «Кеше тамашачы белән тулы кино залында шуңа теләге булганга гына «янгын» дип кычкырырга тиеш түгел,» – ди ул. – Бу сүз ирген чикләүме? Әйе. Ләкин бу әле җаваплылык дигәнне дә аңлата. Ә Россиядә аңа никтер ияләшә алмыйлар». Матбугат ирген һәр журналист үзенчә аңлап, үзенчә кабул итә. Аны бер яктан гына карау дөрес тә булмас иде кебек. Бу беренче чиратта кешенең идеологиясе, ышануларына бәйле. Хокукый яктан караганда, матбугат ирге бар, ул законда теркәлгән, ләкин ул безгә шул ук вакытта зур җаваплылык та өстәвен дә онытмаска кирәк. Журналистның эчке үзаңы аны һәрвакыт дөрес юлны эзләргә этәрергә тиеш. Бу очракта «ирек культурасы» дигән төшенчә килеп керә. Әмма хокукый яктан таләпләр куелу белән матбутның җаваплылыгы арта. Матбугат ирге бар, ләкин аның чикләре гомуми законнарда күрсәтелә. Шул рәвешле югары хакимият закон чыгару хокукына ия булган кебек, ирекнең кысаларын булдырырга, аны начар максатларда кулланмауны контрольдә дә тота белергә тиеш.

Бүгенге журналистиканың иң олы проблемасы – ул үз-үзеңне чикләү, цензура кую. Сүз ирге дәүләт газеталарында да, шәхси басмаларда да бар, Конституция гарантияләгән мөмкинлек белән файдаланучылар гына аз. Аннан соң еш кына барысы да баш мөхәррирдән тора, дигән фикерләрне дә еш ишетергә туры килә. Ә баш мөхәррирләр бу турыда үзләре ни уйлый икән соң?

Шәхси һәм дәүләти матбугат чараларында сүз ирегенең аермасы бармы? Үзләреннән сорарга булдым. «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров сүз ирге булган җирдә матбугат ирге булмыйча кала алмый дигән фикердә тора. Ул үзенең күзәтүләренә нигезләнеп, соңгы 12 ел эчендә генә дә гаммәви мәгълүмат чаралары ирген чикли торган 49 закон актына төзәтмә кертелгәнлеген билгеләп үтә. Ирек ул бөтен нәрсә дә

ярый дигән сүз түгел, аның чикләре булырга тиеш. Журналист фикеренчә, моннан тыш кешенең башында үзенең «ярый-ярамый»лары була. «Әгәр кеше үзенең фикерен азакка кадәр әйтергә курка икән, димәк аның башында цензура бар дигән сүз. Моннан котылу өчен үз өстеңдә эшләргә, профессионал осталыгыңны арттыру өчен күп көч куярга кирәк. Үзең язганны кеше алдында, кирәк булса суд алдында дәлилли аласың икән, матбугат иреге менә шушы була инде, — ди М.Сәфәров. Матбугат иреге бүген генә барлыкка килә торган әйбер түгел, аны булдыру өчен җәмгыятьтә ихтыяҗ булу шарт. Аннан соң акчалы булу – ул әле ирекле булу түгел, дип саный редактор. «Күп очракта шәхси газеталар да укучысы фикере артыннан чаба башлыйлар. Бер уйлаганда, аларның бит үз акчалары бар, дәүләттән бәйсез саналалар. Нигә әле менә башкаларга үрнәк булырдай кыю, интеллект дәрәҗәсе югары булган белемле журналистларны туплап, матбугат оештырмаска»,— ди М.Сәфәров. Күп очракта шәхси матбугатта кешеләрне үзе артыннан иярта алырлык идеология булмый.

Ә шәхси газета мөхәррирләре матбугат иреге турында ни уйлый соң? Илфат Фәйзерахманов Россиядә ирек торган саен кысыла, сүз ирегән чикләү буенча яңадан-яңа кануннар кабул ителә тора дип саный. «Бездә шәхси мәгълүмат чаралары шактый. Әмма сәяси юнәлештә эшләүче һәм сәяси вәзгыятькә анализларны курыкмыйча урнаштыручы татар телендәге басма «Безнең гәҗит» кенә. Калганнар социаль тематикадан чыга алмый һәм аны сәяси дип тасвирламакчы була. Ә без Россия, Татарстан тормышындагы сәяси вакыйгаларны күз уңында тотабыз. Бюджет хисабына яшәүче басмалар да шул тирәдә. Дөрес, тел, милләт турындагы язмалар күренгәли. Ә менә Президентлар югарылыгындагы сәясәткә, бигрәк тә Татарстанга тәнкыйть бәя-анализ юк. Ул безнең басмада гына. Безне урыс телле мәгълүмат чаралары да күзәтеп укып бара. Тәрҗемә ителгән, безгә сылтама биреп, бездән мәгълүмат алган очраклар да җитәрлек», — ди мөхәррир. Сүз ирегән бар дип тә, юк дип тә булмый дип саный. Без шулай ирекле эшли алабыз икән әлегә, ул бар. Безгә беркем күрсәтмә бирми. Бары законнар гына безне күзли. Без беркемгә дә сәяси яктан да, финас ягыннан да бәйләнмәгән. Безнең бәйлелек бары укучыларга. Алар язылсалар, без яшибез, юк икән, юк»,—ди ул.

«Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Мансур Мортазин: «Совет хөкүмәте белән чагыштырганда, сүз иреге бар. Дәүләт матбугатына дәүләт тарафыннан дотация бирелә икән, ул аңа каршы чыга алмый. Бу инде үзеңә эш биргән хуҗаңа каршы чыккан кебек була. Ләкин проблемаларны ипләп-җайлап кына дәүләт газеталары да күрсәтә ала», – ди Мансур Мортазин.

«Мәгърифәт» газетасының элеккеге баш мөхәррире Хөсәен Вәлиәхмәтов фикеренчә, матбугат органы теркәлеп, дәүләт аңа акчасын түләп тора, уставны язып бирә икән, димәк аның таләп итәргә хакы бар. Ленин сүзләре белән әйтсәк, « Җәмгыятьтә яшәгәндә аннан ирекле булу мөмкин түгел», — ди ул. Без чит илдәге татар матбугатын абсолют ирекле булган дип саныйбыз, ләкин аның да үзенә күрә чикләре булган. Суз иреге, матбугат иреге кешенең йөрәгендә булырга тиеш, дигән фикердә тора ул.

Матбугат иреге мәсьәләренә бәя биргән вакытта, укучылар һәм журналистлар , фикерен исәпкә алу өчен сораштыру үткәрдем. Сораштыру өчен 15 гади укучы һәм 15 журналист сайлап алынды. Аларның төрле җирдән булуын, төрле яшьтә, төрле социаль дәрәҗәдәге кешеләр булуын да исәпкә алырга кирәк. Сораштыру нәтиҗәләре буенча журналистларның 9 ы сүз иреге бар дип саный. Алар фикеренчә, бүгенге җәмгыятьтә дә ирекле иҗат итәргә, үз сүзеңне әйтергә мөмкин.Ләкин биредә ирек мәсьәләсен бер яклы гына карау ялгыш булыр иде. Ирек ул киң төшенчә, ул үзенә күрә җаваплылык та сорый. Ләкин ул беркайчан да абсолют була алмый. «Сүз иреге бар, ләкин шул сүзеңне дәлилләрлек документларың кулыңда булырга тиеш. Әле дәлилең һәр әйткән сүзең өчен бер генә дә түгел, ә берничә булырга тиеш, шул очракта сүз иреге бар. Һәр кеше үз сүзе өчен җавап бирә алганда гына сүз иреге халыкка файдага була ала, ә теләсә-кем артыннан гайбәт сату - ул сүз иреге түгел. Менә шул гайбәтне сүз иреге дип аңлаган журналистлар гына сүз иреге юк дия ала торгандыр», – дип үз җавабын исбатлый бер журналист.

Журналистларның 6 сы сүз ирегеН юк дип саный. Ирек төшенчәсе нинди матбугатта эшләвеңә, нинди темаларга язуыңа карап чикләнә. Бигрәк тә район матбугатында зур чикләүләр куелуын искәртеп үтәләр. «Җирле матбугатта эшлисең икән, җирле түрәләрне бик тәнкыйтьләп булмый, мактап кына язасың. Аларга теш кайрый башласаң, юлыңны кисүләре, газетаңны яптырулары мөмкин. Аннан соң кемнәрдер синең газетаңа язылу чорында булышкан булырга мөмкин. Андый кешеләрнең яман якларын белә торып та тешеңне кысып түзәсең, чөнки син аларга рәхмәтле булырга мәҗбүр, шуңа күрә дә андыйлар хакында язсаң да мактап кына яза аласың, ә дөресрәге мактап язарга мәҗбүр буласың», – дип үз сүзләренең дөреслеген исбатлый бер журналист. Моннан тыш, Татмедиа ААҖ һәм редактор үзе дә газетаның чикләрен билгели һәм «ярый-ярамый»ларын булдыра. Сүз иреге мәсьәләләренә килгәндә, укучыларның күбесе (9 укучы) сүз ирегенең барлыгына ышана. Ләкин булган ирек тә тулысынча түгел, күпмедер күләмдә чикләнә ди алар.Ә 6 укучы сүз иреге юк дигән фикердә тора. «Сүз иреге безнен илдә язылган закон буларак кына эшли. Чын тормышта ул чагылмый. Әйтәсе килгән сузләрне 100 процент теләгәнчә әйтеп бетерү безнен илдә мөмкин тугел. Бар да идарәче фикере белән хисаплашырга мәҗбүр»,—дип белдерә алар.

Шушы сораштырулар, редакторлар сөйләве буенча түбәндәге нәтиҗәләрне ясадык. Сүз иреге, матбугат иреге бар, ләкин хәтта демократик җәмгыятьтә дә 100 процент ирек була алмый. Биредә ирек төшенчәсен бер яклы гына алмаска кирәк. Һәр нәрсәнең чиге булган кебек, ирекнең дә чиге булырга тиеш. Ирек ул чикләрне узып, аерым кешеләргә зыян салырга тиеш түгел. Чөнки ул кешенең дә иреге бар.

Ирек булу белән генә дә түгел, үз сүзеңне әйтүдән дә курыкмаска кирәк бит әле. Бу инде беренче чиратта журналистның башындагы «ярый-ярамый»ларына карап билгеләнә. Биредә күпмедер күләмдә кешенең психологиясе, тормышы, яшәү рәвеше һәм белем дәрәҗәсе дә зур роль уйный.

Журналист киң эрудицияле, югары махсус белемле булырга тиеш дип санала. Ул үзенең һәр әйткән сүзе өчен җавап бирә алырлык булырга тиеш.

Шунысы аяныч, сораштырулар буенча халык бик аз укый дигән фикергә килдек. Алдырылган газеталарның саны нибары 1-2 генә. Иң күп укучылар ул өлкән буын вәкилләре, укытучылар һәм гуманитар югары уку йортларында белем алучы яшьләр. Ә бит кеше нинди дә булса фикер әйтерлек дәрәҗәгә җитү өчен, ул белемле, бар өлкәдән дә бераз булса да хәбәрдар булырга тиештер. Ә бүгенге көндә күпләр «укымадым, ләкин минем үз фикерем бар» дигән принциптан чыгып эш йөртәләр. Сораштыруда катнашучыларның кайберләре гомумән матбугат чарасын укымавы турында әйтә. Шул сәбәпле сүз иреге мәсьәләләре турында алар гомумән дә белми булып чыга түгелме соң? Сүз иреге бит әле ул гайбәт сөйләү, моны күрдем, тегене ишеттем дип язу түгел. Күпләр шушы төшенчәләрне сүз иреге дип уйлап ялгыша. Шуңа күрә безгә күбрәк рәсми матбугат укырга, стереотиплардан арынып, тирән фикерләргә кирәк.

Матбугат иреге булсын өчен, ин беренче чиратта аңа ихтыяҗ булу мәҗбүри. Әгәр халык гел сафсата сату, сенсациягә корылган «сары» матбугатка өстенлек бирә, шундагы ялганга ышана икән, сыйфатлы матбугат булудан ни мәгънә. Җәмгыятьне ирек кирәклегенә ышандырырга кирәк.

Матбугат иреге үсеш кичерсен өчен иң беренче чиратта демократик җәмгыять булу зарур. Аннан соң булган законнарның чынлап торып эшләве, бөтен нәрсә дә закон нигезендә тормышка ашырылуы, искергән законнарның үзгәртелүе дә кирәк.

Әдәбият

1. Ворошилов В.В. Журналистика: учебник, 2-е издание. Спб.: Изд-во Михайлова В. А. , 2000. 360 с.
2. Зәйни Р.Л. Журналистиканың хокукый нигезләре: уку ярдәмлеге. Казан: Казан ун-ты, 2011. 120 б.
3. Корконосенко С.Г. Основы творческой деятельности журналиста. СПб.: Знание, СПбИВЭСЭП, 2000 г. 130 с.
4. Прохоров Е.П. Правовые и этические нормы в журналистике: учебник, 2-е изд. М.: Аспект Пресс, 2007. 230с.
5. Прохоров Е.П. Введение в теорию журналистики: учебник для вузов,7-е изд. М.: Аспект Пресс, 2007. 410 с.

«Шәһри Казан» газетасында мәгариф темасының яктыртылышы (2013 елгы саннар мисалында)

Ф.Р.Мостафина, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – Р.М.Галиева,
филология фәннәре кандидаты, доцент)

«Шәһри Казан»ның 2012 елгы саннарын алып карасак, газетада мәгариф темасын даими яктыртып барган тотрыклы сәхифәнең булмавын күрәбез. Аерым хәбәрләр биреп барылган, ә менә анализлап язылган күләмле мәкаләләрне үзәккә алган, шул ук вакытта мәгариф яңалыклары белән дә таныштырган сәхифә чыкмаган. Төрле елларда мәгариф темасын Нәүбәһар Кәбир, Айсылу Имамиева, Азат Юсупов кебек журналистлар яктырткан, ә сәхәфә өчен махсус җаваплы кеше беркетелмәгән булган. Белем бирү темасының даими рәвештә чыгып бармавын да шуның белән бәйләп аңлатырга була.

2013 елда «Мәгариф» сәхифәсе өчен җаваплы итеп корреспондент Фәнзилә Мостафина билгеләнә, сәхифәнең даимилеге ике атнага бер тапкыр бер полоса күләмендә дип билгеләнә. Актуаль темаларга язылган оператив язмалар булганда, сәхифә атна саен да чыга. Мәгариф темасына кагылышлы язмалар тематик яктан туры килгән башка сәхифәләрдә дә басыла. Газета битләрендә белем һәм тәрбия бирү темасын үзәккә алган хәбәрләргә дә зур урын бирелә.

«Шәһри Казан» илдә, республикада һәм аерым алганда башкалада барган мәгариф вакыйгалары белән бер аяктан атларга тырыша. Белем бирү системасын яктыртуны шартлы рәвештә 4 периодка бүлеп карарга була.

1. **Көз.** Чикләрен шартлы рәвештә август ахыры – ноябрь дип күрсәтик. Бу вакытта мәгариф темасында яңа уку елы башлану, уку йортларына кабул итү кампаниясенең төгәлләнүе кебек вакыйгалар, җәйге эшчәнлеккә нәтиҗә ясау үзәктә була. Быел, билгеле булганча, көз башы «Мәгариф турындагы» яңа федераль законның кабул ителүе һәм Россия Фәннәр академиясе тирәсендә барган үзгәрешләр белән дә истә калды. «Шәһри Казан»да телгә алынган ике темага да шактый язма басылган. Мәсәлән, «Өч айдан соң күз күрер» (Шәһри Казан (алга таба – Ш.К.), 2013, 24 сент.) язмасында автор Сөембикә Билалова Мәскәүдәге вәзгыять фонында ТР Фәннәр академиясендә хәлгә ачыклык керткән. Журналист эксперт буларак баш фәнни сәркатип Дания Фатыйх кызы Заһидуллинага мөрәҗәгать итеп, кызыксындырган сорауларына җавап алган.

Мәктәптә законсыз рәвештә акча җыю күренеше «Балам өчен биш мең дә жәл түгел!» (авторы Ф.Мостафина) (ШК, 2013, 29 окт) язмасында яктыртылган. Автор тормыштан да мисаллар китергән, экспертларның фикерен дә сорашкан, побор проблемасы белән күзгә-күзгә очрашкан кешеләрдән дә комментарий алган.

2. **Кыш.** Чикләрен шартлы рәвештә декабрь – март дип күрсәтик. Мәгариф өлкәсендә чагыштырмача тыныч вакыт. Бу чорда күбесенчә нәтиҗәләр ясау, БДИ, фән олимпиадалары, төрле конкурс-бәйгеләр турында язмалар күренә. «Шәһри Казан» газетасы да бу периодта шул юнәлештә эш иткән. Шул ук вакытта укучыда кызыксыну уята һәм бәхәс тудыра торган язмалар да юк түгел. Мәсәлән, Фәнзилә Мостафинаның «Укытучымны атып үтерәм!» (ШК, 2013, 12 дек.) язмасында укучыларның укытучыларга һөҗүм итүләре, аяк чалулары турында бәян ителгән. Автор чит илләрдәге

вакыйгалардан башлап, Россия киңлегенә, аннан эзлекле рәвештә Татарстандагы, аерым алганда Казандагы вәзгыятькә күчә.

3. **Яз.** Апрель – май. Үзәк тема – БДИга әзерләнү. Бу вакытта югары уку йортларында урыннар саны, бәяләр билгеле була, шулай ук студентларның җәйге сессиясе якынлаша, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында Соңгы кыңгырау һәм чыгарылыш кичәләре үтә. Мисал өчен, «Соңгы кыңгырау ничә сум тора?» (авторы Ф.Мостафина) (ШК, 2013, 21 май) язмасында автор бәйрәмнең сәхнә артына күз сала, ягъни тантананың уртача ничә сумга төшәчәген исәпли, төрле район мәктәпләре мисалында күрсәтә. Алисә Сабирова исә «Исерек бантиклар бәйрәме» (ШК, 2013, 21 май) язмасында бәйрәмнең кара якларын ача. Автор укучыны язманың баш исеме белән үк җәлеп итә.

4. **Җәй.** Июнь – августның беренче яртысы. Мәгариф өлкәсендә бу вакытта чын мәгънәсендә кызу урак өсте. Шулай да төп ике тема үзәккә куела – БДИ һәм югары уку йортларына укырга керү. «Шәһри Казан» да бу темалардан читтә калмаган. «БДИны тагын бирер идем!» дип аталган интервьюның (авторы – Ф.Мостафина) (ШК, 2013, 23 июль) герое – 3 фәннән 100 балл җыйган укучы Гөлназ Садриева. Шундый зур уңышка ирешкән кызның җаваплары, киңәшләре газета укучыга да кызыклы, димәк, теманы актуаль дип атарга җирлек бар. Шулай ук югары уку йортларын нәтиҗәлелеккә тикшерү темасы да яктыртылган. «Кара тамга кемгә төшәр?» язмасында (авторы Ф.Мостафина) (ШК, 2013, 17 авг.) автор телгә алынган теманы ачып салган. Аналитик мөхбирнамә жанрында язылган әлеге язмада статистикага да, Казан уку йортлары вәкилләре җавапларына да урын бирелгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Шәһри Казан» газетасы 2013 елда мәгариф темасын даими рәвештә яктыртып барырга тырышкан. Илдә көн кадагында булган темалардан басма «Мәгариф турындагы» яңа федераль закон кабул ителүгә, Фәннәр академиясе тирәсендә барган үзгәрешләргә, югары уку йортларын нәтиҗәлелеккә тикшерүгә, балалар бакчаларына түләү артуга, бердәм дәүләт имтиханнарына үз мөнәсәбәтен белдергән.

«Мәгариф» сәхифәсенә укытучы һәм укучылардан хатлар килеп тора, алар сәхифәдә урын алып килә. «Шәһри Казан»дагы мәгариф полосасына темасын белеп язган журналистлар төрлелеге җитеп бетми, бер-ике автор белән генә чикләнелә. Тагын нәрсә җитми дигәндә, тема тарлыгын атарга кирәк. «Мәгариф» сәхифәсе өчен җаваплы корреспондент тулаем бер өлкәне колачларга тырышса да, урта гомуми белем бирү системасына игътибар күбрәк бирелә, фән, югары белем һәм мәктәпкәчә тәрбия икенче планда кала бирә.

«Шәһри Казан» газетасында мәгариф темасының яктыртылышы» дигән темага тирәнтен фәнни тикшеренү үткәрергә уйлаган кешегә газетада чагыштырып, анализлап карау өчен материал күп. Теманы үстерергә мөмкинлек бар.

Матбугаттагы рекламаның балаларга тәэсире

(балалар матбугаты мисалында)

Р.Р.Садретдинов, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
Сабирова Л.Р.)

Бүген реклама индустриясенең чәчәк атуын һәркайда күзәтергә мөмкин. Чыгып килә торган нинди генә газета-журналны алма, барысы да диярлек реклама белән шыплап тулган. Телевидение эфирының һәр 15 минуты саен ул, ә интернет челтәрендә аны әйтеп тә торасы түгел. Бүген реклама индустриясе ни генә тәкъдим итми дә, үз товарын нинди ысуллар белән генә мактамый!

Реклама өлкәсендә эшләүчеләр балаларга да игътибар юнәлдерә башлады. Балалар рекламасын уенчык тартмасында, китап-дәфтәр тышлыгында, балалар өчен чыгып килә торган газет-журналларда да күзәтергә мөмкин. Балалар рекламасы активлашуны күпләр түбәндәге фикерләр белән дәлилли. Беренчедән, балалар – үзләре сатып алучы, нәрсә генә әйтсәк тә, аларның үз «бюджетлары» була. Икенчедән – теге яки бу әйберне сатып алганда, балалар әти-әниләренә зур йогынты ясый.

Реклама индустриясенең психология фәненнән башка тора алмавын PR өлкәсендә эшләүчеләр күптән инде аңлап алганнар. Бу өлкәдә фәнни эшләр еш эшләнә. PR белгечлеге буенча укучы студентлар өчен кайсы гына уку ярдәмлеген, китапны, дәреслекне алма, реклама психологиясенә аерым бер бүлек бирелгән.

Сатучы, товар җитештерүче, реклама агентлыгы алдында товарны ничек рекламаларга дигән сорау туса, җавап гади – рекламада балаларның үзләрен катнаштыру кирәк. Күп кенә очракларда моннан башка берничек тә булмый. Мәсәлән, балалар өчен эшләнә торган сөт катнашмалары рекламасы сабый һәм ана образыннан башка барып чыкмаячак.

Олыларның күбесе телевидениедәге реклама роликларын карарга яратмый. Бер үк рекламаның күп тапкырлар кабатланып торуы «туенып китү» эффектына китерә. Телепрограмма вакытында рекламаның күплеге һәм бер типтагы сюжетлар кешедә ярсучанлык китереп чыгара.

Ә кечкенә балаларда берөзлексез кабатланып тора торган бер типтагы реклама клипларына ярсу хисе күзәтелми икән. Бер үк телероликны алар күп тапкырлар һәм саекмас кызыксыну хисе белән карарга әзер. 2003 елда «КОМКОН-Медиа» оешмасы тарафыннан үткәрелгән сораштыру нәтиҗәсе реклама тамашачылары аудиториясенең яртысыннан артыгы (52,4%) сабыйлар икәнен күрсәтә. 12 яшькәчә балаларның елына уртача 25 мең реклама каравы расланган. 2 яшьтән 7 яшькәчә балалар телевизор каршында көн дә 2 сәгатькә якын вакытларын уздыралар. Бу аларны рекламчылар өчен җиңел мишень ясый [1].

Президент Путинның политтехнологлары яшьләр белән эшләүгә күп көч түгә. Рунетта «Россия президенты мәктәп яшендәге гражданнарга» дип исемләнгән балалар интернет-ресурсы ачылды. Ел ярым вакыт аралыгында аны

төзүдә югары квалификацияле белгечләр белән берләштән, балалар психологлары да көч куйды. Интернет-ресурсның аудиториясе – 8 яшьтән 14 яшькәчә булган мәктәп балалары [2].

Сайт әкият рухында эшләнгән. Анда илнең конституциясе, президентның фотоальбомы, иллюстрацияләнгән Россия тарихы һ.б. бик күп кызыклы материаллар урнаштырылган. Экскурсияне виртуаль персонажлар – Добрыня Никитин, Ильюша Муромцев һәм Аленушка Попович үткәрә [3]. «Путин һәм балалар» идеясы әлбәттә яңа түгел: Ленин, Сталин һәм башка бик күпләрне искә төшерү дә җитә. Мәктәпләрдә оештырылган пионер-комсомол оешмалары шуның бер мисалы булып тора түгелме соң? Алар күпме буынны бәхетле совет иле идеологиясендә, патриотик рухта тәрбия кылды.

Реклама тексты укучыга өч яссылыкта тәэсир ясый: эмоциональ-хисси, мантыйкый (логик) һәм интеллектуаль. Башта хис-тойгы тудыру чаралары тәэсир итә, аннары аерым хис мантыйкый дәлилләр белән беркетелә, хисси һәм мантыйкый чараларның һәр аерым шәхескә үзенчә йогынты ясарга кирәклеген истә тоту сорала. Чөнки һәр укучы рекламны төрле хисси яссылыкта кабул итә. Нинди халәтләр була? Шатланып куя, кызыксынып китә, аптырап-гаҗәпләнеп ала, күңеле күтәрелеп, очынып-канатланып китә, хәтта илһамлануы да ихтимал.

Шул ук вакытта мантыйкый (зиһени) процесс белән бәйле хис тәэсирләре дә чагыла: кисәтү, өндәү, үтенү, төшендерү, ышандыру.

Бүген күпләрдән: «Татар балалар басмаларында реклама юк ул,» – дигән кискен сүзләр ишетергә була. Мин бу сүзләр белән һич кенә дә килешмим, чөнки татар балалар басмасында реклама бар, булган, булачак. Мин моны үзем «Сабантуй» газетасын, «Салават күпере», «Ялкын» журналларын анализлап инандым.

Төпләнмәләрне карап чыкканнан соң татар балалар басмасындагы рекламаның түбәндәге төрләрен билгеләдем.

1. Белдерү, хәбәр, афиша формасын алган һәм аерым рубрикада, гадәттә, газетаның – икенче, журналның уртадагы битләрендә бирелгән реклама. Бу төргә, мәсәлән, конкурслар турындагы белдерү дә, театр-кинога чакыру да керә. Бу төр мин тикшергән басма матбугатта беренче урынны алып тора. Ул кыска хәбәр рәвешендә, белдерү формасында бирелә. Мәсәлән, «Сабантуй» газетасының 2010 ел, 1 май санында чыккан «Шүрәле килгән! Күреп калыгыз!» дигән белдерү. Исеме үк өндәү билгеләре белән язылган [4]. Аннан берәр чара турында саллы гына мәгълүмат биреп язылган язмалар шактый. Мәсәлән, «Салават күпере» журналының 2010 елның 8 санында чыккан Дю Соли (Кояш циркы) турында [5], «Сабантуй» газетасының 2010 елның 13 февраль санында басылган «Дали» күргәзмәсе турындагы белдерүләр шундыйлардан [6].

2. Реклама газетның төп материалларында, ягъни газетаның үзенең жанрлары (репортаж, интервью, хәбәр, мөхбирнамә, рецензия, мәкалә, очерк) системасында бирелә. Моны «яшерен» реклама дип карарга кирәк. Монда рекламага кыек ишарә ясала, газета жанрлары бу төргә зур мөмкинлекләр ача. Бу яссылыкта өйрәнүгә аерым тукталып китүне мәслихәттер дип саныйм.

Чөнки бу төр мин тикшергән реклама мисаллары арасында икенче урынны алып тора. Чыннан да, газета жанрлары элек тә реклама функциясен үтәп килгәннәр.

Хәбәр жанрларының реклама мөмкинлеге зур. Теге яки бу яңалыкның, аеруча кешеләрнең беренчел физиологик һәм рухи, ягъни көнкүреш, сәүдә, мәдәни ихтыяҗына кагылган яңалыкның беренче булып матбугатта бәян ителеп, шуның аша тәүге тәэсир ясавы зур әһәмияткә ия. Хәбәрнең тиз, оператив җиткерелүе, аз сүзле, төгәл фактлар белән белдерелүе зарур. Аның беренче булып җитәкче орган авызыннан чыгуы, имза белән белдерелүе үтә дә тәэсир итү көченә ия. Мондый белдерүләр газетаның беренче булып караш төшә торган урынына урнаштырыла, төрле төсләр, полиграфик аеру билгеләре белән характерлана. Урын дигәннән, газетаның кайсы бите укучыга күбрәк тәэсир итә дигән сорауга инде 1909 елда ук американ психологы Д.Старг җавап биргән. Ул күләмле газетада иң тәэсир итә торган бит дип беренче һәм соңгы битләрне атый [7].

Мин тикшергән татар басмаларында да әлеге закончалыкны күзәтергә, дәлилләргә мөмкин. Мәсәлән, «Сабантуй» балалар һәм яшүсмерләр газетасы иң беренче биткә бик күп фотолар белән бизәп, берәр мәктәп, чара, музей турында мәгълүмат бирә. Шуңа дәлил итеп, мин бу газетаның 2011 елның 26 март санын китерә алам. Газетаның бу битендә «Ә сез ямьсез принцны яратыр идегезме?» дип исемләнгән авторсыз язма бирелә. Язма, алда әйтеп кителгәнчә, фотолар белән чуарланган. Язма авторы балаларны Татар дәүләт курчак театрының «Алчәчәк» спектаклен карарага чакыра. Шушы язманың ахыргы сүзләре җәлеп итте: «Сез дә Аленушканың сүзләрен кабатлап: – Әтием, миңа Винкс курчагы да, яңа күлмәк тә кирәкми, син мине «Алчәчәк»кә алып бар! – дия аласыз. Театрда сезне сихерләнгән принц көтә.» Монда реклама ярылып ята бит [8]!

«Салават күпере» кебек балалар басмасындагы реклама аерым игътибарга лаек. Бу журнал балаларны яшьтән характерларын формалаштыра, аларга зур тәэсир итә. Монда да мин рекламага бик күп ачык мисаллар таптым. Рекламаны ахыргы биткә урнаштыралар икән дигән фикердә калдым мин. Шуңа дәлил итеп, «Салават күпере» журналының 2011 елның 5-6 санында, иң соңгы биттә (тышлыкта) бирелгән реклама афиша формасын алган, «Мини мисс Татарстан» фестивале турында икән [9]. Шул ук елның 7-8 саннарында басылып чыккан реклама да шул форматта, «Балачак Татарстан китап нәшриятыннан башлана!» дип исемләнгән [10]. Соңгы биттә бирелеп, тулысынча реклама дип әйтерлек белдерүне шушы журналның 6 санында да табарга мөмкин. Бу – «Сабыйлар» балалар үзәге рекламасы [11].

«Ялкын» журналында да ахыргы биттә бирелгән рекламага мисаллар очрады. Ләкин бу мисаллар конкрет, ачык якты төсләрсез, бизәүләрсез, ә фотография форматында чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Яңа гасыр» каналында бара торган «Яшьләр тукталышы» алып баручылары – Венера белән Алмаз матур итеп фотога төшкәннәр, тапшыруның чыгу вакытын беркеткәннәр, «Синең тормышыңа – яңа сулыш» дип тә өстәргә онытмаганнар[12].

Сүз уңаенда әйтик, газетаны ачып караганда, караш иң башта уң якка, өченче биткә төшә икән. Ә аерым битне алсак, аның иң игътибар итә торган өлеше – өстәге ярты икән. Бу уңайдан «Сабантуй» газетасында белдерү форматында чыккан хәбәрләр икенче биттә урын ала, ләкин аларга аерым рубрика багышланган. Ә «Ялкын» журналында реклама урта битләрне били.

Интервью жанры реклама максатында бик тә кулай. Ул яңалыкны иң ышанычлы чыганактан ишеттерү; икенчедән, яңалыкның «хуҗасы» үзен тулысынча күрсәтә алуы, шулай ул фирмасын да, эш алымнарын да рекламалый алуы белән әһәмиятле. Шул ук вакытта ул, темадан читкә китеп, үзен бик мактау белән мавыга алмый; максаты бит конкрет яңалыкны – вакыйганы күрсәтү.

Реклама бирергә сәләтле тагын бер жанр – *репортаж*. Монда да шактый мисалларга юлыгырга туры килде. Мисал итеп, «Сабантуй» газетасының 2011 елның 17 сентябрь санының 1 битендә басылган материал – Ф.Вагыйзованың «Совет мәктәбе» дигән язмасын карап китәргә була. Бу язмада Казанда әле күптән түгел генә ачылган «Социалистик көнкүреш» музеена реклам яшеренгән [13].

«Ялкын» журналының 2010 елның 3 санында чыккан «Бокс» язмасын да (авторы Р.Сабирова) репортаж жанры кысаларына кертеп карарга кирәктер, мөгаен. Монда автор бокс спорт төре турында мәгълүмат бирә, тарихына, уен кагыйдәләренә игътибар итә. Тик авторның төп максаты – Казан шәһәренең Ю.Фучик урамы 79 А йортында урнашкан «Бокс» клубына реклама ясау. Язма журналның 29 нчы битенең уң ягының өстәге өлешендә урнашкан «Бокс» клубының адресын һәм телефонын биреп, максатына ирешкән дип уйларга кирәк авторны [14].

3.Реклама турыдан-туры бирелә. Бу вакытта ул плакат формасын ала. Моңа да төрледән-төрле мисаллар байтак табылды.

Мәсәлән, «Сабантуй газетасында бу «Сөенче» нәниләр өчен кичке әкият, «Күчтәнәч» тапшыруы графигы, дәү әни һәм дәү әти фотосы [15] «Яшьләр тукталышындагы» Венера белән Алмаз, аларның «Тормышка яңа карашлары» плакатлары [12].

«Салават күпере» журналында бу төр реклама еш кулланыла. Ул плакат, фото төсмерен алганга күрә актив. Билгеле булганча, балалар текстларга игътибар бик итми, аларга матур бизәкле, ачык төсле, якты позитив рәсемле, танылган персонажлар кулланылган реклама кирәк. Мәсәлән, «Салават күпере» үзе үк шундый образ уйлап тапкан. Ул да булса – Шүркә дигән яңа герой, рус Лунтигының игезәге дип тә атап була.

«Сабантуй» газетасын караганда шуңа тап булдым: 2011 елның 21 май санында реклама дигән рубрикада (8 нче бит) «Национальный негосударственный пенсионный фонд» реклама-хисабы урын алган, шушы ук реклама газетаның берничә саны буенча чыгып бара. Бу рекламаны караганнан соң, үзеннән үзе «Бу нигә кирәк?» дигән сорау туа [16].

Татар балалар басмасындагы рекламның сыйфат дәрәҗәсенә, бизәлешенә тел-теш тидерерлек түгел. Барысы да югары дәрәҗәдә эшләнгән. Бу уңайдан «Салават күпере» журналы бигрәк тә алга киткән.

Бүгенге тормышыбызда реклама инде ныклап урнашты. Хәзерге вакытта без үзебезне рекламасыз калсак, төссез дөньяга килеп эләккән кебек хис итәр идек. Әмма бигрәк тә балалар рекламасын ясаганда, игътибарлы булсак иде, балаларның якты киләчәге үзебездән генә тора бит.

Чыганаклар

1. Сороченко В. Детская реклама / URL: http://psyfactor.org/recl15.htm (Дата обращения: 10.02.2014).
2. Пичурин И.И., Обухов И.В., Эриашвили Н.Д. Основы маркетинга теория и практика: учеб. пособие для студентов вузов, обущающихся по специальностям «Коммерция (торговое дело)», «Маркетинг». М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2012. 286 бит.
3. Детям. Президент России гражданам школьного возраста / URL:http://www.uznai-prezidenta.ru/
4. Шүрәле килгән! Күреп калыгыз // Сабантуй. 2010. 1 май.
5. Дю-соли циркы – тылсым дөньясы // Салават күпере журнал. 2010. №8.
6. Дали // Сабантуй. 2010. 13 февр.
7. Панкратов Ф.Г., Баженов Ю.К., Шахурин В.Г. Основы рекламы: Учебник. М.: Издательско-торговая корпорация «Дашков и К», 2006, 461 бит.
8. Ә сез ямьсез принцны яратыр идегезме? // Сабантуй. 2011. 20 март
9. Мини мисс Татарстан рекламасы. «Салават күпере» журналы. 2011. №5-6.
10. Балачак Татарстан китап нәшриятыннан башлана рекламасы. «Салават күпере» журналы. 2011. №7-8.
11. Детский центр «Сабыйлар» рекламасы. «Салават күпере» журналы. 2011. №6
12. Яшьләр тукталышы. Венера һәм Алмаз. Синең тормышыңа – яңа караш рекламасы. «Ялкын» журналы. 2010. №2
13. Вагыйзова Ф. Совет мәктәбе // Сабантуй. 2011. 17 сент.
14. Сабирова Р. «Бокс» // Ялкын. 2010. №3
15. Сөенче – нәниләр өчен кичке әкият рекламасы.«Сабантуй» газетасы. 2010. 16 гыйнв.
16. Национальный негосударственный пенсионный фонд рекламасы. «Сабантуй» газетасы. 2011. 21 май.

Матбугатта журналист тикшерүе жанры

Н.Г.Сөнгатова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты,

доцент Р.Л.Зәйни)

Без егерме беренче гасырны мәгълүмат заманы дибез, шуңа да укучыга мәгълүмат җиткерү аерым бер осталык таләп итә. Кызыксындыру өчен төрле жанрларга мөрәҗәгать итсәң, тагын да яхшырак.

Мин барлап чыккан «журналист тикшерүе» дигән җанр энциклопедик сүзлекләрдә юк. Әмма журналистиканы аннан башка күз алдына китереп булмый. «Журналист тикшерүе» атна саен төрле газета битләрендә басылып чыга, аудитория аны зарыгып көтеп ала һәм бик теләп кабул итә.

Әлеге жанрны мин шулай ук «халык өчен эшләүче жанр» дип әйтер идем, чөнки күпчелек басмаларда журналистлар нәкъ менә гади халык тормышын тикшерәләр, халыкка ярдәм итәләр.

Россия журналистикасы тарихында хезмәт эшчәнлеге белән бәйле рәвештә берничә журналистның гомере дә өзелде. Шулардан иң билгелеләре – Д. Холодов, А.Политковская.

Журналист тикшерүе хокук саклаучылар алып барган тикшерүләрдән аерыла. Тикшерүчеләр башта берничә төрле фараз билгелиләр һәм, шулар арасыннан берсенә тукталып, аның дөреслеген тикшереп, закон нигезендә гаеплеләрне табалар. Журналист та тикшерүче кебек эш итәргә мөмкин. Ләкин ул соңгы сүзне әйтми, гаепләү актын язмый. Журналистның төп максаты – күренешкә яисә билгеле бер кешегә карата игътибарны җәлеп итү, укучыны, радиотапшыру тыңлаучыны яки телевизор караучыны уйланырга мәҗбүр итү.

Мин «Ватаным Татарстан» газетасында журналист тикшерүенә караган язмаларны карап китәргә телим. Бу газетада журналист тикшерүенә караган язмалар күп чыга, алар төрле темаларны үз эченә ала. Мөлкәт бүлешә алмауның бер мисалы – «Бәрәкәтсез бүләк»тә 2012 нче елның 7 нче декабрендә Чулпан Хәйруллинаның оста каләме ярдәмендә чыкты.

Кызлары белән улы әнисенең фатирын бүлә алмыйлар. Нина Степановна – Бөек Ватан сугышы инвалидының тол хатыны, торыр урыны юк, бер-бер артлы дүрт кызында тора. Бу турыда кызларының берсе редакциягә хат юллый. Журналист аның белән элемтәгә керә. Ч.Хәйруллина каршы як – әбинең улы Юрий белән дә әңгәмәгә кереп, аның авызыннан чыккан сүзләрне газета битләрендә китерә. Газета укучы нәтиҗәне үзе ясый, кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнлеген үзе билгели.

Минемчә, низагъ уңышлы тәмамланырга тора. Бөтен аңлашылмаучанлыкларга нокта куелыр кебек. Язма азагында исә Ч.Хәйруллина газета юристы Р.Туктаровтан «Бүләк итү карарын үзгәртеп буламы?» дигән соравына җавап ала.

Шулай итеп, автор ызгышка катнашы булган кешеләр белән сөйләшеп, суд карары белән танышып, юристтан рәсми җавап алып, журналист тикшерүенә караган әлеге язмасын бик уңышлы башкарып чыккан. Аны укыганнан соң, беркемдә дә сорау тумагандыр. Чөнки бирелергә тиешле сорауларга бөтен җаваплар да мәкаләдә ярылып ята. Туганнар арасындагы аңлашылмаучанлыкка да шушы урында нокта куелыр дип уйларга җирлек бар.

Гөлгенә Шиһапова берничә журналист тикшерүе үткәргән. 2012 елда аның гади бер яшь хатын язмышына караган 3 материалы дөнья күрә: 25 нче октябрьдә «Тормыш җайланса да, әнине эзләмәячәкмен», 2 нче декабрьдә ««ВТ» укучылары битараф калмады», 7 нче декабрьдә «Тормыш җайланса да, әнине эзләмиячәкмен – 2».

Казахстан якларында туган Мария 13 яшьтән әтисез кала. Әнисе шешә белән дуслаша. Казанда яшәүче әбиләре аларны үзләренә чакыра. Ләкин әби үлеп китә, әни кеше исә йорттагы өлешне сата. Мария шулай итеп урамда кала. Һәм үз көнен үзе күрә башлый. Бер-бер артлы ике бала таба, ике ир белән яшәп карый. Биектау районы Тәберде Чаллы авылына кайтып, салкын йортта, ике нәни нарасые белән ач-ялангач яшәүче Марияны Гөлгенә үз күзләре белән күреп кайта. Беркем дә ярдәмгә ашыкмаган. Газетада басылган язмадан соң гына боз урыныннан кузгала. Г.Шиһапова район социаль яклау бүлегенә шалтыратып, әлеге гаиләгә тиешле барлык ярдәмне ачыклый һәм аны бирдерүгә ирешә. Әлеге материалга ике мәртәбә кире кайтылып язылган, бу үз чиратында авторның битараф булмавы, геройның тормышы белән кызыксынып торуы турында сөйли.

Өч материалны да балалар белән төшкән фотолар бизәп тора. Беренчеләрендә Мария бер баласы белән генә төшкән булса, соңгысында ике баласы белән төшкән фоторәсем балкый. Чыннан да балкый, Мариянең һәм аның балаларының йөзенә бәхет чаткылары сирпеп чыккан!

2012 нче елның 8 июнендә «Ватаным Татарстан» газетасында «Газета кая югала?» дигән язма чыга. Беренче биттә чыгуы аның бик мөһим, актуаль мәсьәлә күтәрүен күрсәтә. Гөлгенә Шиһапова әйтүенчә, соңгы вакытта һәркөн диярлек редакциягә шалтыратып, әбүнәчеләр газета соңарып килүгә, кайбер битләре «югалып» калуга яки бөтенләй килмәүгә зарланалар икән.

Журналист тикшерү эшен шушы көннәрдә генә шикаять килгән районның почта бүлеге җитәкчесенә шалтыратудан башлый. Башка районнарда эшнең торышын ачыклау, чагыштырып карау өчен Гөлгенә Шиһапова икенче район җитәкчесе белән элемтәгә керә. Биредә дә нәкъ шушы ук хәл икән. Бераз тынып торганнан соң, әлеге мәсьәлә янәдән күтәрелә. 23 ноябрьдә шулай ук беернче биттә «Ватаным» кая киткән?» дигән мәкалә басылып чыга. Бу юлы әлеге эшкә икенче журналист – Фәния Әхмәтҗанова алына. Ул газетаның атна саен чыгуы, бәйрәмгә бәйле рәвештә графиктан тайпылса да, аудиториягә хәбәр ителүе турында яза.

Газета югалуы гадәти хәлгә әйләнеп бара. Бу юлы да, эш сәгате тәмамлануга кармастан, редакциягә шалтыратып, Балык бистәсе районында газета югалуы турында җиткерәләр. Журналист район элемтә начальнигы Илсур Катиев белән элемтәгә керә. Ул үз чиратында үз районнарында газетаның кая югалуын ачыклый, адресатка җибәрә.

Журналист исә тикшерүен дәвам итеп, «чылбыр» буенча китә. Газетаның кайда югалып калуын табарга тырышып, Балык бистәсе филиал мөдиренә барып җитә. Венера ханым әлеге хәл турында белешермен дип кала. Шундук Фәния Әхмәтҗанова Кече Әшнәк хат ташучысы белән элемтәгә керә. Ахыр

чиктә журналист бу мәрәкәгә нокта куюга ирешә. Бер кечкенә генә хата әбүнәчегә һәм «ВТ»га зыян салуын ачыклый. Мондый хәлләр кабатланмасын, җитешсезлекләргә каршы көрәшергә җиңелрәк булсын өчен, аудиториядән газета битләрендә басылып чыккан анкетага җавап бирүләрен сорый.

Югарыда китерелгән язмаларга таянып, шуны әйтеп була: «ВТ»да журналист тикшерүенә караган язмалар еш басыла. Аларның һәрберсе ныклап тикшерелгән, төрлечә дәлилләнгән.

Күргәнебезчә, журналист тикшерүе җанрында иҗат итү журналисттан тирән белем, зур тырышлык, җаваплылык, төгәллек таләп итә. Үзенә кирәкле фактларны туплау, тикшерү өчен күп урыннарда булырга, төрле кешеләр белән очрашырга, документлар өйрәнергә кирәк. Ә кайбер материалларны эшләр өчен атналар гына түгел, айлар буе да эзләнергә туры килә. Моның өчен вакыйганы күзәтеп, проблеманы тулысынча чишкәнче язган темага кабат- кабат әйләнеп кайтырга, берничә язма әзерләргә туры килә.

Күргәнебезчә, журналистка тикшерүен башкарып чыгар өчен язма геройлары, аларга каршы як вәкилләре белән очрашып сөйләшергә, үзе күргәннәрне-ишеткәннәрне җентекләп язып чыгарга кирәк. Фактларның дөреслеген тикшерер өчен, төрле оешмаларга сорау җибәрмичә яки җитәкче урында утыручы рәсми затлар белән дә очрашып сөйләшмичә мөмкин түгел.

«Ватаным Татарстан»да журналист тикшерүенә караган язмалар даими рәвештә басыла. Татар матбугатында әлеге жанрдагы язмалар гадәттә газета укучыларыннан килгән борчулы хатлардан соң «туа». Шуңа да халык аларны яратып укый. Әлеге язмаларның ярдәме мәкалә героена гына түгел, ә нәкъ менә шундый ук проблемалы башка кешеләргә дә катлаулы низагны чишеп чыгу юлларын күрсәтә дип әйтергә мөмкин. Чөнки һәркемнең дә журналистларга мөрәҗәгать итәргә кыюлыгы җитми.

Экологик проблемаларны яктыртуда аналитик жанр мөмкинлекләрен куллану үзенчәлекләре

К.Ш. Хәсәнова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Л.Зәйни)

Аналитик жанр мөмкинлекләрен нәкъ менә экологик проблемаларны яктыртканда куллануны тикшеренергә алынуыбызның сәбәбе шул: бүген экология торышы глобаль проблемалар рәтендә тора. Кешенең сәламәтлеге турыдан-туры әйләнә-тирә торышы белән бәйләнгән. Экология турындагы мәгълүмат безнең иң мөһим инстинктлар – яшәү, исән калу инстинктына кагылганга, аны халык җитди кабул итә. Экология темасы хакында гади хәбәр белән генә чикләнергә ярамый, ул үзеннән-үзе аналитика таләп итә. Әгәр дә журналистлар экологик проблема турында кыска хәбәр язып кына чикләнә икән, укучы әлеге вакыйганың кешеләр өчен ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен белми

дә кала. Гаммәви мәгълүмат чараларында экологик проблемаларны ешрак яктыртырга кирәк – экологик журналистика булырга тиеш, дигән сүз бу. Бигрәк тә 2013 ел федераль һәм республика дәрәҗәсендә Әйләнә-тирә мохитне саклау елы дип игълан ителгәч, фәнни хезмәтнең актуальлеге арта.

Проблема дигәч тә, күз алдына аналитик жанрлар килеп баса. Аналитика экологик проблеманың кешелек өчен әле бик билгеле булмаган яисә игътибар читендәрәк калган якларын ачыкларга, аның чишелеш юлларын эзләргә һәм күрсәтергә ярдәм итә. Экология проблемаларын яктыртканда нәкъ менә аналитик жанр үзенчәлекләрен тикшерүебез шуңа бәйле. Әлеге үзенчәлекләрне аңлатканчы, экологик теманың матбугатта яктыртылыш дәрәҗәсенә тукталып үтүне урынлы дип саныйбыз.

Бүгенге вәзгыятькә күз салсак, татар матбугатында хәзер инде күпмедер дәрәҗәдә экологик проблема хакында хәбәр итеп кенә калмыйча, аның чишелеш юлларын эзләгән язмалар да урын ала башлады. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, әлегә бик сирәк. Шунысы да шатландыра әле. Чөнки моннан берничә ел әлек кенә экология проблемалары игътибардан читтә кала барды. Хәзер исә экологларның гына тугел, сәнәгатьчеләр, җитештерүчеләр, иң мөһиме, республика җитәкчелегенең дә моңа битараф түгеллеге сизелә. 2012нче елда билгеләнгән «Санитар-экологик чисталык икеайлыгы – 2012» операциясе булганга, безнең тикшеренү объекты итеп алынган күп кенә аналитик мәкаләләр көнкүреш калдыклары, тиешсез урыннарда оештырылган чүплекләр, ул җирлекләрне чүптән арындыру һәм ул чүпләрне эшкәртү яки бөтенләй юкка чыгару турындагы сорауларны күтәреп чыга.

«Intertat.ru» сайтының район газеталары һәм «Шәһри Казан» газетасына кушымта булып килүче «Атна вакыйгалары» газетасыннан һәм «Ватаным Татарстан» газетасында басылып килүче «Яшел бишек» махсус экология кушымтасындагы аналитик жанрда иҗат ителгән язмаларны тикшерергә алынуыбызның сәбәбе татар матбугатында экология темасын яктыртып язылган аналитик язмаларның башка газеталарда урын алмавы белән аңлатыла. Һәрбер матбугат чарасында да экологияне яктыртучы рубрикага аерым урын бүлеп бирелми. Татар басма матбугаты арасыннан «Татарстан яшьләре» – яшьләрнең иҗтимагый-сәяси газетасы экологиягә кагылышлы катлаулы проблемаларны күтәреп чыкмый. «Шәһри Казан» газетасында «Экология» рубрикасы бар. Анда ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының яңалыклары, хәбәрләр даими басылып килсә дә, экологик язмалар жанр, тема төрлелеге ягыннан бик аксый, кызыклы мәгълүматлар, проблемаларны тикшереп язылган аналитик мәкаләләр юк.

2012 ел дәвамында «Яшел бишек» һәм «Атна вакыйгалары»нда басылып чыккан экология темасын яктырткан язмаларда мөрәҗәгать ителгән аналитик жанрларның мөмкинлекләренә, үзенчәлекләргә нигезләнеп, без аларны өч аспектка бүлеп карадык: экологик язмаларда текст төзелешендәге үзенчәлекләр, аналитик жанрның теоретик методлары һәм тел чараларының кулланылыш дәрәҗәсе.

Текст төзелешендәге үзенчәлекләрдә, барыннан да бигрәк, үзенчәлекле баш исем, кызыклы лид, тезис китерү, текст эчендә кечкенә темаларга бүленү, күтәрелгән проблеманың торышын күзәтеп, газетаның берничә санында яктыртып баруны анализладык. Үзенчәлекле баш исемгә килгәндә, экология темасын яктыртып язылган аналитик язмаларның күбесе ике башисемле булалары белән үзенчәлекле. Без беренче һәм төп башисем дип билгеләгән өлеше укучыны язмага җәлеп итү өчен кызыксындыручы башисем булса, икенчесендә язманың эчтәлеген чагылдыру күзәтелә. Мәсәлән, «Чүптән «кәнфит» ясар чак «Республикада калдыклар эшкәртү системасын җайга салмакчы булалар». Башисемдә шулай ук сорау, тойгылы җөмләләр, антитезалы сүзтезмәләр, укучыга мөрәҗәгать итү, киңәш бирү, мәкаль куллану, язма ахырында ясалган нәтиҗәне башисемгә чыгарган очраклар да күзәтелде; кызыклы лидлар да җитәрлек. Бу журналистның үз тормышыннан алынган күренешләр, шәхси уйланулары булырга мөмкин. Безнеңчә, экологиянең катлаулы тармакларына, төрле проблемаларга басым ясалган язмаларны укучыга ят булмаган, аңлашыла торган күренешләр белән башлап җибәрү укучы тормышына тагын да якынаю өчен эшләнелә. «Хакимият компенсация түләмәс өчен, безнең акрынлап үлеп беткәнне көтәдер ахыры», - дип саный Түбән Каманың сәнәгый үзәге янындагы Алан һәм Мартыш авыларында яшәүче халык» дип башланып китә «Казлар кырыла, ә кешеләр яши» («Атна вакыйгалары») язмасы. Кереш өлештә укучыны саннар белән шаккаттыру, язманы кемдер сөйләгәннәр белән башлап җибәрү, кереш өлештә үк фикер каршылыгын күрсәтү яки язманы берәр кызыклы тәкъдим белән, халыктан ишетелгән моң-зар белән башлап җибәрү очракларын күзәттек; текст эчендә кечкенә темаларга бүленүгә килгәндә, аналитик язма күләме, колачлаган мәгълүматы, ярдәмче темалар һәм вак проблемалар белән зур була. Белгеч булмаган кеше өчен аны аңлау читен. Шуңа да бүген аны текст эчендә кечкенәрәк текстларга бүлеп, кечкенә темаларны аерып язалар. Безнең фикеребезчә, болай эшләгәндә укучыга аңлау җиңелләшә. Журналист Чулпан Хәйруллина «Чүп һаман күп әле» («Ватаным Татарстан») дигән зур аналитик язмасында шушы алымга мөрәҗәгать итә: «Чүп әрҗәсе генә куясы бит», «Чүпле башкала», «Әлмәт - «5», Бөгелмә - «2»!» кебек башисемнәр кечкенә темаларны аңлата. «Үз агачыңны утырттыңмы әле?» («Ватаным Татарстан») язмасында акция кысаларында уздырылган чараларның исемнәре белән, һәрберсенә аерым анализ ясалган: «Милли урман утырту көне», «Әтидән – балага», «Яшел рекорд» дип атала алар; күтәрелгән проблеманың торышын күзәтеп, газетаның берничә санында яктыртып баруга Әлфия Тимериевадан бер мисал: вакыйгаларның хронологиясен хәтта язмаларның баш исемнәреннән үк күреп була: «Казлар кырыла, ә кешеләр яши» («Атна вакыйгалары») – сәнәгый үзәкләрнең халык тормышына куркыныч тудыру проблемасын күтәреп чыга, «Һаваны кем пычрата, шул түләсен» – Алан һәм Мартыш халкына Түбән Кама заводларының 350 миллион сум күләмендә акча түләргә тиешлеге, ләкин аларның түләмәс өчен баш күтәрүе турында һәм «Йөк урынныннан кузгалды» («Атна вакыйгалары») – журналист күченүчеләрнең яңа йортларын тиешле

вакыттан соң 5 ел үткәч кенә алачакларын хакындагы проблеманы күтәреп чыга. Бер проблеманың чишелеше газетаның өч санына сузылган.

Экологик язмаларда аналитик жанрның теоретик методларына без экологик проблеманың сәбәпләрен ачыклау, шуннан чыгып, текстта тезислар, аргументлар, автор бәясе булуны керттек. Биредә шулай ук танып-белүнең бөтен методлары да киң кулланылганлыгын ачыкладык. Алар – детальләштерү; аналогия буенча чагыштыру; бәя бирү; факт белән эш итү; белгеч фикерен китерү; тарихка мөрәҗәгать итү; мисаллар китерү; проблемадан чыгу юлларын, китерәчәк нәтиҗәләрен күрсәтү; язманың темасы кызыклы булуны автор-журналистның үзе үк әйтеп узуы; журналистның тикшерүләр, санау, аңлату эшләрен башкаруы; фаразлау; гомумиләштерү. Экологик язмаларда материалны өйрәнүнең төгәл, ачык күренеп торган чаралары кулланылган: укучыда инде булган мәгълүматка таянып, катлаулы күренешне гади юллар белән аңлатуга игътибар иттек. Язманың темасы кызыклы булуны автор-журналист үзе үк әйтеп узган очраклар белнә очраштык: «Бүген республиканың бигрәк тә сәнәгать тармагы киң үсеш алган районнарда яшәүчеләрне чиста су белән тәэмин итү проблемасы аеруча калку тора. Сыйфатлы суның сәламәтлеккә турыдан-туры тәэсирен исәпкә алганда, бу бигрәк тә актуаль» («Алга китеш бар», «Ватаным Татарстан»). Аналитик жанрдагы экологик язмаларда проблеманың сәбәбен, аннан чыгу юлларын, ул китерәчәк нәтиҗәләрне күрсәтү төп өлешләр булып тора.

Журналист аналиктик жанрда иҗат иткәндә, туган телгә хас шәхси үзенчәлекләрен белергә, сүз уйнатуга сәләтле булырга тиеш. Аналитикада тел чараларын куллану дигәндә, барыннан да элек образлы-экспрессив сөйләм, вакыйгаларны күз алдына китереп бастырганда шартлылык куллануны күздә тоттык. Аналитикада телнең образлы чараларын дөрес итеп куллану фактның дөреслеге белән чикләнгән образлар, вакыйгалар кертелгән текст язуга китергән. Экологик язмаларда тел чаралары дигәндә, текстта, барыннан да элек, риторик сорау, тойгылы җөмләләр, халык сөйләмен, ирония, литота, гипербола, метонимия, антитеза, мәкаль-әйтемнәр һәм фразеологизмнар куллануны күздә тоттык. Язманы җанландырып җибәрү максатыннан, халык сөйләмен куллану очрагына бер мисал: «Хакимият компенсация түләмәс өчен, безнең акрынлап үлеп беткәнне көтә ахры». («Казлар кырыла, ә кешеләр яши» (А.в.). «Ул суда йөзгән казлар озак та үтми аягын суза» («Һаваны кем пычрата, шул түләсен», А.в.). Болай язу халыкка якынаю, укучыны катлаулы аналитик язмага җәлеп итү, ышандыру өчен кулланылган. Метонимиягә бир мисал: «Су түләмә тарата?» (А.в.) дигән язмада үләт базы - «хайван зираты» дип бирелгән. Фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр куллану да аналитик язманы җанландырып җибәрүгә хезмәт итә.

Фәнни анализ барышында без өстәмә чараларны аерып чыгардык. Алар түбәндәгеләр: укучыга турыдан-туры тәэсир чараларыннан укучының тоемлавына басым ясау, проблеманың җитдилегенә ышандыру, шул ышанудан чыгып уйландыру, аңа киңәшләр бирү, тәҗрибә, мисал аша үрнәк күрсәтү,

халык яклы булып, җитәкчелекне гаепләү, үзең катнашуы эффекты, автор мине h.б.

Экологик теманы аналитик жанр ярдәмендә яктырту үзенчәлекләреннән чыгып, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

- 2012 елны экология темасын яктырткан аналитик язмаларның темасы су һәм һава экологиясе белән бәйле;

- без күзәткән язмаларда экология темасын яктыртканда аналитик жанрның барлык мөмкинлекләре дә кулланылган;

- предметны тикшерүнең текст төзелешендәге, теоретик һәм матур әдәбият методларына мисаллар китереп, экологик язмаларда аналитик жанрда иҗат итү методларының барысы да иркен кулланылган дигән фикерне дәлилләдек;

- әлеге методлар арасында аеруча да еш кулланылганнары, әлбәттә инде, теоретик методлар. Бу аналитик жанрдагы язмаларның характер үзенчәлеге белән аңлатыла: проблеманың килеп чыгу сәбәпләрен, аның чишелеш юлларын, киләчәктә китерергә мөмкин булган нәтиҗәләрен, алга таба үсешен күрсәтмәгән язма аналитик язма була алмый!

- экология темасын яктыртканда, күп очракта аналитиканың мөхбирнамә һәм мәкалә жанрлары кулланылган.

Экология проблемасын бер генә ведомсто хәл итә алмый. Чөнки ул тормышның бөтен өлкәләренә дә кагыла. Ә журналист шул өлкәләрне, моның өчен кемнең җаваплы булуын ачыклый. Ул экологик проблеманы чишә алмый, ләкин сүз, җөмлә ярдәмендә әнә шул чишелеш юлларын ачыклауга ирешә ала. Экология турындагы материалның үзенчәлегенә, проблемаларның җитди һәм катлаулылыгына бәйле рәвештә, журналистларны әзерләгәндә экологик махсуслашу да бик урынлы булыр иде, дип саныйбыз!

МӘГЪРИФӘТЧЕ ЖУРНАЛИСТЛАР МИРАСЫ

Сәлах Атнагулов иҗатында мәгариф темасы

Р.С.Әхмәтвәлиева, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
А.Ф.Галиәхмәтова)

Репрессияләнгән журналист, мөхәррир, сәясәтче, галим Сәлах Атнагуловны бүгенге көндә белсәләр дә, әдәбият юнәлешендә вульгар социологизм тарафдары буларак кына беләләр. Шуңа күрә Атнагулов турында мин беренче чиратта күләгәдә калган шәхес, дияр идем. Ул, дөрестән дә,

күпкырлы, шактый катлаулы шәхес булган. Атнагулов мәгариф белән таныш кына түгел, ә аның эчендә кайнаган кеше. Ул педагогика институтында мөгаллим була, татар әдәбияты тарихын укыта. Журналист буларак, аның 15 еллык стажы булган. Республикабызның күп кенә газет-журналларында редактор вазыйфасын да үтәгән.

Журналист буларак та ул үз мәкаләләрендә мәгариф темасына шактый мөрәҗәгать итә, үз заманына күрә актуаль мәсьәләләрне күтәрә. Аның тел мәсьәләсенә кагылышлы кайбер язмалары, фикерләре әле дә актуальлеген югалтмаган. Әмма мин Атнагуловның безнең өчен әһәмиятен күрсәтәсем, аның язмаларының тарихи чыганак, мәгарифебезнең үсешен, бүгенгесен аңлау өчен кыйммәтле хезмәт булуын ассызыклыйсым килә. Чөнки Атнагулов үзе дә мәгарифкә кагылышлы хезмәтләрендә бер яктан тарихны искә алса, икенче яктан үз заманына мөрәҗәгать итә. Алга таба әлеге ике юнәлештәге язмаларга тукталырбыз.

Кыскача билгеләп узсак, журналистлык эшчәнлеге аның сәясәт кырында башлана. Сәлах Атнагулов 1917-1919 елларда Уфада «Кызыл яу», «Кызыл юл» газеталары редакторы, 1920-1921 елларда Казанда Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларның Үзәк бюросында, Мәскәүдә «Эшче» газетасында, аннары Казанда «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы, «Гажур» нәшриятының җаваплы редакторы, Галимҗан Ибраһимов авырып киткәннән соң Татарстан Мәгариф комиссариаты каршындагы Академик үзәкнең җитәкчесе, В.И.Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү һәм аларны бастырып чыгару өчен төзелгән һәм шулай ук бик җитди, җаваплы комиссиянең рәисе була.

Казанда ул иҗтимагый эшләрдә актив катнашуы белән бергә, «Татарстан» газетасы, «Безнең юл», «Чаян», «Кызыл шәрык яшьләре», «Җитәкче», «Мәгариф», «Яңалиф», «Фән һәм дин» журналлары битләрендә актуаль мәсьәләләргә күп кенә мәкаләләр яза.

Сәлах Атнагулов «Татарстан» газетасының редакторы булып та эшли. «Кызыл яшьләр» газетасының иң беренче саннарын чыгаруда да актив ярдәм күрсәтә.

Атнагулов яшәгән чорда тел өлкәсендә, аның кулланылышында зур үзгәрешләр була. Иң беренче чиратта, 1917 елгы революцияне әйтеп китәргә кирәк. Атнагулов фикеренчә, революция татар теленә уңай тәсир ясый, аны киңрәк куллану өчен уңай шартлар тудыра. «Революциягә чаклы татар теле рәсми оешма һәм учреждениеләрдә бөтенләй дә кулланылмый, тик телдән аңлату кирәк булган чакта гына тәрҗемә ителүе мөмкин таныла һәм йорт-гаилә теле булып кына исәпләнә иде», – дип яза Атнагулов «Татарстан» журналының 1929 елгы 1 санының оттискысында [1]. Әлеге мәкаләдә Атнагулов вакытлы матбугат теле булу ягыннан, татар теле берничә йөз еллар гарәп, фарсы телләре аркасында үзлеген югалта язуга барып җиткән дип әйтә. Мисалга, 1905 елга чаклы басылган әдәбиятның телендә 75-80% гарәп-фарсы сүзләре булуы турында яза ул. Җәдитчелек кузгалганга чаклы татар теле татар-мөселман мәктәпләрендә дә укытылмаган һәм кирәк тә саналмаган, ди Атнагулов. Галим

Октябрь революциясенә килеп кергәндә дә татар теле, матур әдәбият дәреслекләренең генә урта тип мәктәпләргә чаклы күтәрелүе, ә башка тип дәреслекләрнең исә башлангыч мәгълүматтан уза алмавы турында әйтә.

«Шулай итеп, революциягә чаклы татар теле бик киң иттереп алганда да, тагы-тагы бер генә буын әдипләргә ия булып кала. Аерым фәннәрне үзләштерү ягыннан, татар теле революциягә чаклы, тик кайбер тармакларда популяр әсәрләр бирә башлау дәрәҗәсенә генә ирешә алды», – ди Атнагулов. Мәкаләсендә ул шулай ук революциядән соң татар теленең дәүләт теле буларак, оешма һәм учреждениеләрдә кулланылуы мәҗбүр булган хокукка ирешүе турында искәртеп китә. Шулай ук вакытлы матбугатта да гарәп-фарсы сүзләренең азрак кулланыла башлавы турында әйтә. Татар әдәбияты фән буларак югары уку йортларына үрли башлады, ди Атнагулов. Гомуми әдәбият тармагында исә революциягә чаклы булган буын классикларга әверелеп, революциядән соң инде яңа буын өлгерүе турында яза. Вакытлы матбугатта да төп кадрларны эшче-крестьяннан күтәрелгән яшьләр һәм хезмәт иясе зыялылары тәшкил иткән, шуның өчен кайбер сүзләр яңа мәгънәләр алган, яңа атамалар да кабул ителә башлаган.

Бүгенге көндә дә заманнына күрә яңа атамалар телгә керә бара. Матбугатта һәр газета, журнал аларны үзенчә яза. Революциядән соң да җәмгыятькә яңа атамалар керү белән матбугатта газеталар аларны төрлечә язган. Бер төрле фикер булмаган. Һәм күп очракта сүзләр калькалаштырылып, туры тәрҗемә ясалган. Ягъни күп яңа атамалар зәгыйфь яңгыраган. Татар теле кагыйдәләренә нигезләнмичә тәрҗемә ителгән. Сәлах Атнагулов бу хакта болай дип яза: «Кызу көрәш елларында атамалар кабул итүдә нинди булса берәр төрле оешканлык булмады, әлбәттә. (Революциягә чаклы булган барышта да юк иде, ягъни бу вакытта иске мирас та юк иде). Шуңа күрә дә һәрбер гәзитәсе, тәрҗемәсе үзеннән үзе, көндәлек барышта очраган яңа мәгънәләргә яңа атамалар уйлап чыгарырга, яхут үз каравынча очраган атамаларны кулланырга тиеш булды».

Гражданнар сугышы беткәннән соң, атамалар кабул итү буенча эш башлана, махсус комиссияләр барлыкка килә. Әмма шулай да байтак кына җитешсезлекләр була. Бу җитешсезлекләрнең бер өлеше атамалар билгеләү эшенең оешу ягына караса, икенче өлеше атамалар билгеләүдә кулланылган принципларга караган. Атнагулов язуынча, оешу рәсми караганда оешканлык булып күренсә дә, дөреслектә ул таркалудан гыйбарәт булган. «Чөнки һәрбер учреждение, оешма, коллектив үзенә-үзе баш. Шуңа күрә дә һәр учреждениегә диярлек үзенә башка атамалар мәйданга килде», – дип яза мәкаләсендә Атнагулов. Мисал өчен ул «секретарь» сүзен китерә. Бер учреждениедә – «сәркәтип», икенчесендә – «язучы», өченчесендә – «язгын», калганнарында – «баш язучы», «язу-сызучы» дигән атамалар булган. Хәтта кайбер атамаларны аңлау өчен русчадагы оригиналын карау таләп ителгән. Мәсәлән «губчатые ткани» дигән сүзне «иренле тканьнәр» дип тәрҗемә иткәннәр. Мондый проблема 1920-1930 елларда гына түгел, бүгенге көндә дә актуаль булып кала. Чөнки белгәнебезчә, һәр газета, журнал, радио замана белән килеп кергән

сүзләрне үзенчә тәрҗемә итә, үзенчә укучыларга, тыңлаучы аудиториягә җиткерә. Әлеге проблеманы чишү юлында Атнагулов: «Татар әдәби һәм фән телен яңа атамалар белән баетуда төп материал итеп төрек-татар теленең үз хәзинәсе алыныр», – дип яза.

Атнагуловның киләсе язмасы шулай ук 1929 елда басыла. «Татар әдәби теленең орфографиясе» дип атала ул. Биредә Атнагулов татар теле узган тарихи юлны искә төшереп китә. Һәм килеп кергән «Яңалиф» чорын татар теленең гарәп сүзләреннән тәмам аерылып, аерым бер төрки тел буларак, үз кагыйдәләренә буйсынып яшәү чоры итеп билгели. Әлеге мәкаләсендә дә Атнагулов, замана хәлләренә карамастан, телнең үзлеген югалтмау, алынма атамаларны да татар кагыйдәләренә буйсындырып үзләштерү, телнең үзлеге, чисталыгы мәсьәләсен күтәрә.

Атнагулов мәкаләсендә Каюм Насыйри турында, аның татар телен яклап, аның язылышын үзгәртүне таләп итеп йөрүен, ә үзгәрешләр өчен татар теленең үзендә булган фонемаларын өйрәнүне һәм тагын яңа хәрефләр кирәклеген уртага салуын әйтә. «Әйе, Каюм Насыйрины «керәшен татар» дип тә, «мәәҗүс» татар дип тә сүгәләр, каргыйлар, аңа бәддога кылалар. Ләкин эш анда түгел! Бәлки Каюм Насыйриның үз заманында шуны күтәреп чыга алуында һәм Каюм Насыйридан шушыны күтәртә алырлык зәмин әзерләнүдә,» – ди Атнагулов [2].

Ул чорда исә орфографиягә карата төрле агымнар туа. Беренчеләре «тарихи-мантыйкый имләчеләр агымы» дип аталган, икенчеләре – «сәрфи берлек», өченче агым исә әле үз эчендә икегә бүленгән. Берләре – «алтынчылар», икенчеләр «унчылар»дип аталган. «Алтынчылар» татар теле орфографиясе өчен «е, э, ө» хәрефләрен биргән. «Унчылар» исә өч авазга хокук бирү белән канәгатьләнмәгән, тагын дүрт сузык аваз өчен хәрефләр барлыкка китерергә кирәк, дигән фикердә булган. «Алтынчылар» рәтендә Һади Максуди, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибрагимов торган булса, «унчылар» арасында Гыймад Ногайбәк, Мөхетдин Корбангалиевлар булган. Нәтиҗәдә «унчылар» җиңеп чыга.

«Турысы, күп еллар буенча көрәшеп килгән фонетика нигезе агымының унчылар өлеше җиңүгә ирешү белән бергә, авазларның шәкелләреннән гыйбарәт булган хәрефләрдә гарәп хәрефләрен бөтеннәйгә ташлап, латин нигезендәге яңа әлифбага күчүне эченә алган бер революциядән гыйбарәт», – дип яза Атнагулов мәкаләсендә. Алга таба ул Яңалиф чорында татар әдәби теленең уңышларны үзләштерү белән бергә, җитешсезлекләргә дучар булуы турында да әйтә. Һәм әлеге җитешсезлекләрне санап китеп, аларны төзәтү юлын күрсәтә. Сәлах Атнагулов тел мәсьәләсенә үзенең күп кенә мәкаләләрендә игътибарын юнәлтә. Яңалиф мәсьәләсенә кагылышлы мәкаләләре «Яңалиф» журналында басылып торган. Сәлах Атнагулов Яңалифне яклаучылар рәтендә булган.

Чыганаклар

1. 1.С. Атнагулов. Татар әдәби һәм фән телен баету юлында яңа атамалар билгеләүнең төп принциплары / Татарстан, 1929.№ 1. 3 б.

2.С. Атнагулов. Татар әдәби теленең орфографиясе. Татполиграф, 1927

Разил Вәлиев – публицист

М.Р.Вафина,
Казан шәһәре 177нче урта мәктәбенең
югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

«Разил Вәлиев – танылган язучы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Халык аның җырларын бик яратып тыңлый, тыңлап кына калмый, отып алып, үзе дә җырлый. Татарстанның халык депутаты буларак, Разилнең һәрвакыт төпле фикере, саллы сүзе бар. Бәлки кайчакта Разил хискә бирелеп, шагыйрьләрчә кайнарланып та киткәлидер. Әмма шунысы ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен гореф-гадәтләребезне саклау һәм үстерү өчен тырыша». Татарстан Республикасының беренче президенты Минтимер Шәймиев Разил Вәлиев турында әнә шундый затлы фикердә.

Әйе, ул халык шагыйре, туган телебезне, мәдәниятебезне үстерү һәм саклап калу өчен янып-көеп яшәүче милләтпәрвар шәхесләребезнең берсе.

Ике дистәдән артык китап, дүрт пьеса, йөзләгән җырлар авторы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, халык шагыйре, танылган җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевның татар милләте, татар тарихы, татар мәдәнияте өчен янып йөрүенә, бу өлкәдә куйган хезмәтләренә дөнья җәмәгатьчелеге дә югары бәя бирде.

Разил Вәлиев өч жанрда – поэзия, проза, драматургия жанрларында иҗат итә. Ләкин кайсы гына жанрда эшләсә дә, ул иң элек шагыйрь булып кала. Аның проза әсәрләре үзләренең шигъри теле, образларга бай булуы белән аерылып торалар. Ә җырлы-моңлы пьеса-спектакльләре театр сәхнәләреннән төшми. Күпкырлы каләм иясенең матбугат битләрендә дөнья күргән тирән эчтәлекле мәкаләләре дә татар публицистикасы өлкәсендә зур урын алып тора.

Матбугат – милләтнең фикерен чагылдырып, аны халыкка түкми-чәчми җиткерүче төп чара. Ул халыкның интеллектуаль байлыгы, фикри мирасы. Матбугат халыкның киләчәге, милләтнең язмышы белән дә тыгыз бәйләнгән. Рәсми газетаның төп максаты һәм бурычы, беренчедән, дәүләт идеологиясен халыкка аңлату булса, икенчедән, халыкның уй-фикерен рәсми җитәкчелеккә һәм киң җәмәгатьчелеккә җиткерү. Разил Вәлиевның соңгы елларда матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләрен укып, кыскача өзекләр китерелде, танылган җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев каләменең гаять зур дәрәҗәдә ялкынлы икәнлегенә инандык.

«1992 елны без, дәүләт буларак, беренче мәртәбә үзебезнең мөстәкыйль төп кануныбызны булдырдык. Соңгы елларда бөтен уңышларыбызга: сәяси, икътисади, рухияти алгарышларыбызга – барысы да шушы Конституциягә нигезләнеп ирешелде» («Мәгърифәт», 2004, 6 ноябрь).

«Мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләрен кыскарткан вакытта чиновниклар даирәсенең бермә-бер ишәя баруы оптимизация һәм цивилизация таләпләренә һич җавап бирми кебек» (Дәүләт Советы сессиясендәге чыгышыннан // «Шәһри Казан», 2008, 8 март).

«Казанның көннән-көн яңара баруы куандыра. Шактый юлларга асфальт түшәлде. Шәһәребезгә әле яшеллек җитеп бетми. Үзәктә өсте-өстенә йортлар салына. Болакның бу ягында бер генә мәчет тә юк. Казан – Европа белән Шәрык мәдәниятләрен берләштергән үзәк. Аның Европа өлеше арта, шәрыкныкы кими. Ул Идел буендагы башка бер шәһәрнең игезәге генә булып калырга мөмкин. «Бәхетле»дән кала сәүдә үзәкләренең берсендә дә татар исеме юк. Мәсәлән, «Мега», «Рамстор»ларга сызыкча аша булса да, берәр татарча исем өстәп куярга мөмкин бит» («Шәһри Казан», 2007, 27 окт.).

«Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә
Тирәнәйде маңгай сырларым».

Авторның шул исемдәге мәкаләсендә берничә шигыре басылып чыга. «Бәхет», «Бөеклек», «Беренче кар», «Бумеранг», «Театр», «Тик минеке» кебек шигырьләре газета битләрендә дөнья күрә. Шигырьләрен укыган саен укыйсы килә, тирән мәгънә салынган булуына мең кат инанасың...

Җилләрдән мин сафлык таләп иттем,
Болытлардан аклык сорадым.
Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә
Тирәнәйде маңгай сырларым.
Күңелемә кайгы-сагыш төшсә,
Ак чәчәкләр җирдә эзләдем.
Офыкларга карап көтә торгач,
Офыкларга мандым күзләрем.
Аклык эзләп гомер иткәнгәме, –
Ап-ак булды чигә чәчләрем.
Шатлыгымны җилгә сибеп йөрдем,
Тик кайгымны җиргә чәчмәдем.
Мннан ары күзне күккә төбәп,
Буш хыяллар белән йөрмәмен.
Минем бәхет – тик минеке генә булыр, –
Туктамасын гына йөрәгем.
(«Шәһри Казан, 2007, 19 гыйнв.).

«Минем өчен Тукай премиясе – ул язылган әсәрләремә укучы бәясе. Һәм киләчәктә әлеге премияне даулап һәм яулап йөрмәдем. Минем өчен иң мөһиме – эшләнгән хезмәтләрем һәм киләчәктә укучыга җиткерер шигъриятем, – диде Разил Вәлиев, – әлбәттә, әлеге премия язучы-шагыйрьләргә генә бирелсә, әйбәт булыр иде. Әмма безнең башка дәүләт премиясе булмагач, башка сәнгать әһелләренә бирелүе дә начар түгел» (Тукайга рухыбызны яңартырга килдек // «Шәһри Казан», 2007, 27 апр.).

«Шәһри Казан» газетасында басылып килә торган «Бәхәс мәйданы» дигән язмада Разил Вәлиевның «Татар китабы нигә укылмый?» дигән сорауга җавабы

басыла: «Мин үзем, язу-сызу эше белән бәйле зат булгач, китап укымыйча яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Кеше суламыйча, ашмыйча яши алмаган шикелле, мин дә китап укымыйча тора алмыйм. Чөнки минем бөтен тормышым китап арасында үтте...» («Шәһри Казан», 2008, 21 ноябрь).

Шулай ук «Мин шагыйрь дә, депутат та» дип исемләнгән язмада «Сез беренче чиратта шагыйрьме, депутатмы? Шагыйрь өчен депутат кәнәфие нигә кирәк иде?» дигән сорауга Разил Вәлиев болай җавап бирә: «...кемдер милләтенә шигърияте белән хезмәт итәргә, кемдер Мәскәүгә кадәр барып, халкының хокукларын якларга, киләчәген кайгыртырга тиеш. Ике кулны кесәгә тыгып, беркая эшләмичә, сукбай булып та шагыйрь булып йөреп була. Ә Мәскәү Думасына урамнан килеп кереп, халкыңның хакын даулап булмый. Бүген депутат булмасам да, мин барыбер милләт проблемалары белән янып яшәр идем. Роберт Әхмәтҗан әйтте бит: «Бүген һәр шагыйрь сәясәтче», – дип. Дөнья тарихында шагыйрьләр, патшалар, вәзирләр, дәүләт эшлеклеләре булган. Эшләү дәверендә миңа халык, милләт язмышына кагылышлы мәсьәләләрне үзебезнең парламентта гына түгел, Мәскәүгә кадәр барып якларга туры килгәне дә булды. Татарстан телләре турындагы законны (1992 ел), Конституцияне шактый зур авырлык белән кабул иттек». («Шәһри Казан», 2007, 22 июнь).

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь, драматург, прозаик, тәрҗемәче, публицист Разил Вәлиевның эшчәнлеген әлеге хезмәт кысаларында гына тикшереп бетереп булмый. Әдип төрле катлаулы мәсьәләләрне чишәргә омтыла, халык тормышын яхшырту максатыннан күптөрле язмалар бирә, туган телебезне саклап калу өчен зур хезмәт куя. Разил Вәлиевның тырышлыгы нәтиҗәсендә күп кенә татар мәктәпләре ябылмыйча калды.

«Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә

Тирәнәйде маңгай сырларым,» – дип янып-көеп яши шагыйрь-публицист. Чыннан да, авторның газета-журнал битләрендә басылып чыккан язмаларын гади халык та көтеп яши, яратып укый, үзе ишетмәсә дә аңа олуг рәхмәтен кабатлый. Бу аның чын мәгънәсендә халык шагыйре икәнлеген исбатлый, ерактагы якын туганы икәнлегенә мең кат инандыра.

Милли агарту юлында мәгърифәтчелек хәрәкәте

Л.Ш.Исхакова, Казан шәһәре 177 нче урта мәктәбенең милли эшләр буенча директор урынбасары, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар мәдәниятенең күп гасырлык тарихы бар. Ләкин, кызганычка каршы, без әле бүген үзебезнең рухи мирасыбызны тиешле дәрәҗәдә тирән беләбез дип горурлана алмыйбыз. Моны истә тотып, милләтебезнең асыл

затларын барлау һәм аларның халкыбыз тарихында тоткан ролен, бөеклеген исбатларга тырышып карыйк.

Татар зыялылары татар мәдәнияте тарихында яңа юл салучылар булып торалар. Калдырган рухи мираслары бик бай булу белән бергә, башка эшчәнлекләре, фикри эзләнүләре, җәмгыятьне уятырга омтылулары, шәхси фидакарьлекләре аларны яңа мәдәниятнең чишмә башында торучылар дәрәҗәсенә күтәрә. Күп мәсьәләләрне хәл итү юлларын бик томанлы күз алдына китерсәләр дә, алар эшчәнлегендә иң мөһиме – халыкны тормыш баткаклыгыннан яңа юлга алып чыгу кирәклеген аңлау.

Заманалар үтү белән, татар зыялылары тарих фаҗигаләре нәтиҗәсе булган тормыш баткагыннан чыгу юлларын эзләүдә яңа баскычка күтәреләләр, Россия дәүләтендә үзләренең законлы урынын аныклау өчен көрәшкә басалар. Бу көрәш, кулга корал тотып сугышудан бигрәк, яңа фикер туплау, милләт бердәмлеге хакында кайгырту, аның рухи нигезе булган ислам динен саклау, халыкны агарту, аның үзаңын һәм иманын ныгыту юлында бара. Бу өлкәдә татар халкы барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга омтыла.

XX гасыр башы татар мәдәнияте тарихында яңарыш чоры булып тора дисәк, һич тә ялгыш булмас. 1905-1907 еллардагы рус революциясе татар халкының гасырлардан килгән хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек ачты. Татар зыялылары аннан киңрәк файдалану юлларын эзләргә керештеләр. Шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, татар милли вакытлы матбугаты барлыкка килде.

XX гасыр башында татар дөньясы мөселман җәмгыяте буларак яшәп килсә дә, бу чорда яңа тип татар зыялылары формалаша. Й.Акчура, С.Максуди кебек зыялылар, Европа югары уку йортларында укып кайтып, татар җәмгыятенә дөньяви принципларга нигезләнгән яңача фикерләү юлларын күрсәттеләр. Әлбәттә, моны татарларның яшәеш рәвешен үзгәртүгә омтылыш дип карау һич тә дөрес булмас. Татарларны бу чорда милләт буларак та, мөселманнар буларак та саклап калып, алга таба үстерү юлларын эзләргә кирәк иде. Җәмгыятьтә фикер төрлелеге бик киң булса да, татар зыялылары нәкъ менә шул хакта уйлыйлар, үзләре күзаллаганча алга таба үсеш юлларын күрсәтәләр, милләтне берләштерү һәм аны саклап калу өчен җәмгыятьтәге төрле сәяси көчләрне оештыру юлларын эзлиләр. Кайберәүләр бу юлны дини ислахчылыкта күрсә, икенчеләре, җәмгыять үсешенә киңрәк карап, аны алга таба үстерү өчен, Европаның алдынгы фикерен һәм икътисади тәҗрибәсен киңрәк файдалану идеясен алга сөрәләр.

Күренекле галим, укытучы-педагог һәм әдип *Каюм Насыйри* татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнады. Аның ярты гасырга сузылган күптармаклы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге халыкка хезмәт итү, милләтнең аң-белем дәрәҗәсен күтәрү, киң күпчелеккә аңлаешлы татар әдәби телен гамәлгә ашыру теләге, демократик караш һәм халыкчанлык рухы белән сугарылган иде.

Барлык көчен дәреслекләр һәм китаплар язуга, тапкан акчасын аларны бастыруга тоткан галимнең килере аерым кешеләрнең балаларын укытудан, гаризалар язып бирүдән, тәрҗемә итү, китапларын сатудан гыйбарәт була.

Дәреслекләренә карталар сызу, басылган китапларын төпләү, рәсемнәр төшерү эшләрен дә үзе башкара. Ул бигрәк тә агачтан төрле әйберләр ясарга яраткан, кирәк булган әйберләрнең барысын да үзе эшләгән.

Аның иң беренче хезмәте – «Нәхү китабы», ягъни татар теле синтаксисы. Бу китап 1860 елда басыла. Русча өйрәнүче татарларны, татарча өйрәнүче русларны күздә тотып, бу дәреслек рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип аталган. Текстларда татарча һәм русча китерелгән сүзлек бирелгән. Шул ук елда аның «Буш вакыт» исемле китабы да басылып чыга. Бу хезмәтендә автор балаларны һәм дөньяви фәнннәрдән башлангыч белем алучыларны анатомия, табигать белемнәреннән кыскача мәгълүматлар белән таныштыра.

Халыкта милли үзаңның формалаша баруы туган телгә игътибарны арттыра, нәтиҗәдә аның К.Насыйри шикелле эшлеклеләре дә мәйданга килә. Ш.Мәрҗани һәм Х.Фәезхановлар уяну хәрәкәтенә тарихны корал итсәләр, К.Насыйри туган телне корал итә, татар телен күтәреп чыга. Татар телен гамәлгә кертүдә К. Насыйри эшчәнлегенең бер тармагы телнең үзен өйрәнү, кагыйдәләрен аңлату, сүзлекләр төзү булса, икенчесе – иң беренче татарча өстәл календарен төзү.

Татарларда рус телен белүнең әһәмиятен яхшы аңлаган мәгърифәтче бу телне өйрәнү өчен уку китабын, рус теле грамматикасын, татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзеп бастыра. Укыту процессында һәм тәрҗемә иткәндә ике телне чагыштыру алымын куллана. Бу – хәзерге көндә дә уңышлы кулланыла торган метод.

Тел байлыгының мул чыганагы халыкның җанлы сөйләмендә, авыз иҗатында икәнлеген яхшы аңлаган К.Насыйри фольклор әсәрләрен җыю һәм гыйльми нигездә бастырып чыгаруда зур тырышлык куя. Бу – аның фольклор өлкәсендәге эшчәнлегенең мөһим бер тармагы. Икенчедән, К.Насыйри татар халкының тарихи риваятьләре, борынгы мифологик ышанулары, гореф-гадәтләре, дөньяга карашлары һ. б. белән башка халыкларны, фән дөньясын таныштыру буенча эш алып бара, рус телендә хезмәтләр чыгара. Өченчедән, галим Көнчыгыш халыклары фольклорын өйрәнә, аның үрнәкләрен, татарчага тәрҗемә итеп, бастырып чыгара. Шул рәвешле, К.Насыйриның фольклор фәнендәге эшчәнлеге төп өч юнәлештә бара. Үзе чыгарган календарьларда, сүзлекләрдә һәм җыентыкларда К.Насыйри халык иҗаты үрнәкләрен урнаштыруга зур игътибар бирә. Шул рәвешле, мәгърифәтче галим, татар фольклорының күп кенә жанрларында да эшләп, халыкның рухи байлыгын, акыл һәм күңел җәүһәрләрен барлап, бергә туплап, халыкның үзенә кайтару юлында армый-талмый хезмәт иткән.

Энциклопедик белемле галим буларак, К. Насыйри татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырды.

Мәгърифәтчелек хәрәкәтенең тагын да бер асыл заты, фәлсәфәче, тарихчы, дини ислахчы – *Шиһабетдин Мәрҗани*. Ләкин бу билгеләмәләр генә дә аның күпкырлы эшчәнлегенең бар ягын колачлый алмый. Мәрҗани әле этнограф та, археограф та, шәркыят галиме һәм мөгаллим дә. Аның энциклопедик белемнәрен XVIII йөз француз мәгърифәтчеләре Дидро һәм Ж.-Ж. Руссо гыйлемлелеге белән чагыштырырга мөмкин. Унҗиде яшендә инде ул мәдрәсәдә укыта башлый һәм, фарсы теле морфологиясе дәреслеге белән канәгать булмыйча, үз дәреслеген төзи.

Мәрҗанинең мәгърифәтчелек идеяләре XIX гасырның 70-80 нче елларында татар иҗтимагый тормышын яңартуның бөтен якларын колачлый, татар халкының дөньяви белемнәр алырга тиешлеге, үткәннәрнең прогрессив (антик, гарәп фикерләре) мирасын һәм бүгенгене (рус һәм Көнбатыш Европа мәдәниятен) үзләштерү зарурлыгы турындагы фикерләрне эченә ала. Мәрҗани татар халкының этногенезы проблемаларына мөрәҗәгать иткән беренче татар тарихчысы иде. Мәрҗани татар халкын үзенең мәдәни мирасын үзләштерергә чакыра, шуның белән татар халкының милли үзаңы уянсын, ул үз милли бергәлеген аңласын дип тырыша.

Мәрҗани Россиядә җәдитчелек хәрәкәтен башлап җибәрде. Аның нигезләрен (мәдрәсәдә укыту реформасын, татар халкының бөтендөнья мәдәнияте һәм фән казанышларын үзләштерүе) нәкъ менә ул салды.

Мәрҗанинең идея-фәлсәфи карашлары, аның мөгаллим, дини ислахчы, тарихчы, мәгърифәтче, фәлсәфәче буларак эшчәнлеге татар халкының гына түгел, ә бөтен Россия халыкларының иҗтимагый фикере, әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында күренекле урын алып тора.

Заманасының зур иҗтимагый-сәяси эшлеклесе, күренекле дин галиме, мәшһүр педагог *Галимҗан Баруди*, XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар халкы тарихында үзенчәлекле шәхес буларак, аерым урын тота.

Казанга кайткач, Галимҗан Баруди тормышында яңа чор башлана. Аннан соңгы 36 ел дәвамында Г.Баруди, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнеп, үз халкының белем һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү өчен армый-талмый хезмәт куя.

Мәчеттә эшли башлагач, Галимҗан Галиевнең үз уку йортын булдыру турындагы хыялы чынга аша. 1882 елда аның атасы Тихвин урамында урнашкан Йосыф Сәгыйтов мәдрәсәсе ишегалдындагы бер катлы таш бина төзелешенә акча бирә. Тиздән бу бина күрше участокны сатып алу хисабына киңәйтелә. Иске мәдрәсә ишегалдында яңа бина төзү, документлар буенча, иске уку йортын киңәйтү булып күренсә дә, соңрак үзенә нигез салучы Мөхәммәтҗан хөрмәтенә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, ә документларда «Галиев мәдрәсәсе» дип аталган уку йорты бөтенләе белән Йосыф Сәгыйтов мәдрәсәсеннән аерылып тора. Г. Баруди «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укытуның яңа, аваз ысулын кертә башлый, уку-укыту программасын да алыштыра.

Казанда Галимҗан Баруди мөхәррирлегендә «Әд-дин вә-л-әдәб» («Дин вә әхлак») журналы чыга башлый, ул үзенең дини-тәрбияви эчтәлеге белән башка басмалар арасында аерым урын тота.

1912 елның 28 февралендә Галимҗан Баруди Казан губернаторына гарәп, фарсы, төрек, рус һәм татар телләрендәге китаплардан торган түләүсез китапханә ачу турында үтенеч язуы яза. 1914 елның 11 гыйнварында гына аңа әлеге китапханәне ачарга рөхсәт итәләр. 1920 елда бу китапханәдәге китаплар һәм аның бинасы Татар республикасының Шәрык китапханәсенә тапшырыла, соңрак ул «Шәрык китапханәсе – музей» дип йөртелә башлый.

Күренекле мәгърифәтче *Ризаэддин Фәхреддин* турында да мәгълүмат биреп китү урынлы булыр. Мәдрәсәнең өлкән сыйныф шәкерте булганда ук Ризаэддин үз хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә: башлангыч сыйныф балаларын укыта. Дөньяви фәннәр укытуы, укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануы белән ул бик тиз танылып өлгерә. Гомумән, бу һөнәренә гомере буена тугрылыклы булып кала.

Укыту эшчәнлеге белән беррәттән, ул фәнни эш белән мавыга, бик күп китаплар һәм мәкаләләр яза, татар халкының тарихы һәм әдәбияты белән бәйле тарихи чыганакларны, истәлекләрне җыя, тәртипкә сала.

Мәдрәсәне тәмамлагач, мөгаллим булып эшли, фән, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Р. Фәхреддин, Уфага күчеп, Диния нәзарәте архивындагы бик күп кулъязмаларны тикшереп, тәртипкә сала, татар укымышлылары, мулла һәм мөдәррисләре, әдип һәм шагыйрьләре турында гаять бай мәгълүматлар тупланган күп томлы «Асар» дигән хезмәтен яза.

Шактый зур фәнни һәм укыту эше буенча тәҗрибә туплаган галим үзенең укытучылык эшчәнлеген Оренбургта да дәвам итә һәм берничә ел дәвамында шундагы танылган «Хөсәения» мәдрәсәсен җитәкли.

1908-1918 елларда аена ике мәртәбә чыгып килгән иҗтимагый-педагогик, әдәби-публицистик «Шура» журналының баш мөхәррире булып эшли. Иҗтимагый-фәлсәфи фикер, әдәбият, мәдәният, мәгариф һ. б. темаларга караган бик күп мәкаләләре шушы журналда басыла.

Р. Фәхреддин үзенең әсәрләрендә, милләтне аң-белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Дини белемнәр белән бергә фәнни белемнәрне үзләштерү, укыту-тәрбия ысулларын үзгәртеп кору, күркәм холыклы булу, рус телендәге фәннәрне өйрәнеп, халыка хезмәт итү идеяләрен алга сөрә. Ул тарих, фәлсәфә, педагогика, әдәбият, тел белеме, сәнгать, география, этнография, археология, археография, генеалогия, медицина, нумизматика, юриспруденция, астрономия, халык авыз иҗаты, дин тарихы һ. б. төрле фәннәр белән бик нык кызыксынган һәм алар буенча күпсанлы һәм кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган.

Гомере буе үз халкы һәм Ватаны азатлыгы турында хыялланган, ләкин аны көтеп ала алмаган атаклы җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, талантлы публицист һәм җәдитче мөгаллим *Габдулла Апанаев*.

Г. Апанаев тарафыннан оештырылган «Азат» газетасының беренче саны 1906 елның 1 февралендә дөнья күрә. Номерның баш мәкаләсендә үк басманың юнәлеше ачыктан-ачык белдерелә. «Үз исеменә тугрылыклы калып,– дип белдерә редакция,– газета азатлык чәчәк атсын өчен көрәшәчәк, халыкның изелгәнлеге, хокуксызлыгы, түбәнсетелүе һәм артталыгы белән беркайчан да

килешмәячәк, барлык милләтләргә тигез хокуклар бирү өчен бөтенесен дә эшләячәк».

Кыска гына вакытта Г.Апанаев һәм аның фикердәшләре ярдәме белән беренче татар китапханәсе «Китапханәи исламиясе», шулай ук «Шәрыкъ клубы» китапханәсе дә даими рәвештә яңа басмалар белән тулыландырылып торган.

Йосыф Акчура – татар халкының танылган иҗтимагый-сәяси эшлеклесе, галим, сәяси төркичелеккә нигез салучыларның берсе, татар һәм төрек милләтләренең барлыкка килүенә гаять зур өлеш керткән кеше. Ул Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих һәм география укыта башлый, шәкертләр арасында реформаторлык хәрәкәте җәелүгә актив этәргеч бирә. Әлеге мәдрәсәдә укыган лекцияләре базасында берничә китап бастыра. 1905 елның көзеннән «Казан мөхбире» дигән беренче татар газетасы чыга башлый. Аның нашире – присяжный поверенный Сәетгәрәй Алкин, ә редакторы Йосыф Акчура (Б.Шәрәф белән бергәләп) була.

Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы) педагог, яңа метод (ысулы җәдит) белән укытуга нигез салучы һәм «Тәрҗеман» исемле гомумтөрки газетаны чыгара башлаучы журналист буларак мәгълүм. Ул беренче тапкыр, бай кешеләрне җәлеп итеп, җәмгыяте хәйрияләр оештыра. Шул үрнәктә мондый җәмгыятьләр бөтен мөселман дөньясында төзелә башлый. Мәдрәсәдә эшләгәндә югары мәктәпнең камил булмавын күреп, ул мөселман мәктәпләрен үзгәртеп кору зарурлыгына инана. Яшь язучыга халыкның наданлыгына һәм фанатиклыгына каршы көрәшергә туры килә.

Милләтебезнең асыл затлары – *бертуган Рәмиевләр*. Алар да татар халкының милли үзаңын формалаштыруда, әдәби һәм мәдәни тормышын баетуда гаять зур урын билиләр.

Рәмиевләр күченеп утыргач, Юлык авылының йөзе үзгәрә. Алар иң әүвәл таштан зур иттереп үзләренә йорт-җир җиткерәләр, кибетләр ачалар. Эшләре алга киткән саен, авылга ярдәмнәрен дә арттыра баралар. 1898 елда мәһабәт итеп таш мәчет торгызалар. Авылда зур мәдрәсә ачалар, озак та үтми, русча укыта торган мәктәп салалар. Хәлфәләрне, укытучыларны үз исәпләренә тоталар. Юлык тарихындагы беренче китапханәне дә алар нигезлиләр.

Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) матди байлыгының да шактый өлешен милләтебезне аң-белемле, мәдәниятле итүгә тота. Шагыйрь булмыйча, бары тик татар халкына күрсәткән игелекләре өчен генә дә Закир һәм аның абыйсы Шакир Рәмиевләр рәхмәт хисләре белән тәкъдир ителергә тиешләр.

1906 елда *Шакир белән Закир Рәмиевләр* «Вакыт» газетасын, 1908 елда «Шура» журналын чыгара башлыйлар.

Шулай итеп, бертуган Рәмиевләр – татар мәдәнияте тарихында якты эз калдырган, исемнәре хөрмәт белән искә алынырга тиешле шәхесләр. Алар нәшир иткән газета-журналларның татар вакытлы матбугатын, әдәбиятыбызны һәм иҗтимагый фикерне үстерүдә өлешләре бик зур.

Закир Рәмиев Октябрь вакыйгаларында типографиясен, алтын приискаларын яңа хакимияткә тапшыра. Хәленнән килгәнчә җәмәгать

эшләрендә катнашырга тырыша. 1921 елгы ачлыкта халыкка ярдәм итү эшен оештыруга керешә.

Сәгыйть Рәмиев – үз заманының актив җәмәгать эшлеклесе, халыкның иҗтимагый аңын үстерүгә зур өлеш керткән, мәдәниятебезне чәчәк аттыру өчен ихлас янып-көеп яшәгән шәхес. Шунысына игътибар итәргә кирәк, кайсы гына газетада эшләмәсен, С.Рәмиев аның телен, төрек йогынтысыннан арындырып, халыкка якынайту гамәленә керешә.

Соңгы елларда исемнәре һәм иҗатлары туган иленә әйләнеп кайткан зыялылар арасында *Гаяз Исхакый* исеме аеруча мөһим урын алып тора. Төрек-татар халыкларының азатлыгы, матур тормышы һәм социаль тигезлеге өчен гомеренең алтмыш елын багышлаган бу олуг шәхес татар тарихында тирән эз калдырган. Г. Исхакыйның милләт язмышы өчен көрәше язучы, мөхәррир һәм сәясәтче буларак эшчәнлегендә төп максат булып тора.

Мөһаҗирлектә чагында да Г.Исхакый әдәби иҗатын дә, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген дә актив дәвам итә. Төрле илләргә таралган татар эмигрантлары белән очраша, алар белән элемтәдә яши. Китаплар бастыру, гәзит-журналлар чыгару буенча актив эшли. XX гасырның 20-30 нчы елларында Варшава, Берлин шәһәрләрендә «Милли юл», «Яңа милли юл», 1935 елда Кытайда «Милли байрак» исемле газета-журналлар чыгара. Ул мәкаләләрендә татар милләтенең киләчәге өчен борчылуын белдерә, телне, милли мәдәниятне саклау проблемаларын күтәрә. Әдәби һәм сәхнә әсәрләрендә дә әдип белемнең, мәгърифәтнең камиллеккә илтүе, ә наданлык һәм әхлаксызлыкның кешенең шәхес буларак түбән тәгәрәвенә китерүе турындагы идеяне үткәрә.

1901 елда Г.Исхакый үзенең фикердәшләре белән бергә студентларның яшерен җәмгыятен төзи һәм кулдан язылган «Тәрәккый» газетасын чыгара, татар халкының аңын уятырга омтылып, кешеләр арасында төрле хатлар тарата.

Татар җәмгыяте күп гасырлар буе үзенең асылын саклап калу өчен көрәшеп, алга таба үсү мөмкинлекләре эзләп яшәде. Шуңа күрә дә татарлар өчен схоластик фикерләү кысаларыннан чыгып, заман таләпләренә җавап бирерлек фикерләү дәрәҗәсенә күтәрелү бик мөһим иде. Татар зыялылыры бу авыр һәм катлаулы юлда төрки халыклар арасында гына түгел, бөтен мөселман дөньясында әйдәп баручылар дәрәҗәсенә күтәрелә алдылар, үзләренең язган хезмәтләре, яңа идеяләре, милләтпәрвәр һәм нык иманлы булулары белән аерылып тордылар.

Соңгы елларда без халык иҗаты, әдәбият, тормыш турында күбрәк уйлана башладык, матурлыкны күбрәк таный, бәяли белергә өйрәндек. Үзебезгә, янәшәбездә яшәгән кешеләргә игътибарыбыз, кызыксынуыбыз артты. Башкаларны да кайгыртып, ярдәмчел һәм киң күңелле булып яшәү үзеңә хөрмәтне арттыра, күңелне үстерә икәнлегенә ышандык.

Кешенең киң күңелле, игътибарлы булуы, ярдәмгә килергә әзер торуы – аның үзен генә түгел, гомумән, тормышны матурлап торган сыйфатлар бит. Янәшәбездә таяныр кеше булу куандыра, җиргә дә ышанычлырак басып йөри башлыйбыз. Андыйлар турында халык «тормышның терәге» дип зурлап әйтә. Үзебезнең булдыклы, көчле икәнлегеңне тоеп яшәү – бик әһәмиятле, кирәкле

хис – канәгатьлек хисе ул. Чишмә сулары тамчылап җыелган кебек, кешелекле булуыбыз кечкенәдән, бала чактан башлана.

Бүген әлеге кешелекле сыйфатларга ия булган кайбер шәхесләребезнең күркәм эш-гамәлләре, милләт файдасына башкарган омтылыш-теләкләре турында фикер йөрттек. Андый шәхесләребез, иншалла, бүген дә байтак. Изге эшләр безнең милли йөзебезне, татарлыгыбызны билгели торган гамәлләр булып калсын, мәңге янәшәбездә булсын иде.

Әдәбият

1. Галиуллин Т.Г. Тарихыңны онытсаң – юк киләчәгең // Замана балалары. Казан, ТКН, 1993.

2. Исламова Ф.Ф., Закиржанов Ә.М. Татар әдәбияты. 5нче сыйныф. Казан, Мәгариф, 2009.

3. Миңнегулов Х.Й., Садретдинов Ш.А. Әдәбият. 9 нчы сыйныф. Казан, Мәгариф, 2010.

4. Мусин Ф.М. Татар әдәбияты, 11нче сыйныф. Казан, Мәгариф, 2011.

5. Хатипов Ф.М. Үткәннәр аша – киләчәккә // Казан утлары. 1985. №11.

6. Хатипов Ф.М. Прозабызда психологизм турында // Казан утлары, 1973, №6.

А. Хәлим публицистикасында тел һәм милли мәгариф мәсьәләләре

Л.Ә.Исхакова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
А.Ф.Галиәхмәтова)

Татарстан һәм татарлар яшәгән башка төбәкләрнең бер рухи милли мохиттә яшәвен күз алдында тотып, гаммәви мәгълүмат чараларының милләтне оештыруда, яшьләргә тарихи һәм милли үзаң бирүдә әһәмияте зур. Вакытлы матбугат милли көнкүреш нигезләрен төзүдә төрле катлау кешеләренең катнаша алу мөмкинлеген дә тудырды. Соңгы елларда милли мәсьәлә, аерым алганда, милли мәгариф һәм тел мәсьәләсе тирәсендә сәясәтчеләр, журналистлар, халык тарафыннан киң фикер алышу куера**.** Чөнки бүген бу тармакны төптән үзгәртеп кору бара. Белем бирү системасына куелган таләпләр көннән-көн катгыйлана. Публицист Айдар Хәлим дә әлеге мәсьәләне читләтеп узмый. Аның бу уңайдан иҗат ителгән кайбер язмаларына аерым тукталыйк.

Авторның әлеге темага багышланган «Иле барның теле бар»[1] дип аталган аналитик мәкаләсенең төп максаты, беренче карашка, Совет заманындагы милли мәктәпләрне юкка чыгару сәясәтен фаш итү. Әмма автор үткән һәм бүгенге арасында аналогияләр билгели, нәтиҗәләр ясый. А.Хәлим милләт, туган тел үсешен турыдан-туры милли мәгариф системасына бәйләп карый. Сүз XX гасырның җитмешенче еллар башында булган хәл белән башланып китә. Автор милли мәктәпне юкка чыгару сәясәтенең үз туган

мәктәбенә ничек тәэсир итүе хакында яза. Башкортстандагы Кыргыз-Миякә авылы мәктәбенә дә кагыла «рус телен яхшырту» җилләре. Нәтиҗәдә белем йортында барлык фәннәрне урысча укыту башлана. «Тел культурасы ул – кешенең гомуми культурасы нигезе. Тел ул – фәлсәфә һәм әхлак, йолалар һәм гореф-гадәт, рухи хәзинәләр, матурлык тойгысы һәм мәңге саф, мәңге тере шигърият чыганагы, кеше хәтеренең йолдызы дигән сүз», – дип яза публицист [2].

Шәһәрдә инде кемнәрдер баласының туган телне онытуына кул селтәгән, моңа күнеккән. Икенчеләр бу хәлне фаҗигагә саный, эчтән сызлана. Баласының русча укып та әллә ни ерак китә алмавын күргән авыл агае исә: «Нинди мәктәп бу, улыбыз ни урысча, ни татарча юньләп белми», – дип сукрана һәм ул хаклы.

Алдагы өлештә автор бу проблеманың сәбәпчесе булып торган факторларга игътибар бирә. Барысы да моңа балаларын туган телдә укытырга теләмәгән «ата-аналар теләге» гаепле дип саный. Әмма бу чыннан да шулаймы? Автор бу фикергә шик белән карый һәм сәбәпче башка дәлилләр китерә. Совет власте иң элек халыклар дуслыгы, соңрак «ата-аналар теләге» дигән сылтау табып, балаларга урыс телендә белем бирүне кулайрак күрде. А.Хәлим югарыдагыларны проблеманың төп сәбәбе дип бәяли.

Саф татар һәм башкорт авылларында туган балалар да урысча укырга мәҗбүр. Әмма үзләре аңламаган телдә алар фикер йөртә алмый. Ят телдә белем үзләштерү – укучы миенә өстәмә йөк. Нәтиҗәдә бала стресс кичерә. Урысча белү дәрәҗәсе дә күтәреләсе урында түбәнәя генә.

А.Хәлим дәлил өчен мәшһүр чех педагогы Ян Коменскийның «Мәңгелек дидактика» хезмәтеннән файдаланып, туган телнең бала тәрбия-үсешенә уңай йогынтысы турындагы фикерләрен китерә. Бөтен дөнья педагогика фәненә нигез салучыларның берсе Иоганн Песталоцци да бу фикерне куәтләгән. Димәк, автор тагын бер сәбәпне күрсәтә: хөрмәтле галимнәрнең исемнәрен телдән төшермәүгә карамастан, аларның укыту программаларын гамәлдә кулланмау, китапларны ерак шүрлекләргә яшерү алып барыла.

Автор фикеренчә, милли сыйфатлар – кешенең яшәү үзенчәлеге. Әгәр кеше бу сыйфатлардан мәхрүм ителсә, ул үз халкына хас йолалардан, гореф-гадәтләрдән, телдән, мәдәнияттән йөз чөерүче, ягъни гармоник тәрбия алмаган бәндә булып үсәчәк.

Әлеге мәсьәлә «Безгә ничек исән калырга?» [3] дип исемләнгән мәкаләсендә автор милләтнең киләчәге турында уйланып, аның исән калу юлларын билгели. Иң беренче чиратта, безгә үз-үзебезне кимсетеп яшәүдән туктарга кирәк, ди автор. Мондый шартларда «Татарча укып кая барасың?» дип паника чәчеп, милли мәктәпләрне яптырмаска кирәк. Автор иң беренче чиратта татар теле үсешенә каршы чыккан татарларны фаш итәргә кирәклеге турында фикер әйтә.

«Татар милләте өчен кануннамә» [4] мәкаләсендә А.Хәлим татар үзен милләт буларак саклап калсын өчен 26 шарт кирәклеге турында яза. Менә аларның кайберләре: сабыйларны туган телдә укыту, аларны тәрбияләү милли моң, тел-авыз иҗаты аша алып барылырга тиеш, милли университет булдыру,

шәһәр-авылларны милли рухта бизәү, татарның талантлы шәхесләрен бөтен Җир шарына таныту, бәйсез милли радио-телевидение булдыру, хакимияттә утырган башка милләт кешеләреннән татарча белүне таләп итү.

А.Хәлимнең «Сөялмәскә» [5] мәкаләсе дә туган тел мәсьәләсенә багышланган. Биредә автор татар теленең халык өчен булган әһәмияте турында тагын бер кат ассызыклап яза.

А.Хәлимне милли телләрне компонент дәрәҗәсенә калдыру проблемасы борчый. Россия мәктәпләрендә, уку йортларында, башта туган телләрне кимсетеп, «региональ компонент» дигән сылтау белән, аннан тел буларак та укытудан тыю турында законга кул куелу хәбәрен бөтен татар җәмәгатьчелеге ишетеп шакката, моңа каршы күтәрелә. Аныңча, иманлы булган һәр халык теләсә нинди халыкның туган телен яклап аваз салырга тиеш. Язма ахырында тел татар өчен аңлашу чарасы булудан бигрәк, мөстәкыйльлеген саклаучы суверенлык формасы ул, дигән фикер өстен чыга.

Әлеге репортажда автор метро ишекләренә язылган «Сөялмәскә» дигән язуны үзенчәлекле деталь рәвешендә куллана. Бу сүзне А.Хәлим татар милләтен кризистан коткарырга сәләтле бер чара-чакыру дип бәяли. Татарны сөялмичә, үз көче белән яшәргә чакыра. Моның өчен берничә юл күрсәтелә. Шулар арасында – татар теле-моңы, татар психологиясенә нигезләнгән милли мәктәпләр булдыруны автор төп бурыч-максатлар рәтенә кертә. Бу уңайдан автор белән килешми мөмкин түгел. Галимнәр фикеренчә, үз туган телендә белем алу балага җиңелрәк бирелә һәм белемне үзләштерү, аңлау дәрәҗәсен арттыра. Публицист А.Хәлим фикеренчә, балада югары әхлак сыйфатларын, шул исәптән туган телгә мәхәббәт, милли үзаң тәрбияләү бары тик билгеле бер эзлеклелектә максатчан рәвештә башкарылганда гына нәтиҗәле булачак.

Белгәнебезчә, илдә Мәгариф турындагы яңа закон проекты эшли башлады. Аның нигезендә төбәкләрдә туган телне укыту мөмкинлеге калдырылды. Проектны әзерләнгәндә, бу киң җәмәгатьчелекне уйланырга мәҗбүр иткән мәсьәләләрнең берсе иде. Туган телләрне өйрәнүгә багышланган 14 нче маддәнең 3 нче пунктында «РФ республикаларында субъектларның законнарына ярашлы дәүләт телләрен өйрәнү һәм укыту кертелергә мөмкин. Төбәкнең дәүләт телләрен өйрәнү РФ дәүләт теленә зыян китерү исәбенә өйрәнелергә тиеш түгел» дигән искәрмә дә бар.

Ни кызганыч, әмма бүген «Киләчәктә балама татар теленнән бигрәк рус теле кирәк булачак,» – дигән фикердә торучы ата-аналар күп. Аларның шушы ялгыш карашларын төзәтү, татар теленең халкыбызның рухи-мәдәни байлыгы икәнлеген аңлату, моңа инандыру укытучы, тәрбиячеләрнең генә түгел, журналист-публицистларның да уртак бурычы.

Чыганаклар

1. Хәлимов А. Н. Яшисебез килә: сайланма публицистика. Казан: Рухият, 2009. 664 б.

2. Хәлимов А. Иле барның теле бар // Казан утлары. 1990. № 11

3. Хәлимов А. Безгә ничек исән калырга? // Шәһри Казан. 2007. 1, 8, 9

июнь.
4. Хәлимов А. Татар милләте өчен кануннамә // Социалистик Татарстан. 1996. 16 февр.
5. Хәлимов А. Сөялмәскә: Казан метросының «Тукай» мәйданы тукталышыннан репортаж // Татарстан яшьләре. 2008. 12 февр.

Тема образования и воспитания в журналистском творчестве Г.Исхаки

А.З.Мубаракзянова, соискатель КФУ
(научный руководитель – проф. В.З.Гарифуллин)

Выдающийся писатель, публицист и общественный деятель Гаяз Исхаки родился в 1878 году, в период набиравшего ход джадидистского движения. Его родители стараются изо всех сил, что бы их мальчик получил хорошее образование. Г.Исхаки с малых лет проявляет себя старательным учеником. С пяти лет он учится читать и писать. После того как получает начальные знания в медресе своей родной деревни, в 1890 году переходит в Чистопольское медресе, где уже начинали преподавать по новому методу. Спустя три года он переезжает в Казань и начинает повышать свои знания в Приозерном медресе.

Несмотря на то, что новый метод обучения значительно повышал качество образования у шакирдов, Г.Исхаки не могли удовлетворить те скудные знания, которые он получал в медресе. Он приходит к выводу, что для доступа к высшим наукам необходимо выучить русский язык и принимает решение поступить в Татарскую учительскую школу. Эта школа была открыта в миссионерских целях среди татар и очень скоро начала приносить завидные плоды в виде прекрасно образованных людей, составивших татарскую элиту того времени. В 1898 году Г.Исхаки поступает в Татарскую учительскую школу. В стенах этого учебного заведения вместе с ним получили образование будущие светила татарской культуры С.Максуди, Х.Ямашев, Ш.Мухаммадьяров, Г.Кулахметов. Здесь Гаяз Исхаки впервые знакомится с литературными произведениями русских и зарубежных классиков И.Тургенева, Л.Толстого, Ги де Мопассана, Оскара Уайльда и др. Это значительно расширяет его кругозор и оказывает сильное влияние на характер его творчества в будущем. Уже тогда он начинает понимать основополагающую роль хорошего образования в развитии нации, что только если в корне изменить систему образования в медресе, нация воспитает достойных представителей современного общества. Возможно, на него повлияли и литературные произведения, где культивировались идеи просветительского реализма, согласно которому общественную жизнь и человеческую личность можно совершенствовать путем нравственного воспитания на примере прекрасных образцов достойных дел и поступков. Успешно закончив Татарскую учительскую школу, он переезжает в Оренбург и начинает преподавать в одном

из самых продвинутых медресе того времени «Хусаиния». У него уже был опыт преподавания в одном из медресе Новой Слободы, где он прославился своим радикальным подходом к обучению, использованием новых методов, тем самым очень быстро завоевал любовь и уважение шакирдов.

Построенное братьями Хусаиновыми медресе «Хусаиния» было самым благополучным и славилось своими строгими порядками. Но получивший европейское образование Гаяз Исхаки нашел в здешних порядках множество изъянов. Особенно его не устраивали отношения между преподавателями и шакирдами, и, как следствие, тяжелая моральная атмосфера, царившая в медресе. Преподаватели с радостью возложили часть своих учебных часов на плечи молодого учителя. В результате, если у всех учителей в день приходилось по три, самое большее по четыре часа уроков и один выходной день, то у Гаяза Исхаки было по шесть часов в день, без выходных. Засучив рукава, он принялся за работу. Невзирая на загруженность, он активно участвовал и в общественной жизни медресе, первым делом приведя в порядок библиотеку.

Надо заметить, что шакирды с опаской приняли молодого учителя. Они откровенно не понимали, чего он от них хочет. Ведь до его прихода все, что творилось в медресе, они воспринимали как должное, как само собой разумеющееся. Гаяз Исхаки же не мог смириться с такой показной мнимой благопристойностью. С первых дней своего преподавания он учит шакирдов быть искренними и высказывать то, что они думают на самом деле, а не заискивать перед преподавателями. Гаяз Исхаки прикладывает все усилия, чтобы установить с шакирдами честные, дружественные отношения. Вскоре и сами шакирды прониклись к нему глубоким уважением и с нетерпением стали дожидаться его уроков. Им становится интересно проводить время с начитанным человеком, который умел самостоятельно мыслить и не выражался заштампованными фразами. Это его качество стали перенимать и шакирды. С его приходом они начинают более трезво оценивать порядки в своем медресе и высказывать свое недовольство существующими порядками. Учителям, привыкшим к тихой и беззаботной жизни в медресе, пришлись не по нраву эти новые веяния и они постарались поскорее избавиться от молодого учителя-бунтаря. И в скором времени они этого добились. Однако сами же после его ухода очень часто любили вспоминать его остроумные выходки и высказывания и, кажется, даже немного по нему скучали.

Недолго переживая о потерянной работе, Гаяз Исхаки приступает к сочинению произведения «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (Исчезновение спустя 200 лет), которое он начал писать еще во время учебы в Татарской учительской школе. В этой фантастико-публицистической повести автор выражает свое несогласие с нынешним заторможенным положением татарской нации. Имея богатый опыт преподавания и будучи хорошо знакомым с жизнью медресе изнутри, одной из главных причин отсталости он определяет несовершенную систему образования у татар.

В своей публицистической деятельности он не раз будет возвращаться к теме образования. Тем более, с каждым годом эта проблема начинает усугубляться, так как сама молодежь начинает протестовать против устаревших порядков. Например, 26 февраля 1906 года 82 шакирда в знак протеста покидают стены медресе «Мухаммадия».

Ближе к началу нового учебного года в августовском номере газеты «Таң йолдызы» за 1906 год выходит его статья «Мәктәп-мәдрәсәләр» (Школы-медресе), в которой он вспоминает об этом инциденте и анализирует настоящее положение дел. Из статьи мы узнаем, что для многих людей обучение в новом году будет очень затруднительным, так как был голодный год, и у многих просто-напросто не хватит средств, чтобы дать образование своим детям. Да и стоит ли то образование, которое могут дать татарские медресе тех денег, которые с таким трудом достаются простому народу, спрашивает автор. Ведь в прошлом году шакирды не захотели тратить свое драгоценное время и покинули стены медресе. Что же изменилось с тех пор? Несмотря на небольшой объем, статья очень емкая по содержанию. Еще раз убеждаешься в мастерстве аргументации автора. Нет ничего лишнего. За каждым предложением следуют логическое развитие мысли и возможное решение проблемы. Эта статья поднимает очень важный и животрепещущий вопрос в сфере образования татарского народа – вопрос финансирования обучения в школах и медресе: «Несмотря на то, что наш народ оплачивает множество земских сборов, а городские жители наравне со всеми отдают деньги на нужды города, ни копейки из этих денег они не могли использовать на обучение своих детей» (Таң йолдызы, 1906, 5 авг.).

Г. Исхаки делает вывод, что финансирование татарских школ и медресе должно производиться из казны наравне с русскими учебными заведениями. Образование не должно быть доступным лишь привилегированной прослойке общества. Еще одна проблема, которая упоминается в данной статье – это необходимость подогнать к европейским стандартам саму программу обучения. Но эта тема упоминается лишь всколзь. Вопрос финансирования образования из казны в статье является доминирующей. Нельзя не отметить главную особенность статей Гаяза Исхаки – его критика никогда не оставляет ощущения пустого сотрясания воздуха. Он всегда предлагает действенное и наиболее удобное решение поставленной проблемы. Например, чтобы закрыть вопрос оплаты обучения, он считает, необходимо провести честное, справедливое тайное голосование, в котором не будут иметь значение ни национальность, ни вероисповедание, ни пол кандидатов. Избранная таким образом мощная Дума сможет, по его мнению, решить озвученные проблемы.

В статьях «Оренбургтагы Хөсәеновлар мәдрәсәсе» (Оренбургское Медресе Хусаиновых), «Мөгаллим вә мөгаллимәләребезнең бу көнге вазыйфалары нәрсә?» (Какие задачи стоят сегодня перед учителями и учительницами?), «Мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе» (Проблема школ и медресе) Гаяз Исхаки берется анализировать не менее наболевший вопрос – вопрос внутреннего устройства медресе, взаимоотношения учителей и шакирдов,

кадровые вопросы и саму программу обучения. Несмотря на то, что появился новый джадидистский метод обучения, который намного эффективнее, во многих медресе продолжали обучать по устаревшему методу. Более того, многие представители духовенства развернули борьбу против нововведений в системе образования. Это значительно мешало культурному развитию нации в целом. Например, в статье «Оренбургтагы Хөсәеновлар мәдрәсәсе» (Оренбургское медресе Хусаиновых) Г.Исхаки пишет: «Медресе Хусаиновых – по внутренним и внешним порядкам является одним из первых учебных заведений. Шакирды там сидят за партами, так и учителя выполняют свою работу. Однако, за 15 лет медресе мало чем послужило нашему народу. Несмотря на то, что расходов на нее тратится значительно больше, по сравнению со старыми медресе плодов она принесла не больше» (Таң йолдызы, 1906, 10 авг.).

А все потому, решает он, что преподаванием занимаются безграмотные учителя, а кадровая политика производится по принципу родства и знакомства. Г.Исхаки без всякой опаски называет по именам тех, кому следует слезть с кресла преподавателя. Автор пламенно критикует методы их воспитания. Ведь к шакирдам в медресе они относятся как к арестантам. Допросы, бесконечные обыски, рукоприкладство по поводу и без повода, абсолютная ограниченность шакирдов от внешнего мира, отсутствие доступа к разнообразной литературе и к периодике никак не способствуют получению знаний, а скорее наоборот. Автор предлагает применить самые радикальные действия в отношении подобных преподавателей. Их срочно нужно освободить от их полномочий. Их места должны занять грамотные, образованные, сведущие в педагогике люди. Нельзя к медресе относиться как к бизнесу. Расходы должны идти на нужды классов, библиотек, на нужды самих шакирдов, а не оседать в карманах учителей. Да и с шакирдами у учителей должны установиться дружеские, честные отношения. Только в таком случае, наши медресе будут развиваться, считает автор.

Очень образно Гаяз Исхаки выражает свое отношения к сторонникам устаревшего метода обучения в статье «Мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе» (Проблема школ и медресе): «Сейчас опять насупила осень, начался новый учебный год. С разных концов страны начали собираться шакирды. Муллы стряхнули со своих прогнивших учебников «Солям-аль голюм» и «Шахри мулла» паутинные гнезда и готовятся вить паутинные гнезда в головах шакирдов» (Таң йолдызы, 1906, 9 сент.).

Здесь же мы можем убедиться, как с помощью языковых оборотов автор добивается большой экспрессивности в тексте. Например: «У нас в Казани есть множество зданий, именуемых медресе» (Там же). Этим автор намекает на то, что медресе на самом деле не выполняют тех функций, которые на них возложены.

Г.Исхаки активно публикуется в первом специализированном научно-образовательном журнале на татарском языке «Мәктәп», который начинает издаваться в феврале 2013 года. В статье «Тәрбиядә берлек» (Единство в

воспитании) он поднимает вопрос о роли национальных школ в объединении татарской нации. Для этого, по мнению Исхаки, все татарские школы должны работать по единым программам.

В статье «Мөгаллим вә мөгаллимәләребезнең бу көнге вазыйфалары нәрсә?» (Какие задачи стоят сегодня перед учителями и учительницами?), опубликованной в 1-ом номере журнала «Мәктәп» от 1914 года, обсуждается кадровая проблема татарских медресе. С 23 декабря 1913 года по 4 января 1914 года в Петербурге проходит первый Всероссийский съезд учителей. На нем принимает участие Гайса Еникеев с выступлением о положении дел в мусульманских школах и медресе. По поводу этого события и написана данная статья, являющаяся ярким примером грамотного построения и аргументации главной мысли у Гаяза Исхаки. В самом начале обозначается проблема – неэффективная программа обучения, моральный климат в медресе. Чему должны обучать в джадидистских медресе, что должны забратҗ с собой дети, закончившие это учебное заведение? И самое главное – как добиться решения национальных проблем с помощью образования? Далее следует подробное исследование поставленных вопросов. Так как национальное самосознание у татар на тот момент пребывало на очень низком уровне, воспитание национальных чувств, по мнению Г. Исхаки, являлось прямой обязанностью учителей. Они должны воспитать новое грамотное и образованное поколение татар.

В статье поднимается вопрос языка: «Разбросанные по разным концам России татары разговаривают на разных диалектах. Пензенские и Нижегородские мишаре даже не разговаривают, а перекрикиваются на каком-то языке, похожем на татарский. Школа должна научить детей говорить на правильном литературном татарском языке, тем самым объединяя разрозненный народ. Поэтому преподавание должно идти на литературном языке казанских татар. Так же и в мишарских деревнях учителя обязаны объяснить детям, что тот диалект, на котором они говорят, не является татарским языком, и использование разговоре русских слов является ошибочным и неправильным. Если школа не смогла обучить детей литературному языку, значит, она не справляется со своими обязанностями» (Мәктәп, 1914, №1. С.4).

Интересно выглядит его сравнение женщин и мужчин в подходе к воспитанию. Например, так как мужчины находятся в постоянных разъездах, то их речь обрастает разными диалектами в зависимости от их круга общения. Женщины же сидят дома, являются хранительницами чистого родного языка. Так же и при воспитании детей именно от женщин, по мнению Гаяза Исхаки, зависит чистота родного языка у татар. Автор отмечает особую роль женщин и в школах. Он замечает, как часто дети перенимают манеры своей учительницы. Значит, являясь достойным примером для детей, значение женщин в системе образования многократно увеличивается. По словам Гаяза Исхаки: «На сегодняшний день самая важная и нетрудная задача – это построить крепкую основу системы образования и работать над тем, чтобы у нас были по

настоящему национальные школы. Чтобы после трех-четырех лет обучения воспитался настоящий татарин. Пусть и душа, и речь, и мышление, и чувства у него будут о родном татарском народе. Только в этом случае, наша культура будет крепкой. Только так наша родная культура не сломается, не сотрется несмотря ни на что» (Там же).

Во всех статьях, посвященных системе образования, проявляется настоящее мастерство выдающегося публициста Гаяза Исхаки. Его статьи получаются очень содержательными и аргументированными. Главное, они не теряют свою актуальность и по сегодняшний день. Даже сегодня в статьях Гаяза Исхаки мы можем почерпнуть множество полезных идей, касающихся национального образования. Он внес неоценимый вклад в развитие национального образования у татар. Причем не только с помощью публицистики. За годы преподавания он сам воспитал множество шакирдов, которые внесли свой вклад в развитие нации. Нельзя не сказать и о том, что он приложил немало усилий, чтобы построить и открыть школу в своей родной деревне Яуширма. А самое важное, после многих лет замалчивания о существовании такой личности как Гаяз Исхаки, его творческое наследие вернулось к нашему народу и на его произведениях воспитывается новое поколение.

Әминә Закирова – журналист

Э.Н.Сөләйманова, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – филология фәннәре кандидаты
Л.Р.Сабирова)

Әминә Әхмәтҗан кызы Закирова – тәҗрибәле журналист. Журналистикага ул 43 ел гомерен багышлый. 12 ел педагог буларак хезмәт куя. Шушы вакыт эчендә күп кенә бүләкләргә дә ия була. Дәһшәтле сугыш елларында Әминә ханым Әлкидә, Әгерҗедә газета чыгара. Районнарда журналистиканы үстерү өчен зур эшләр башкара. Алга таба «Совет Татарстаны» газетасында, «Ялкын» журналында эшли.

Татар журналистикасында тирән эз калдырган шәхес булса да, әлегә кадәр Әминә Закирова иҗатын өйрәнүчеләр булмаган. Шуңа да журналистның бормалы, сикәлтәле тормыш юлы белән таныштырырга телим. Чыганак буларак, Әминә ханымның үз кулы белән язып калдырган автобиографиясе, Нури Закировның «Космическая хроника 60-70 годов. Автобиографические заметки с итогами» дигән китабы, Фәйрүзә Мөслимованың «Сөембикә» журналында (1999, май) чыккан «Кеше китә, эзе кала» язмасын кулландым.

Әминә Әхмәтҗан кызы Закирова 1910 елның 27 апрелендә Чиләбе шәһәрендә дөньяга килә. Октябрь революциясенә кадәр әти-әнисе Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә яшиләр. Әтисе Әхмәтҗан Троицк шәһәрендә

Галиев дигән байда чимал җыючы булып эшли. Аның бер аягы нык аксый торган була. Ә әнисе Сәхипҗамал дүрт баласын тәрбияли, хуҗабикә була.

1922 елның җәендә, Әминәгә 11 яшь булганда, авырлыкларны күтәрә алмыйча, әтиләре үлеп китә. Балалар әниләре җилкәсендә кала. Анага кешеләрдә эшләргә туры килә. Машина юнәлтеп, тегү тегә башлый. Аннан соң олы улы Шакир эшкә керә. Әминә дә яшелчә бакчасына эшкә йөргәли. Тормышлары авыр була, алабутага кадәр ашыйлар. Өйдә булган бар нәрсәне саталар яисә кулакларга әче катыкка алмаштыралар. Нәни Әминә байларга идән юа, елгадан көянтә белән су ташый. Хөкүмәт дөге боткасы һәм кукуруз онынан берничә кисәк ипи бирә башлый. Шул гына аларны ачлыктан, үлемнән коткарып кала һәм Әминәгә мәктәптә укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә.

Әминә «Сөембикә» башлангыч мәктәбендә укый. Бу мәктәпне ул мактау кәгазе белән тәмамлый.

1924 елда алтыеллык татар-башкорт педагогия техникумы ачыла. Анда урта белем бирәләр, авылларга җибәрергә укытучылар әзерлиләр. «1924 елның җәе иде. Каядыр, кемнәндер, ярлы балалары өчен техникум ачыла икән, дигән хәбәр ишетеп кайттым. Уку теләге миндә шул кадәр көчле иде, керү шартларын да, кемнәрне хәзерләп чыгаруын да белмәстән, «укырга керәм» дигән уй мине баштанаяк биләп алды. Өйдә бу теләгемне бик хупламадылар. «Өстеңә-башыңа юк, нәрсә киеп йөрмәкче буласың» дип иң элек әни каршы төште. «Анда зурларны гына укыталар, син бит әле русча да белмисең» дип абый да кире кагарга теләде. Юк, бу сүзләр барыбер мине айныта алмады, бер нәрсә минем башыма нык сеңеп калган иде: техникум ярлы балалары өчен! Шулай булгач, ник мине алмасыннар?! Ләкин үзем генә барып сүз салырга тәвәккәллегем җитми иде. Мин үзебезнең урамда торучы кызларны котыртырга керештем. Ә алар миннән көлделәр генә. Чынлап та, икмәккә тамагың туймаган, өс-башка кияр нәрсә булмаган бер вакытта «укыйм» дип шашынып йөрү бәлки җүләрлек тә булгандыр. Белмим, нәрсә мине очындыргандыр, кечкенәдән укуга булган мөнәсәбәтме, әллә үзем дә сизмәстән, революциядән соң алдыбызда ачылган яктылыкка омтылумы, һәр хәлдә миндә кабынган уку ялкыны сүнәргә уйламады да.

Бөтен кыюлыгымны җигеп, техникумга үзем генә киттем», –дип яза бу турыда Әминә Закирова.

Имтиханнарны яхшы тапшырып, ул техникум студенты була. «Техникумда алты ел уку дәверендә үзебез укучы, үзебез мич ягучы, үзебез идән юучы булдык. Анда китап төпләргә, столярлык һөнәренә өйрәндек. Ял көннәрендә өмәгә бармаган көннәребез сирәк булгандыр. Җир казып, трубалар салып, шәһәргә водопровод үткәрдек. Берничә километрга тезелеп шәһәрнең бер читендәге кирпеч заводыннан, икенче читендәге тимер юл вагоннарына кирпеч төягән көннәр дә аз булмады», – дип яза истәлекләрендә Әминә Әхмәтҗан кызы. Техникумның өйрәнү хуҗалыгында сука артына басып үгезләр белән җир дә сөрә, ашлык һәм яшелчә дә чәчә, аларны үстерә, печән дә чаба, кибән дә куя студентлар. Үзләре аш пешерә, үзләре җыештыручы була. Ләкин ару-талуны белми, белем алырга омтыла алар.

Әминә Закирова драмтүгәрәккә дә йөри, концертларда катнаша, мандолинада яхшы уйный. 1929 елда комсомолга керә. 1930 елда, соңгы курста, завод эшчеләрен укыта.1930 елда техникумны тәмамлый.

«Чиләбедә туып, Троицкида ярлы эшче гаиләсендә үскән кыз – Әминә Усманаева – Троицк татар-башкорт педагогия техникумында укып, балаларны да, өлкәннәрне дә укыту эшенә алынган.

– Мин авылга китәм. Кая булуы әһәмиятле тугел. Тик матур табигатле, урман-сулы якка җибәрегез, – дидем.

– Мин күптән түгел Барда якларыннан йөреп кайттым, – диде директор абый. – Хәйран матур җирләр, икенче Кавказ диярсең. Шунда җибәрсәк барырсыңмы?

– Барам, берсүзсез барам! – дидем мин шатланып.

Әминә апа истәлекләрендәге бу язма – аның борма-борма юллардан торган язмышындагы беренче тәэсирләре, беренче өметләре генә әле. Аннан соң да кабат-кабат юлларга чыгасын, яшәгән төбәкләрен, аралашкан кешеләрен, эш урыннарын туктаусыз алыштырып торасын каян белсен, ди ул?» – дип яза Фәйрүзә Мөслимова «Сөембикә» журналында чыккан язмасында.

Барда Мәгариф бүлегендә аны район үзәгеннән 3 километр ераклыктагы Әрҗән авылына җибәрәләр. Биредә ШКМ каршында техникумнарга хәзерләү өчен ике айлык курслар була. Әминә Закированы шунда татар теле һәм математика укытучысы итеп куялар. 2 айдан соң аны Бардадан 20 километр ераклыктагы зур бер авылга – Сараш башлангыч мәктәбенә укытырга җибәрәләр. Әминә колхоз оештыру эшләрендә актив катнаша. Авылда драмтүгәрәк оештыра. Сарашта комсомол оешмасы төзи.

1931 елның августында Әминә НКВД хезмәткәре Нури Закировка кияүгә чыга. Ирен нинди шәһәргә, нинди эшкә билгеләсәләр, аның белән бергә күченеп йөрергә туры килә аңа.

Өйләнешкәч, тормыш иптәшен Чиләбе өлкәсенә эшкә җибәрәләр. Монда Әминә башлангыч мәктәптә эшен дәвам итә. 1931 елда Нурины Ленинградка укырга җибәрәләр. Бер елдан соң аларны Свердловскига күчерәләр.

1933 елның 22 октябрендә уллары Урал туа. Әминә 4 нче номерлы җидееллык үрнәк мәктәптә укыта башлый.1932 елның ноябреннән 1936 елның августына кадәр Урал өлкәсенең укытучыларына һәм техникум студентларына күрсәтмә дәресләр бирә. Әминә Закировага «Укытучы-ударница» дигән исем бирәләр. 1936 елда Нури Закировны Свердловск өлкәсе Манчаж районына күчерәләр. Әминә РАЙОНОда татар мәктәпләренең инструкторы булып эшли. Барлыгы 12 татар мәктәбе була.

1938 елда янә күченү. Нурины Татарстанга – Казанга җибәрәләр. Әминә 13 номерлы урта мәктәптә укыта башлый. Аңа монда «Укытучы-отличница» исеме бирәләр.

1940 елны аларны Нурлатка, 1942 елны Әлки районы Базарлы Матак авылына күчерәләр. «Әлки районы исә Әминә апаның тормыш юлында кискен борылышлар ясаган төбәк. Район үзәгендә татар мәктәпләре булмаганлыктан, ул биредә мәгариф бүлегендә эшли башлый. Вакыты да нинди бит – 1942 ел,

дәһшәтле сугыш бара. Ирләр барысы да диярлек фронтта. Бөтен эш балалар, хатын-кызлар җилкәсендә. Фронттан килгән хәбәрләрдә әлегә сөендерерлек, җанны җылытырлык түгел», – дип яза Фәйрүзә Мөслимова.

Әминә ханымны районның «Колхоз Алга» дигән газетага җаваплы сәркатип итеп эшкә күчерәләр. 1943 елның декабрендә Әминә Закированы газетаның мөхәррире итеп билгелиләр. Басма сүзнең бик кадерле чагы. Газетадан тыш, листовкалар чыгарырга да, радиотапшырулар алып барырга да кирәк бит әле! Кәгазьгә кытлык! Калдык-постыклары да алтын бәясе – аларына да азык-төлек талоннарын басалар. Көн саен иртәнге сәгать 4 тә Әминә ханым Совинформбюро хәбәрләрен кабул итә. Алардан листовкалар әзерләп, почта белән авылларга таратасы була. Колхозларга да ярдәм итәргә кирәк. Редакциядә кадрлар җитми. Күп эшне үзенә генә эшләргә туры килә. Авыл советларына, колхозларга җәяү йөри,чөнки редакциянең аты булмый. Ул дүрт ел мөхәррир һәм шул ук вакытта җирле радиода диктор булып та эшли.

1945 елда ире белән аралары өзелә.

Журналистлык эшенә җиң сызганып керешеп киткән Әминә ханым сугыштан соң башка төбәктә кирәгрәк булып чыга. 1947 елның декабрендә ул Казанда үткән редакторлар семинарында катнаша һәм шуннан Әгерҗегә китәргә күрсәтмә алып кайта.

Журналист ханымны биредә дә очсыз-кырыйсыз эш көтә. Әминә Закирова газета редакторы гына түгел, типография директоры итеп тә билгеләнгән. Типографияне, һичшиксез, редакциядән аеру зарурлыгы килеп туа. Эшне шрифтларны алыштырудан башлый. Казаннан яңа шрифтлар кайтарта, чөнки булганнары шулкадәр искергән була, хәтта газетадагы кайбер хәрефләрне аңлап та булмый.

Бераздан радиотапшырулар редакциясе ачып җибәрәләр. Әлкидә туплаган бай тәҗрибәсен куллана Әминә Закирова. Коллектив14 кешедән тора. Эшләү көннән-көн күңеллерәк, җайлырак була бара. Әминә ханым Сталин исемендәге колхозга да булыша, стена газеталары чыгаралар. Шулай уңышлы гына ярты ел үтеп китә.

Әминә Закированы Казанга икееллык партия мәктәбенә укырга чакырталар. Анда аңа бик авыр була. Йөрәге авырта башлый. «Васильево» дәваханәсендә ял итеп кайта. 1951 елда бу мәктәпне уңышлы тәмамлый ул.

Әминәне Казанда «Совет Татарстаны» газетасында әдәби хезмәткәр итеп алып калалар. Казан баш киемнәре фабрикасында пропагандист булып эшли. Сугыш елларында чыгудан туктаган балалар журналын кабат чыгара башлый. Педагог булуын истә тотып, журналның мәктәп бүлеге мөдире итеп билгелиләр аны. «Ялкын» журналында Әминә Закирова 9 ел эшли. «Ялкын»да эшләү елларында Әминә ханым яңадан яшьлегенә – укытучы чакларына кайткандай була. Районнарга күп йөри, укучылар һәм укытучылар өчен конференцияләрдә, педсоветларда катнаша, дәресләр карый.

7 ел Язучылар берлегенең татар бүлегендәге профком әгъзасы булып тора, казначы вазифасын башкара. Татарстан Журналистлар берлеге оешкан 1957 елда берлек әгъзасы буларак алынып, анда 41 ел – гомеренең соңгы

көннәренәчә тора. Татар китап нәшриятында укыту-педагогия редакциясенең редакторы була. Журналист буларак, татар әдәбиятының күп кенә күренекле шәхесләре белән аралаша, Гариф Гобәй, Ләбибә Ихсанова, Гариф Галиев, Рәисә Ишморатова, Роза Хафизова, Мәхмүт Хөсәен, Гариф Ахунов, Әминә Бикчәнтәева кебек шәхесләр белән таныш була.

Әминә ханым 1963 елда, сәламәтлеге начараю сәбәпле, 2 төркем инвалид булып калса да, авыруына карамастан, мәкаләләр, очерклар язуын ташламый.

1965 елда тәрҗемәчелек эше белән шөгылләнә башлый. Дәреслекләр тәрҗемә итә (8,9,10 сыйныфлар өчен СССР тарихы). Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү буенча ул 23 ел эшли. Соңгы дәреслек – «Яңа тарих» 1988 елда чыга, аның бер өлешен Әминә Закирова тәрҗемә иткән.

Бердәнбер улы Уралны Ригада Югары хәрби авиация училищесында укыта. Соңыннан егет Мәскәү университетын тәмамлый. Озак еллар космонавтикага хезмәт куя. Физика-математика фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясенең алдынгы хезмәткәре, Россия космонавтикасы федерациясе әгъзасы ул – Урал Нуриевич Закиров.

Әминә Закированы әнисе белән рәттән Татар зиратында җирлиләр.

Туфан Миңнуллин публицистикасында тәрбия проблемалары

Л.И.Староверова, КФУ аспиранты,
“Болгар FM” радиосы алып баручысы
(фәнни җитәкче – филология фәннәре докторы,
профессор В.З.Гарифуллин)

Публицистик стильдә язылган материалда мәгълүмат фактларны тасвирлап кына калмыйча, авторның фикерен, кәефен дә укучыга җиткерә. Публицист комментарийлар, уйлануларын да күрсәтә ала. Публицистик язма өчен теге яки бу күренешне һәрьяклап тасвирлап бирү мәҗбүри түгел. Публицист, иң беренче чиратта, җәмгыятьнең аерым бер төркемендә кызыксыну уяткан вакыйга, проблема турында язарга омтыла.

Публицистиканың мөһим функциясе – укучыга тәэсир итү. Язма авторының максаты җәмгыятьтәге хәлләр турында гына сөйләү түгел, шулай ук китерелгән фактларга ышандыру да. Публицистик стильгә хас эмоциональлек, сурәтлелек ярдәмендә автор укучыны үз позициясенә ышандырырга тырыша.

Шушы сыйфатларның барысы да Туфан Миңнуллин публицистикасында бик ачык чагыла. Т.Миңнуллин Татарстан Югары совет депутаты буларак та, язучы буларак та татар милләтенең матди һәм рухи тормышы турында кайгыртты, аны яхшырту өчен көрәште. Туфан Миңнуллин әсәрләренең барысы буенча барган проблема – туган телне, гореф-гадәтләрне саклау проблемасы. Бүгенге җәмгыятьтә чишеләсе проблемалар бик күп. Алар арасында иң актуальләреннән берсе – милләтләрнең үзләренә караганда күпсанлыраклары арасында эреп югалудан саклану проблемасы.

Т.Миңнуллин – җор телле хикәяче, туры сүзле публицист һәм актив җәмәгать эшлеклесе иде. Ул даими эзләнүдә булды, күп иҗат итте, бик тә үзенчәлекле публицист буларак танылды. Ул үзенең һәр иҗат җимешен тормыштан алып, үз җаны-тәне аша уздырып яза. Журналистика Туфан Миңнуллинны формасы һәм эчтәлеге белән камил булган публицистикага алып килде. Теле бик бай. Образларны сурәтләүдә, төп идеяне ачуда, үз фикерен укучыга җиткерүдә телнең барлык мөмкинлекләреннән файдалана. Публицистик жанрларның нигезе итеп тормышны тирәнтен өйрәнүне, кеше психологиясенең иң катлаулы катламнарына үтеп керүне ала. Туфан Миңнуллин публицистикасы – эмоциональ. Аның әсәрләрендәге образлар беркемне дә битараф калдыра алмый.

Туфан Миңнулинның публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге уйланулар, көндәлекләр, фикерләрдән гыйбарәт. Тормыштагы теге яки бу вакыйгаларга булган мөнәсәбәтләрен, көтелмәгән очрашулардан туган тәэсирле хатирәләрен теркәп барып, язучы тормышны, аның үзгәрүле агышын нечкә сиземли, анда әледән-әле туып торган әхлакый социаль мәсьәләләрне оста тотып алып, аларны табигый һәм тормышчан итеп укучыга җиткерә белә. Башкалар өчен гадәти булып күренгән күренешләргә язучы күзе белән карау, гадәти хәлләрне тирән эчтәлекле фәлсәфи вакыйгага әйләндерү осталыгы хас аңа. «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Өмет» газеталарында, «Сөембикә», «Мирас», «Казан утлары» журналларында чыккан язмалары аша ул кешенең дөньяда яшәү мәгънәсе, аның җәмгыять һәм үз алдында җаваплылыгы, әхлакый сафлыгы, намусы, үз халкының үткәне һәм хәзергесенә ихтирамы һәм киләчәккә ышанычы турында тирән фикерләр әйтте.

Публицист үзенең хезмәтләрендә гаилә, ир-ат, хатын-кыз, авыл, балалар язмышы темаларына аеруча яратып яза. Хатын-кызларның җәмгыятьтәге роле, гаиләне җылытучы, саклаучы икәнлегенә, гаиләдә ир кеше – ир булып, хатын-кыз үз урынында булса гына төзек гаилә төзелүенә ишарә ясый. Аның әхлак темасын яктырткан «Ялгышлар һәм язмышлар», «Ирләр кирәк, әтиләр кирәк», «Их дөньясы, дөньясы» һәм башка күп кенә язмалары тормышта төрле хәлләр алдында калган кешеләр язмышын ача. Язмалары аша ул бер-береңә мәрхәмәтле, игътибарлы булырга, акны карадан аера белергә өйрәтә, рәхимсезлек һәм битарафлыкка борчыла. «Ни өчен кеше туа, яши? Тәмле ашап, матур киенеп бер максатсыз яшәү өчен генә нигә туып торырга? Әти-әни, әби-бабай, нәсел-нәсәп, балалар, оныклар, туган-тумача – болар барысы да безнең асылыбыз. Шуларны онытмыйк!» – ди Туфан Миңнуллин.

Яшь буынны милли рухта тәрбияләүдә аның төрле өлкәдәге хезмәтләреннән һәрдаим файдаланырга була. Аңа оригиналь фикерләү сәләте, тормышны өйрәнеп белү тырышлыгы, аны чагылдыру осталыгы бирелгән.

Т.Миңнуллинның әсәрләре укучыга тәэсир итә. Автор борчыган проблема турында мөмкин кадәр киңрәк аудиториягә җиткерергә тырыша. Аның геройлары күп сөйләшми, монологлары кыска, диалоглары җанлы һәм мавыктыргыч. Ул геройларын көчләп сөйләштерми, алар үзләре сөйләшә, үзләре мөстәкыйль тормыш белән яши, уйный-көлә, шаяра. Туфан Миңнуллин

публицистикасының тагын бер үзенчәлеге – ул җөмләләрне бер төрле итеп төзү һәм аларның азагы бертөрле сүзгә генә тәмамлану.

Туфан Миңнуллинның кешеләрне, тормышны, табигатьне, бар дөньяны яратуыннан киләдер. Аның әсәрләрендәге яман затлар да бөтенләе белән яман түгел, ә бәлки ялгышкан, адашкан бичаралар. Хәтта адәмнәрнең җанын алырга килгән Газраил дә Туфан Миңнуллин кодрәте белән әкренләп яхшы якка үзгәрә.

Туфан Миңнуллинның һәр әсәрендә, әсәрнең үзәгендә ихласлык һәм халык язмышы өчен борчылу ята. Ул һәр сүзне кайда һәм ничек итеп әйтергә кирәклеген яхшы белә. Туфан Миңнуллин әсәрләре гаҗәеп бай һәм мавыктыргыч, сихри һәм үзенчәлекле тормышчан бер дөньяга алып керәләр. Алар рухи яктан баеталар, саф әхлак, әйбәт зәвык булдыруга ярдәм итәләр, яхшыны яманнан аерырга өйрәтәләр.

Туфан Миңнуллин пубицистикасының тагын бер үзенчәлеге – аның сюжетлы булуында. Шуңа да авторның әсәрләрен укыганда, үзеңне шул вакыйгалар эчендә итеп тоясың. Бу бигрәк тә әдипнең «Язмышлар һәм ялгышлар» очеркында ачык чагыла. Көндәлек язмалар сериясенә караган әсәр булгач, әлбәттә, монда автор «мин»енә зур роль бирелә. Әсәрнең эчтәлеге шуннан гыйбарәт: автор, ягъни Туфан Миңнуллин, төрмәдә утыручы бер ханым белән хат алыша. Беренче булып ханым үзе яза. Төрмәдә спектакль куяр өчен, драматургның берничә пьесасының тәрҗемәләрен сорап яза ул аңа. Язучы аның үтенечен үти, рәхмәт хаты көтә, тик бу ханым югала. Күпмедер вакыттан соң язучыга үз эшләре буенча шул төрмәгә барырга туры килә һәм ул монда хат авторын очрата. Әлеге хатын-кыз аны үзе таба. Менә шушы вакыттан аларның актив рәвештә хат алышулары башлана. Исеме дә ачыклана. Мөнирә исемле ханым була бу.

Очеркның композицион төзелеше бик кызыклы. Ул безгә әсәрнең сюжетын публицистик тасвирлау чарасы итеп карарга мөмкинлек бирә. Монда барлык эчтәлек ике геройның да хатларыннан һәм авторның шуларга биргән комментарийларыннан, өстәмәләрдән тора. Әлеге очеркта сюжет бар һәм ул дөрес, реаль булган вакыйгаларга нигезләнгән. Шикләнер урын юк: автор һәр хатның датасын, вакыйгалар урынын, исем-фамилияләрне күрсәтә. Болар барысы да журналистик-публицистик стильнең беренче лексик үзенчәлеген – төгәллеккә, документальлеккә ирешү чараларын тәшкил итәләр.

Проблема да монда күпкырлы, алар бер-берсе эчендә урнашкан кебек тоела. Мәсәлән, Т.Миңнуллин Козловка исемле хатын-кызлар төрмәсенә килеп кергәч, хатын-кызлар арасында җинаять проблемасы турында уйлана башлый: «...Мин, әлбәттә, кая барганымны белеп бардым. Төрмәнең санаторий түгеллеген барыбыз да беләбез. Шунысы кызык: төрмәнең ни икәнен белсәк тә, шуның тирәсендә буталабыз. Һәм, билгеле инде, күп буталган кеше бер эләгә. Төрмәдә беренче тапкыр булсам да, аның «кыяфәтен» сурәтләп, андагы таләпләр турында язарга җыенмыйм. Үземне тетрәткән күренешләрне һәм шул уңайдан туган уйларымны гына теркәп куям.

Тетрәнүемнең иң беренчесе: төрмә ишегалдына кергәч, андагы әллә ничә йөзләгән хатын-кызны берьюлы күрүем булды. Кояшлы матур көн һәм

ишегалды тулы хатын-кыз. Иң тетрәндергәне – барысы да диярлек яшьләр һәм чибәрләр. Гүзәлләр конкурсына җыелганнар да сәхнәгә чыгарга чират көтәләр, диярсең...»

Проблеманы сурәтләүдә Т.Миңнуллин саннарны иркен куллана: «Рәсәй халкының 70-80 процентын утыртып куярлык», «инде безгә 1980 елда туганнар килә башлады», «унсигез яшьтән егерме яшькә хәтлеләр төрмәдә 70 проценттан артык икән», «1980 елда туганнар». Болар язучының төрмәдә япь-яшь кызларның утыруына гаҗәпләнү хисен чагылдыра, аерым бер очракта сан «япь-яшь» сүзен алыштыра, укучыга көчле тәэсир итә. Әлеге саннар, хаттагы даталар (ә алар хронологик тәртиптә бирелә), күренеш һәм вакыйгалар, кеше исеме, атамалар, тел берәмлеге буларак, документальлекне көчәйтә.

Төрмә сурәтләве тәмамлангач, язучы проблеманың сәбәбен дә күрсәтә: «кешене яклый торган законнар эшләми, закон бозмыйча бүген Рәсәйдә яшәү – мөмкин түгел хәл», «юристлар әйтүенчә, кызларны җинаять юлына ир-атлар алып керә икән. Ә ирләр, гадәттәгечә, чибәрләргә күз салучан булалар. Кыяфәте чибәр, әмма башында мие булмаганнар, өендә тиешле тәрбия алмаганнар еш кына җинаятьче ирләр кармагына кабалар да ычкына алмыйлар икән. Аларның ихаха да михаха килеп типтереп йөрүләре төрмә белән тәмамлана икән. Аларны җинаять юлына алып керүчеләрнең күбесе иректә калып, бүтән «аңгыра сарык бәрәннәр»ен аздыралар икән ».

Әйе, «кызлар» карап торырга чибәр, ләкин күбесе – җенси авырулар, үпкә чире белән интегүчеләр.

Шушындый зур бер проблема эчендә шәхси проблема да килеп чыга. Бу – Т.Миңнуллинга хат язучы хатын-кызга – Мөнирәгә кагылышлы проблема. Язучы аның белән хат алыша. Проблеманың чишелешен табарга тырыша: «Мин аңа таулар вәгъдә итмәдем, әмма иреккә чыгарырга кулымнан килгәнне эшләргә сүз бирдем», «Комиссия әгъзаларына ул ханымнан хат алуымны һәм хатның эчтәлеген дә сөйләгәч, аны ярлыкарга – иреккә чыгарырга кирәк, дигән нәтиҗә ясадык».

Ахырдан әлеге ханымның проблемасы уңай хәл ителә. Т.Миңнуллин ярдәме белән аның эше Ярлыкау комиссиясе тарафыннан яңадан карала һәм аның карарына Президентның гына кул куясы кала. Бу турыда язучының Мөнирәгә адресланган тагын бер хаты сөйли.

Әсәрдә конфликт та бик үзенчәлекле бирелә. Конфликт язучының үзендә туа. Ханым белән хат алышканда, Т.Миңнуллин аның җинаяте нидән гыйбарәт икәнлеген белер өчен аны хөкем иткән судның хөкем карарын соратып ала һәм Мөнирәнең элек тә хөкем ителгәнен һәм аның үзен, баласын кызганып кына иректән мәхрүм ителмичә, шартлы рәвештә иректә калдырылганын белә. Менә шушы моментта язучының өмете өзелә, Мөнирәнең төзәләчәгенә шиге туа: димәк, Мөнирәнең бу юлы хөкем ителүе очраклы гына түгел, алай йөрүе яшәү рәвешенә әйләнгән булган. Бер уйласаң, вакыт әрәм итеп, өстеңә зур йөк алып, ярдәм итәргә тырышу да мәгънәсез бер эш кенәдер.

Соңынан, инде Мөнирәнең проблемасын чишкәч, автор яңадан үз-үзенә сорау бирә, шикләнә: әллә соң мин җинаять һәм җинаятьчене акларга

тырышаммы? Тик нәкъ шушы моментта үз-үзендә туган каршылыкны җиңеп чыгучы характер килеп керә: «Әгәр укучыларда да мондый шик калса, өзеп әйтәм: «Юк, җинаятьне беркайчан да аклап булмыйдыр. Әмма кешегә, хәтта ул җинаять кылган булса да, ышанып карарга кирәктер», – дип өнди автор.

Әлеге очеркта автор «мин»е ачык күренә дип билгеләгән идек инде. Монда ул төп геройның берсе. Проблеманы сурәтләгәндә, аның чишелешен эзләгәндә, сәбәбен аңлатканда да автор үз фикерен белдереп килә. Бу төшенчәләр белән факт тыгыз бәйләнештә тора. Ә очеркта факт, беренчедән, проблема барлыкка китергән, аны чишү өчен нигез булса, икенчедән, ул тасвирлау-сурәтләү чарасы да: «Хатын-кыз һәм төрмә. Бу ике сүзне бергә кушып әйтүе җанны әрнетә. Кешелек дөньясын яшәтер өчен яратылган зат кешелек дөньясының әхлакый законнарын таптап, кешелеген югалту дәрәҗәсенә җиткән. Хәер, хатын-кызның кадере булмаган, аңа бары тик эш аты итеп кенә караган илдә башкача була да алмый. Хатын-кызлар боксын телевизордан пропагандалаган җәмгыятьтә матурлыкка, гүзәллеккә, нәфислеккә соклану була алмый. Телевизордан шәрә ирләр белән шәрә хатыннарның аунашуын күреп үскән кызлар тотнаклы була аламыни? Безнең кызларыбызны бозыклыкка өйрәтәләр, без нишлибез? Сакланабызмы соң? Юк. Тудырабыз да урамга куып чыгарабыз. Аннан соң кызларыбызны-улларыбызны төрмәләрдән эзләп табып, ах-ух килеп җылап йөрибез».

Очеркта әдәби тасвирлау чаралары да актив эшкә җигелә. Мәсәлән, метафоралар файдаланыла: «язам дигән кешегә, тормыш аны өеп бирә». «укыганда күземнән яшьләр бәреп чыкты», «меңтөрле уй-хисләр бергә чуалып, җанның төпкеленнән күз яшен сыгып чыгардылар», «күзләрендә һәрвакыт мөлдерәмә тулы яшь булды. Түгеләм-түгеләм, дип тордылар да, ниһаять, бер түгелделәр», «хисләр җанымны айкадылар».

Чагыштырулар да уңышлы файдаланыла: «тормышның кәнфит кәгазе кебек тәти түгеллеген мин беләм, кешеләне дә идеаллаштырып, аларны әүлияга санамыйм», «төрмәнең санаторий түгеллеген барыбыз да беләбез», «кояшлы матур көн һәм ишегалды тулы хатын-кыз. Иң тетрәндергәне – барысы да диярлек яшьләр һәм чибәрләр. Гүзәлләр конкурсына җыелганнар да сәхнәгә чыгарга чират көтәләр, диярсең», «тормозы булмаган машиналарга охшый башладык».

Автор эпифорага еш мөрәҗәгать итә: «хәерлегә генә булсын иде инде. Сөенечкә генә булсын иде, көенечкә булмасын иде».

Риторик сораулар остасы Туфан Миңнуллин әлеге тел чарасын бу очеркта да еш эшкә җигә: «телевизордан шәрә ирләр белән шәрәхатыннарның аунашуын күреп үскән кызлар тотнаклы була аламыни? Безнең кызларыбызны бозыклыкка өйрәтәләр, без нишлибез? Сакланабызмы соң?», «дөньяда төрмәләр барын белмәдеңмени? Ялгыш адымыңны атлаганда «тукта!» дип әйтерлек көч таба алмадыңмыни?!»

Диалог очеркта үзенчәлекле рәвештә бирелә: ул автор белән Мөнирәнең хатлары аша барлыкка килә: «Исәнмесез, хөрмәтле Туфан абый! Иң изге теләкләр белән Сезгә хат язучы Мөнирә», «Саумысез, Мөнирә сеңлем!»

Очеркта укучының игътибарын гади сөйләм теле җәлеп итә. Гади сөйләм теле китап сөйләменнән үзенең яңачалыгы, җиңеллеге белән аерылып тора. Күп кенә публицистик әсәрләргә хас булганча, сөйләмдә кыска җөмләләр дә кулланыла. Әлеге җөмләләрдән тулы бер сурәт килеп чыга. Әсәргә көчле эмоциональ төсмерле лексика хас. Әлеге текстта публицист әдәби тел кысаларыннан чыгып китеп, сөйләмендә жаргоннар да куллана башлый.

Т.Миңнуллин әсәрләрендә – язмышлар, характерлар, тормыш сукмагындагы борылышлар. Шуларны тормышчан дөреслек юлына салу, кешене ышандыра алырлык чынбарлык ясау – әдип калдырган зур публицистик мирасның мөһим бер асыл сыйфаты.

Туфан Миңнуллин үзгәртеп корулар чоры тудырган проблемаларны, аеруча халкыбызның бүгенге язмышы, үткәне һәм киләчәге өчен борчылып, үз әсәрләрендә күрсәтә алды. Язучы кеше язмышын җәмгыять һәм милләт язмышы белән бәйләнештә карап, халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен тасвирлау аша һәр кешегә үз алдында торган бурычларын оныту ярамавын искәртә. Т.Миңнуллин милләтнең бөтенлеген саклау – бүген безнең төп бурычларыбызның берсе икәнлеген аңлата, татарның милли йөзен саклап калу өчен көрәш юлларын тасвирлый, милләтебез язмышына битараф булмаска өнди.

Туфан Миңнуллинның таланты милләт язмышын үз язмышы итеп яшәвендә, көчле-куәтле, серле-мәгънәле, шифалы-бәрәкәтле әсәрләр иҗат итүендә, үз халкының бәгырь кисәге, газиз баласы һәм яклаучысы була алуында!

Заманыбызның, тормышның кайсы ягына гына кагылмасын, Туфан Миңнуллин аны үзенчә күрә, үзенчә бәяли һәм халык күңеленең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек итеп сурәтли алды.

Кызыл Байрак и Сайдашев: об исторической роли Шигаба Ахмерова

А.Х.Фарукшин, бывший преподаватель Верхнеуслонской школы и ДШИ, руководитель общественного центра культуры и просвещения

Верхний Услон имеет на своей земле Кызыл Байрак и тем он славен. Ежегодно по инициативе камаловского театра здесь проходит «Праздник искусств», посвященный Салиху Сайдашеву. И начинается он с возложения цветов к памятнику композитора в виде мраморного камня – монолита, на котором выгравированы слова «Здесь в 1920- 1940 годы в летние месяцы жил выдающийся татарский композитор Салих Сайдашев».

Одним из первопроходцев, принимавшем активное участие в переселении татар на живописный берег Волги, был выдающийся общественный деятель

Шигаб Шарафутдинович Ахмеров, ставший и первооткрывателем музыкального таланта, гения Салиха Сайдашева, его воспитателем, наставником, заменившим отца.

Конец XIX – начало XX века. На стыке веков состоялся исторический ренессанс татарской культуры, выдвинувший замечательную плеяду деятелей культуры татарского народа. Среди них особое место занимает Шигаб Ахмеров, всей своей жизнью воплотивший в себе неистребимое свойство татарского народа – стремление к знаниям, к самоусовершенствованию, к просвещению своего народа в целом.

Сегодня, отмечая 100-летие журнала «Мәгариф», мы особо чтим его память как о выдающемся общественном деятеле, педагоге, журналисте. Именно он выступил в 1913 году в качестве организатора, учредителя и главного редактора журнала «Мәктәб», направленного на развитие образования татар. Отметим вехи, «говорящие даты» его жизни.

«Шигаб Шарафутдинович Ахмеров родился 30 декабря 1882 г. в деревне Задоровка Буинского уезда Симбирской губернии (ушёл из жизни 30 апреля 1966 г. в Казани), педагог, журналист. Образование получил в Буинском медресе. В 1901-1907 гг. преподавал татарский язык в сельских школах Казанской губернии. В 1908-1918 гг. главный редактор издательства «Сабах», одновременно в 1913-14 гг. издатель и редактор журнала «Мәктәб». В 1918-19 гг. совместно с Г.Ибрагимовым издавал журнал «Мәгариф», в 1920-22 гг. – член правления Татсоюза, в 1923-29 гг. – зам.председателя правления банка «Общество взаимного кредита».

Одновременно стал инициатором и организатором переселения на берег р.Волга отдалённых малоземельных татарских деревень (в т.ч. в д. Кызыл Байрак). Один из организаторов Восточного клуба. Автор букварей татарского языка, работ по истории книгопечатания. С 1912 г. в семье Ахмерова воспитывался один из основоположников татарской профессиональной музыки С.Сайдашев. Ахмеров необоснованно репрессирован (1929), реабилитирован в 1959 г» [1].

Приведём в кратком изложении сведения из книги Д.З.Саиновой-Ахмеровой «Салих Сайдашев» (страницы жизни и творчества композитора), которую автор посвятила светлой памяти матери Салиха Сайдашева-Махубжамал, сестры его – Амины и воспитателя и наставника – Шигаба Ахмерова.

Шигаб Ахмеров был занят вместе с председателем ТатЦИК Гани Ганеевым (родственником Саидгалеева) организацией переселения малоземельных крестьян из далеких татарских деревень на пустующие земли на правом берегу Волги. Как известно, после завоевания Казани Иваном Грозным татарам не разрешалось селиться вблизи Казани, а в других местах отводились небольшие земельные наделы. На огромных же пространствах на правом берегу Волги пустовали плодородные земли.

Многие представители татарской интеллигенции включились в осуществление этого замысла. С их помощью на пустующих землях появились

татарские деревни: Бахчисарай, Кызыл Байрак, Брек, Нариман, Шура и др. Шигаб Ахмеров взял шефство над переселением деревни, получившем в дальнейшем название Кызыл Байрак. По его ходатайству и при поддержке Общества взаимного кредита каждому переселенцу были выделены средства на приобретение коровы и лошади. На эти же благотворительные средства для будущей земельной коммуны были приобретены плуги, трактор, построена школа, приглашен учитель Сунгат Биктимеров. На живописном высоком берегу Волги, под вековыми соснами, поднялись первые срубы и возникла деревня Кызыл Байрак.

В последующие годы эти добрые дела были расценены иначе. Все, кто участвовал в них, в том числе и Шигаб Ахмеров, были арестованы. Многие не вернулись.

В 1912 г. Шигаб Ахмеров делает предложение Амине Сайдашевой – родной сестре Салиха. Свадьба их примечательна тем, что в качестве друга жениха приехал в дом Габдулла Тукай. К этому времени Шигаб Ахмеров уже был хорошо известен в общественных кругах как автор монографии «Матбугатчылык тарихы» («История книгопечатания», 1909), букварей, статей в журналах и газетах. В 1907 году в качестве журналиста (корреспондента газеты «Дума» – еженедельного органа группы депутатов, назвавших себя Мусульманской трудовой партией) он присутствовал на заседании Второй Государственной думы в Петербурге.

Прошедший большую школу жизни, начиная с освоения социального уклада крестьянского хозяйства, познав на практике условия жизни и работы учителя на селе, Шигаб Ахмеров имел большой опыт работы в области татарской культуры, развитию которой он посвятил свою жизнь.

Время его женитьбы совпало с периодом организации журнала «Мәктәб», направленного на развитие образования татарского населения. Как видно из оглавлений и названий статей, журнал рассматривал вопросы не только учебного, но и более широкого плана, например, о мероприятиях правительства по отношению к просвещению среди мусульман, о национальном воспитании, о школьных системах древнего и нового мира, приводились литературные обозрения, мусульманская и немусульманская библиография и.т.д. Знание истории магометянства и других религий, свободное владение арабским языком, толкование изречений Корана – все это сохранилось у него в активной памяти до конца жизни. Он цитировал изречение Корана, тут же переводил их на татарский язык, и они всегда были к месту и времени.

Жизнь маленького Салиха вступает в новую полосу. Он уже живёт в совершенно другой микросоциальной среде, в корне отличающейся от прежней. Первым человеком, который поймет и разгадает дар Салиха, наблюдая за его увлечениями музыкой и направит по предначертанному ему пути, станет Шигаб Ахмеров.

Вот как он напишет о первых днях общения с Салихом в своих воспоминаниям о нем: «Видя большую одаренность, мы освободили его от мелких хозяйственных дел, которые обычно возлагаются на детей, и по

возможности создали дома условия для занятия музыкой. Тогда же я попросил моего знакомого Хаджи Мохаммат ага Ахтямова достать не очень дорогой инструмент – пианино или рояль… Появление инструмента, как рояль, очень обрадовало, взволновало и вдохновило Салиха. Чтобы основательно познакомить его с музыкой и обучить его нотной грамоте, я пригласил к нам домой известного в то время пианиста, автора «Марша Тукая», Загидуллу ага Яруллина…. Очень тонкий музыкант, Загидулла ага быстро распознал талант Салиха. Они подружились, и с этого дня Салих регулярно стал брать уроки музыки. Человеком, впервые открывшим для Салиха путь профессионального музыканта, был, безусловно, Загидулла ага Яруллин».

Дом часто посещали передовые представители той эпохи: писатели, поэты, актеры. В воспоминаниях Ш.Ахмерова читаем: «Знаменитый поэт Тукай часто бывал у меня дома. Салих с ним уже близко знаком, с уважением и радостью его встречает, Тукай тоже явно ему симпатизирует и любит слушать, как он играет. Случалось, что Тукай заходил к нам даже без всякого дела, только для того, чтобы послушать игру Салиха, причем в этих случаях он просиживал долго!»

Спустя много лет, уже после смерти Салиха, анализируя жизненный путь двух корифеев нашей культуры – Тукая и Сайдашева, – Ахмеров напишет ряд статей. В одной из них он проводит параллель между их жизнью, характерами, привычками и судьбами этих выдающихся людей эпохи. Прозорливый ум Ш.Ахмерова, конечно же, знал и видел значимость всего того, что сделал Сайдашев для своего народа. Для Ахмерова, человека аналитического ума – он был в ряду выдающихся сынов своего народа.

Сайдашев любил Кызыл Байрак, приезжал он сюда и один, и с друзьями – писателями. И надолго и лишь на выходные. Заядлый рыбак, он подолгу с удочкой просиживал на берегу Волги. А вечерами вместе с приезжими гостями непременно выходил на игры к молодежи на полянку в лесу. Не было тогда предела веселью, остротам. Звучала своеобразная народная речь и и конечно же, народные песни.»

Замечательную работу проделал уроженец Верхнего Услона К.Ф.Амиров, издав в 2008 г. совместно с журналистом Г.Ризвановым уникальный сборник-буклет «Сәйдәш аланында», в котором представлены летопись «Праздника искусств», история возникновения села Кызыл Байрак, мастерски сделанные фотографии видов чудной природы.

Читая этот сборник, ощущаешь, как Кызыл Байрак становится местом путешествия в Страну Сайдашстан, как из года в год приумножает интеллектуальный потенциал Верхнеуслонского района, прославляет его. Мы обязаны не только знать прошлое, но и строить, созидать очаг нашей культуры Кызыл Байрак для будущих поколений, сохранив его историческое величие установлением памятника Шигабу Ахмерову. Можно было бы переименовать и саму деревню, назвав ее именем Шигаба Ахмерова.

Каждая культура, в том числе татарская, уникальна и имеет право на возрождение и расцвет. Татарская культура в районе, в особенности её

музыкальная культура, художественная самодеятельность находятся, к сожалению, на примитивно-бытовом уровне. «Праздник искусств» в Кызыл Байраке - знаменательное событие в районе и заслуживает того, чтобы оно проходило на фоне подъема татарской культуры Верхнеуслонского района. По нашему мнению, татарская культура в районе может получить мощный импульс развития, если ежегодный фестиваль, посвященный С.Сайдашеву, будет расширен проведением ежегодных фестивалей татарской музыки, татарской песни на районном уровне. Об этом мы говорили в коллективных Обращениях к руководству района в 2004 г., 2006 г., 2012 г., но не были услышаны.

В творчестве С.Сайдашева заложены неисчерпаемые возможности нравственного воспитания. Поэтому нам нужны ежегодные сайдашевские фестивали в школах района и в районном масштабе, чтобы открыть простор приобщению учащихся к творчеству композитора, чтобы они смогли на празднике услышать, увидеть выступления мастеров театра, оркестров под управлением прославленных дирижеров и пообщаться с выдающимися деятелями татарской культуры [2].

Существующая в районе административно-командная система с некомпетентном вмешательством в вопросы развития татарской культуры нередко проявляет себя своей разрушительной силой.

Под прессом этой силы остается нерешенной проблема обеспечения конституционного права татароязычных детей изучать музыкальную культуру (хоровое, вокальное искусство) через общение на татарском языке. Под влиянием этой силы вопреки закону осуществляется вмешательство местных властей в управление, реорганизацию местной организации Исполкома Всемирного Конгресса татар, вследствие чего мы имеем организацию, не способную решать возложенные на нее задачи, превратившуюся в «присутственное место» председателя.

Но проблема все же заключается в нас самих. Пребывая в административно-командной системе, мы приучили себя к всесилию вышестоящего, к безысходности, к имитации деятельности вместо активной деятельности, к отказу от борьбы за свои права. Поэтому мы говорим: административно-командный ресурс, основанный на некомпетентном вмешательстве, совершенно недопустим и должен уйти в небытие.

Мы должны избавиться от чиновничьей накипи и обеспечить развитие татарской музыкальной культуры в районе, впитав в себя дух времени Шигаба Ахмерова и Салиха Сайдашева.

Литература

1. Татарская энциклопедия, Казань, институт татарской энциклопедии, 2002 г.

2. Фарукшин А.Х. «Музыкальное воспитание – это, прежде всего, воспитание человека…» (Творчество С.Сайдашева и С.Садыковой в системе

нравственно – экологического воспитания) // Мәгариф, 2011г. №10. С.82.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Бүгенге телевидениедә сөйләм культурасы проблемалары

Д.Н.Батыршина, КФУ студенты
(фәнни җитәкче – профессор,
филология фәннәре докторы В.З.Гарифуллин)

Телебез – дөньяның иң бай, иң аһәңле, теләсә кемнең теләсә нинди мәгънә, хис төсмерләрен иң төгәл, нәкъ теләгәнчә белдерергә сәләтле [1, 140]. Тел дигән корал-чара ул бөтен бер системадан (аваз-хәреф, иҗек кушымча, сүз, сүзтезмә, җөмлә, синтаксик бөтен, микротекст, макротекст, текст һәм башка берәмлекләр) гыйбарәт. Сөйләм төзер өчен шул системаның һәр берәмлеге кирәкле һәм әһәмиятле. Сөйләм оештыруның төп бурычы: укучыга тиз тәэсир итү, фикерне ачык, аңлаешлы, шул ук вакытта хисле дә төшенчәләр белән тиз үткәрү.

Сөйләмнең төрлесе бар. Халык сөйләме гади һәм әдәбигә бүленсә, матбугат һәм радионыкы үзенә хас үзенчәлекләргә бай. Ә телевидение сөйләме алардан тагын да нык аерыла. Аның тәэсир көче язу белән әйтү чараларыннан гына түгел, күрү-күрсәтү чараларыннан да, шул өчесенең тыгыз, самими үрелүеннән хасил була [2, 90].

Элек Үзәк телевидение һәм Бөтенсоюз радиосында алып баручы һәм дикторларның сөйләм культурасына зур игътибар бирелгән. Сөйләмне контрольдә тотканнар, тел квалификациясен үстерү системасы эшләгән. Әйтергә кирәк, безнең чор – ул туры эфир киң җәелгән вакыт. Төрле ток-шоу, телевизион күперләр, турыдан-туры ялгану, вакыйга шаһитләре фикере – барысы да безнең өчен гади күренеш. Әмма моның белән беррәттән туры эфирда сөйләм хаталары да күбәя. Бүгенге көндә халык матбугат һәм радиога караганда телевидениегә күбрәк мөккиббән китә. Чөнки бу төр гаммәви мәгълүмат чарасы барыннан да оперативрак, кулайрак, актуальрәк. Шуңа күрә һәр сөйләм хатасы халык игътибарын җәлеп итә.

Бу фәнни эшнең төп максаты – татар телевидениесы тапшыруларында сөйләм хаталарын тикшерү һәм анализлау, бурычлары – татар телевидениесе тапшыруларын карау, сөйләм хаталары табу; типик хаталарны тикшерү, анализлау.

Илдар Малик улы Низамов үзенең «Татар социолингвистикасы» китабында түбәндәгеләрне яза: «Кызык бер халәт: тамашачы үзе ана телен чамалы гына белсә дә, татарча тапшыруларның тел-сөйләм сыйфатына ифрат

таләпчән, чөнки ул гомер буе дөрес әйтелешле, ягымлы аһәңле, әдәби нормаларга тәңгәл сөйләмгә зарыгып, ихтыяҗ тоеп яши, шул ихтыяҗын канәгатьләндерә алмавына борчыла, үзе үрнәк алырлык дип саналган сөйләмгә ризасызлык белдерә, андыйны тәнкыйть итә, ана телебезнең тизрәк дәүләт теле дәрәҗәсенә җитлегүен тели» [2, 89]. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә ана телен ишетүгә мохтаҗлык юк. Татар теле бар тарафтан ишетелә дип әйтсәк, ялгыш булмас. Шуңа күрә халык күбесенчә телевизион тапшыруларда сөйләм хаталарына артык игътибар итми. Кызганычка каршы, алып баручылар да үз сөйләмнәренә битараф кебек. Тапшыруларның һәр чыгарылышында колак ярып керерлек хаталар бар. Шунысы кызык, үз ялгышларын алар төзәтергә дә җыенмыйлар.

Замана хәзер үзгә, халык грамоталы, барысын да аңлый. Шуңа күрә иң популяр гаммәви мәгълүмат чарасы – телевидениеда урынсыз кулланылган автор неологизмнары, нормалары бозылган сөйләм телевизор караучыларда уңай тәэсир калдырмый. Бу, әлбәттә, тапшыруларның сыйфатына да тәэсир итә. Нәтиҗәдә, халык үз фикере белән сүз иреге чикләнмәгән Интернет челтәрендә бүлешә: «Кем әзерли икән ул надан журналистларны? Нигә аларны туган нигезләрендә үк өйрәтә башламаска?! Кем гаебе белән надан соң алар?»; «Гомумән «Яңа гасыр» каналы – полный застой. «Новости», «Хәбәрләр» – куян шулпасының шулпасы... Башка тапшырулар да ташка үлчим. Монда сәбәбе нидә икәнлеге аңлашыла – җитәкчелекнең һөнәри осталыгы шуның кадәр генә. Ижат дигән нәрсә бөтенләй юк» һ.б.[1] (1, 141).

ТНВ каналында барган тапшыруларны күзәттем. Сөйләм хатасы аларның барлык төрләрендә дә очрый: информацион («Хәбәрләр»), яшьләр өчен («Яшьләр тукталышы», «Яшьләр онлайн»), күңел ачу («Җырлыйк әле», «Башваткыч), интеллектуаль («Тамчы-шоу») һ.б. Җәмгыятькә экраннар аша хәбәр җиткерүче, актуаль проблемаларны анализлаучы журналистлар чиста һәм дөрес сөйләмгә ия булырга тиеш. Алып баручыларның сөйләменә карап, халык үз телен камилләштерә.

ТНВда еш очраучы тел-сөйләм хаталарын түбәндәге таблицага урнаштырдым һәм аларга аңлатма бирдем. Алдан кисәтеп кую зарур: барлык мисаллар да телевидениеда журналист һәм дикторлар сөйләменнән алынды.

Хата төре	**Хаталы мисал**	**Аңлатма**
Татарчадан русчага калька тәрҗемә итү	- «Татарстан моңарчы күренмәгән сайлауларга әзерләнә» («Хәбәрләр», 12.02.2014) – фигыль юнәлешләре бутау хатасыннан тыш (күреЛмәгән);	Татар телендә сүзләргә -лар/-ләр күплек кушымчасы өстәү гадәте күзәтелә. Таблицада китерелгән мисалларда рус теленнән калька тәрҗемә итү сәбәпле, *сайлау* һәм

[1] Остазларым. Шәкертләрем (журфакка – 50 яшь) / И.М. Низамов. – Казан: Казан ун-ты, 2012. – 152 б.

	- «Яңа ел каникулларыннан (новогодние каникулы) соң халык ябыгу юлын эзли» («Хәбәрләр», 10.01.2014). **Дөресе**: «Татарстан моңарчы күрелмәгән сайлауга әзерләнә», «Яңа ел каникулыннан соң халык ябыгу юлын эзли».	*каникул* сүләренә күплек кушымчасы ялганган: *выборы – сайлаулар, каникулы - каникуллар*. Моның дөрес түгеллеген Илдар Малик улы Низамов та искәртә (3, 86).
Сузык авазга беткән сүзләр әйткәндә авыз йому сүзнең ахырына «м» авазы өсти	– «Җил талгын. Яшен вакытында көчәя[м]» («Һава торышы»ның һәр чыгарылышында) – «Монда барысы да сездән тора[м]» («Музыкаль дистә» хит-парады рекламасында). **Дөресе**: «Җил талгын. Яшен вакытында көчәя», «Монда барысы да сездән тора»	Сузык авазга беткән сүзләр әйткәндә авыз йому сүзнең ахырына «м» авазы өсти. Бу – сөйләм нормаларына туры килми. Шуңа күрә авызны ярым ачык калдырырга кирәк.
Кушымчаларны урынсыз куллану	– «Бәрмә уен коралларында нәкъ безнеңчә моңлы ит**ТЕР**еп уйнаучы Николай Кирилов» («Җырлыйк әле») – «моңлы итеп»; – «Белгәнегезчә, биючеләр сәламәт яшәү рәвеше**Н** алып бара» («Хәбәрләр», 27.09.2013) – «сәламәт яшәү рәвеше». – «Яшьләр**НЕҢ** тормышында нинди үзгәр**ТЫ**ләр булуын без бары тик яшьләрдән генә сорый алабыз» («Яшьләр онлайн», 2.02.2014) – үзгәрүләр. – «Наркоманнар һәм көнкүреш җинаятьләр**ЕН** кылган кешеләр юк» («Хәбәрләр», 11.02.2014). **Дөресе**: моңлы итеп; сәламәт яшәү рәвеше; яшьләр, үзгәрүләр; җинаятьләр.	Ялганмалык законы телнең асыл кануны булганга, чын татарның колагына кушымчаның артыклыгы гына түгел, «китеклеге» дә ят ишетелә (3, 86).

Артык гадиләшү, гади сөйләм стиле куллану	Журналист әйткән җөмлә («итәге-ние белән», «сәпит» сүләреннән кала) якынча бирелә: – «Шундый куртканы миңа абыем, ул заманча әйтсәк, «по блату» итәге-ние белән алып кайтып бирде»; – «сәпит». («Музей социолистического быта» – «Социалистик көнкүреш әйберләр музее»ннан репортаж). **Дөресе**: итәге белән бергә алып кайтып бирде, велосипед.	Телевидениедә артык гади сөйләм сүләре куллану уңай күренеш түгел. Сөйләме үрнәк булырга һәм аудиторияне дөрес тел нормаларына өйрәтергә тиеш.
Интонацион паузаны дөрес урында куймау (орфоэпик хата)	«Туфан Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» әсәрен сәхнәдә быел урысча сәхнәләштерергә булганнар. Артистлар (пауза) үз образларын бик (пауза) җанлы һәм шаян гәүдәләндерә. Шуңа да (пауза) спектакльнең (пауза) нинди телдә баруы (пауза) мөһим түгел, диләр» («Хәбәрләр», 2014 ел).	Текст укыганда интонацион паузаны дөрес куймау җөмлә чикләрен бутый. Әлеге мисалда пауза беренче җөмлә ахырында ясалмый, ә икенчесенең иясеннән соң куела. Шуңа күрә әйтергә теләгән фикер тыңлаучыга аңлашылмый.
Басымны дөрес урында куймау (орфоэпик хата)	– «Ә бу – гадәти булмаган тапшыру. Һәрберсе шул кадәр җитди карап, вакытында килеп җиттЕләр» («Яшьләр онлайн», 1.12.2013). – «Булатны беренче курста ук алмаган булсАлар, ул әле керер идеме икән» («Яшьләр онлайн», 2.02.2014). **Дөресе**: җиттелӘр, булсалАр.	Сүздә басымны дөрес урында куймау орфоэпик хата ясауга китерә.
Сүзләрне урынсыз куллану	– «*Бәрмә уен коралларында* нәкъ *безнеңчә моңлы* итеп уйнаучы Николай Кириллов» (Җырлыйк әле,	Сүзләрне урынсыз куллану җөмләнең мәгънәсен бозуга китерә. Әлеге мисалларны анализлап үтсәк:

	01.02.2014). – «Чөнки аның *бөек максаты* бар» («Яшьләр тукталышы», 9.02.2014). – «*Татар көенең* бөтен *нечкәлекләрен әйтеп бирүче* скрипкачы кызыбыз Динә Закирова» (Җырлыйк әле). – «Хәзер минем дә *искитмәле мөмкинлегем* бар чаңгыда шуарга» («Яшьләр тукталышы», 9.02.2014). – «Хәерле *тәүлек вакытлары* барчагызга да» («Яшьләр онлайн», 2.02.2014). – «Башта бюджетка салынган зыян *10 миллиард сум дип аталса*, хәзер 29 миллион тирәсе дигән нәтиҗәгә килгәннәр» («Хәбәрләр», 11.02.2014). **Дөресе**: Бәрмә уен коралларында уйнаучы; максаты бар; нечкәлекләрен җиткереп; мөмкинлек туды; Хәерле көн барчагызга да; дип фаразланса.	«бәрмә уен кораллары» һәм «моңлы итеп уйнау» сүзтезмәләрен бергә кулланылышы мәгънәле яңгырамый. Чөнки бәрмә уен коралында моңлы итеп уйнап булмый, ул моң яңгыратмый; «көйнең нечкәлекләрен ӘЙТЕП бирү» дә урынсыз кулланылган; Бәлки, «тәүлек вакытлары» дигән сүзтезмә оригинальлек кертү максатында әйтелгәндер. Биредә «фаразланса» дип әйтү уңышлырак. Чөнки акча турында «*зыян <..> сум дип аталса*» кулланылышы дөрес түгел.
Аваз белән хәреф туры килмәү	– «Конкурс ике [и]тапта үтә. Беренче [и]тапта һәр район телевизор караучыларга талантларын тәкъдим итә» («Җырлыйк әле», 07.09.2013); – «Әссәләмәгаләйкем, хөрмәтле т[и]л[и]ви[зр] караучылар» («Җырлыйк әле», 01.02.2014); – «Миңа калса, безгә я п[и]нсия яшенә җитмәскә кирәк» («Кара-каршы», 01.02.2014). – «Буш вакытыгыз бармы? Яисә сезнең яшәү	Телевидениедә эфирга чыгучы журналистның сөйләме камил булырга тиеш. Шуңа күрә мондый әйтелеш дәрәҗәле яңгырамый.

	с[и]ссиядән, с[и]ссиягә кадәр генәме?» («Башваткыч», 8.02.2014). «Тагын бер фән [э]стәлергә мөмкин» («Хәбәрләр», 14.02.2014).	
Кабатлаулар	– «Бәлки Лилия дә сөйләп китер, тормышта *чикле* булуын. Һәм *чиксез* мөмкинлекләрнең барлыгын. Чөнки барлык кеше өчен дә мөмкинлекләр *чиксез*» («Яшьләр онлайн», 1.12.2013). – «Хәзер минем дә искитмәле мөмкинлегем бар *чаңгыда* шуарга. Мин сораган идем, миңа кечкенә, яхшы шуа торган *чаңгы* бирегез дип. Алар миңа менә шушындый *чаңгы* тоттырдылар. Бу инде чын мәгънәсендә профессионаллар шуа торган *чаңгылар*. Могҗизалы дип әйттеләр, тылсымлы дип әйттеләр. Ләкин мин җөрәт итмәячәкмен мондый *чаңгыларда* шуарга. Ә мин менә шундый *чаңгылар* алырмын» («Яшьләр тукталышы», 9.02.2014).	Туры эфирда яки оперативлык таләп ителгәндә сөйләмдә кабатлаулар
Мантыкый хата	«Яңа торак дип *алданган* Чаллы халкын *төп башына утыртканнар*» бер үк мәгънәгә ия сүзләр («Хәбәрләр», 10.02.2014). **Дөресе**: «Яңа торак дип өметләнгән Чаллы халкын алдаганнар».	*Алданган* һәм *төп башына утыртканнар* икесе дә бер мәгънә белдерәләр. Аларны җөмләдә бергә куллану – мантыйкый хата билгесе.
Фразеологизмны урынсыз куллану	«Яңа торак дип алданган Чаллы халкын төп башына утыртканнар» («Хәбәрләр»,	Фразеологизмнар стиль ягыннан стильара әдәби, сөйләм һәм гади сөйләм

	10.02.2014). Шулар рәтендә: «колак каккан» (28.01.2014), «кесәсенә суга» (29.01.2014) h.б. **Дөресе**: «Яңа торак дип өметләнгән Чаллы халкын алдаганнар».	төрләренә бүленә. Һәр төр фразеологизмнарны урынсыз куллану төрле сөйләм хаталары ясауга китерә. Мәсьәлән, артык тәэсирле һәм гади сөйләм стиленә кергән фразеологизмнарны җитди, информацион тапшыруларда куллану сөйләмгә пародия төсмере бирә. Калган төр телевизион тапшыруларда төрле стиль фразеологизмнарын куллану, берсүзсез, алып баручыларның сөйләмен баета.
Сөйләмә стиль сүзен урынсыз куллану	– «Шигъри юлларыгыз өчен сезгә *зур итеп рәхмәт*» («Башваткыч», 8.02.2014); – «Һава температурасының 30 градустан да *түбән төшүе* көтелә» («Хәбәрләр», 29.01.2014)	*Итеп* сүзе артык. *Түбән төшүе* – плеоназм (бер үк мәгънәдәге сүзләрне куллану)
Сүз белән сөйләм берәмлеге тәңгәл килү	– «Чынлыкта да шулай *булды микән* соң?» («Тамчы-шоу», 3.02.2014); – «Булатны беренче курста ук алмаган булсалар, ул әле керер *иде микән*?» («Яшьләр онлайн», 2.02.2014). **Дөресе**: «булдымы икән», «керер идеме икән».	Телдә «микән» дип сөйләшү гадәти күренеш, диләр. Әмма басма матбугаттагы кебек ни өчен сөйләмдә дә бу сүзләрне дөрес аермаска? Татар телендә кабул ителгән кагыйдәләрне «моңа күнегелгән инде» дип кенә бозарга ярамый. Ә дөрес сөйләүче журналистны мин таптым. «Хәбәрләр»не алып баручы Фәнис Камал нәкъ менә «...ме икән» дип әйтә.

Уйлавымча, күп кенә хаталар журналистларның халыкка артык якын килү максаты аркасында ясалалар. Нәтиҗәдә, халык мәнфәгатьләрен кайгыртабыз дип, әдәби нормага кермәгән, ялгыш сүзләр, тел чаралары кулланыла. Шулай ук оригинальлеккә омтылу телдә бөтенләй ят, сәер сүзтезмәләр барлыкка китерә. Югыйсә телевидение, киресенчә, үрнәк сөйләм күрсәтергә тиеш.

«Журналистлар барлык кешегә аңлашылырлык итеп, мөмкин кадәр гади тел, кулланылыштагы сүзләр белән язарга тырыша. Кайчагында хәтта рус сүзен файдалану да зыянга түгел, бу бары тик укучыга аңлаешлырак булсын өчен генә эшләнә [1, 137].

Сөйләм хаталарын киметү өчен, минем фикеремчә, түбәндәгеләрне эшләү зарур:

- телевидение тапшыруларын алып баручылар, журналистлар өчен сөйләм нормаларын өйрәтү буенча махсус курслар оештырырга;
- алып баручыларга төгәл сценарий төзергә;
- телевидениедә эшләүче журналистларның сюжетларын тел белгечләренә тикшертергә.

Аңлашыла, бер хата да ясамыйча сөйләшү авыр. Бигрәк тә туры эфирда эшләгән яки оперативлык таләп ителгән очракта, журналистка фикер барлау һәм барлык тел нормаларын истә тоту җиңел түгел. Ләкин сүләрнең кулланылышын һәм сөйләм кагыйдәләрен игътибарда тотарга тырышырга кирәк. И.М.Низамовның «Татар социолингвистикасы хәрәкәттә» китабында «тел җаваплылыгы» дигән төшенчә кертелүе юктан гына түгелдер.

Телевидение каналы аша без татар телен үстерәбез. Нормалары бозылган сөйләм кулланып, милләтебезнең дәрәҗәсе төшмәсен. Шуңа күрә әйткән һәр сүзебезне уйлап, барлык кагыйдәләргә туры китереп яңгыратыйк.

Әдәбият

1. Низамов И.М. Остазларым. Шәкертләрем (журфакка – 50 яшь). Казан: Казан ун-ты, 2012. 152 б.

2. Низамов И.М. Татар социолингвистикасы. Казан: Казан ун-ты, 2006. 150 б.

3. Низамов И.М. Татар социолингвистикасы хәрәкәттә. Казан: Казан ун-ты, 2011. 2 китап. 301 б.

Аналитик жанрларның сөйләм үзенчәлекләре («Сөембикә» журналы мисалында)

А.А.Гөсәйнова, КФУ укытучысы

Иң мөһим вакыйгаларны үз вакытында яктыртып бару – журналистика алдына куелган төп таләпләрнең берсе. Хәбәри жанрлар нәкъ менә шушы максатка хезмәт итә. Ләкин күп кенә очракларда газет-журналда укучыны яңалыклар гына канәгатьләндерми. Факт һәм вакыйгаларның асылына төшенергә, тормышыбыздагы кайбер күренешләрнең сәбәпләрен ачыкларга, күп кенә проблемаларны чишәргә туры килә. Әлегә максатларда журналист тарафыннан аналитик жанрлар кулланыла.

Аналитик жанрлар төркеменә керүче төп жанрлар: рецензия, күзәтү, мөхбирнамә (корреспонденция), мәкалә, журналист тикшерүе, анализга корылган хатлар (мәсәлән, ачык хат).

Рецензия - укучыга сәнгать, әдәбият, рухи культураның барлык өлкәләренә караган яңа әсәрләр турында мәгълүмат җиткерә. Рецензия - латинчадан «бәя» дип тәрҗемә ителә.

Рецензиянең предметы – *икенчел.* Игътибар үзәгендә фактлар түгел, ә аларның әсәрдәге чагылышы.

«Бу әсәр игътибарга лаек», «Бу әсәр игътибарга лаек түгел» фикерләрен уятуга хезмәт итә. Бу әсәрдән мисал итеп цитата, деталь, фактлар китерү белән раслана.

1911 елда Г.Ибраһимовның «Вакыт» газетасындагы «Яңа әсәр» дигән рецензиясе Ф.Кәриминең тарих дәреслегенә багышлана. 1911 елда Г.Тукай «Идел» газетасында «Яңа әсәрләр» рецензиясе М.Гафуриның «Хәмитнең хәяте» әсәренә язылган.

Даими рубрикалар хәзерге матбугатта да бар. «Казан утлары», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан»ның «Илһамият» бүлегендә.

Төрләре:

– тема буенча (әдәби, театраль, кино);

– күләменә карап (олы рецензия, ягъни грандрецензия; күләмле әсәрләргә языла; кече рецензия, ягъни минирецензия);

– әсәр саны буенча (монорецензия - бер әсәргә, полирецензия – берничә әсәргә);

– журналист тарафыннан иҗат ителгән, белгеч тарафыннан иҗат ителгән.

«Сөембикә» журналынының төсле битләрендә «Рәссам сәхифәсе» рубрикасындагы язмалар рецензия жанрында язылган. Анда рәссамнар күргәзмәләре, картиналарын тасвирлаган, бәяләгән язмалар басыла. Рецензиянең авторлары – Сөйләм Иясе (алга таба - С.И.) төрле. Мәсәлән, «Безнең Мансур»[2] рецензиясен Роза Камалетдинова язган. Ул журналист буларак күбрәк фактларга таянган, рәссамның тормыш юлы турында кыскача мәгълүмат биргән. Шул фактлардан рәссам иҗатына бәя биргән, нәтиҗә чыгарган.

«Рәссамның музасы – хатынының портретлары, улының сурәт-рәсемнәре аеруча дулкынландыра. Улы Эрнест йокымсырап утырамы, күзләрен зур ачып дөньяны өйрәнәме, яраткан эте белән уйныймы – аңа мәхәббәт, ярату тулы күзләр карап тора: әти кеше – рәссам күзләре. «Идел аһәңнәре» картинасында гына ул моңсу сыман... «Бу бит мин үзем, минем алсу томан артында калган балачагым...» – ди Мансур. Әйе, сәнгать – күңел көзгесе, йөрәк җылысы белән өртелгән, хыялы, өмете, узганы, бүгенгесе белән кушылган сурәтләр генә кешене битараф калдырмый. Ә бу – һәр рәссамның олы хыялы... Димәк, безнең Мансур теләгенә ирешкән!»[2].

Сөйләм иясе тарих фәннәре кандидаты Булат Хәмидуллинның рецензиясе «Мәхәббәт. Талант. Осталык»[5] дип атала. Ул танылган каләм, рәссам остасы

Рушан Шәмсетдиновны якыннан белә. Шуңа күрә аның иҗатына объектив бәя бирә.

С.И. бәяләгәндә белгечкә генә хас җөмләләр куллана: *«Һәрбер портрет – төрледән-төрле хисләрнең тулы бер гаммасы. Әмма һәр очракта да доминанта, спектрдагы төп сызык бар»*[5].

Мәгънә каршылыгына нигезләнгән стилистик фигуралардан антитеза кулланыла: *«Аның портретларын карарга гына түгел, укырга да була»*[5].

Күзәтү – җәмгыятьтәге нинди дә булса эшчәнлек төренең билгеле бер вакыт кысаларында үсеш-үзгәрешен масштаблы һәм максатчан тикшерә.

Матбугат барлыкка килгән чорда ук актив кулланыла.

Төрләре:

– Эчтәлек буенча: матбугат күзәтүе, хат күзәтү, тематик күзәтү: (спорт, сәясәт, икътисад), чорга бәйле күзәтү.

– Форма буенча: информацион, аналитик.

Автор фикере төп рольне уйный.

Язу алымнары:

– күп төрле жанрларга мөрәҗәгать итә;

– гомуми сораулар кузгатыла;

– факт-система-тормыш панорамасы-анализ-комментарий.

1910 елда Ш.Камалның «Вакыт» газетында «Хатын-кызлар мәктүбләре» күзәтүе басыла.

«Сөембикә» журналында журналист Мәдинә Авзалованың «Ак һәм кара»[1] язмасын хат күзәтүе жанрына кертеп анализлыйк.

Өч ел дәвамындагы низагны күзәтүдә 155нче татар гимназиясе бинасында урнашкан Казан шәһәренең 3 нче балалар музыка мәктәбе филиалы базасында ачылган музыка мәктәбенең яңа директор урынбасары Ильмира Курмашеваның хезмәт һәм финанс дисциплинасын тупас бозуы ачыклана.

Нәтиҗәдә проблема чишелми, автор бары тик үз фикерен генә белдерә: *«Гаҗәп! Һәм кызганыч. Кызганыч, чөнки моның ише гадәттән тыш хәлләргә каршы тору чарабыз, мөмкинлегебез юк. Коллектив та, район мәгариф бүлеге дә, хәтта министрлык та берни эшли алмый. «Суд яклый», диләр алар. Ә без исә барыбыз да законга буйсына торган гражданнар. Бәлкем, безгә укытучы этикасы турында махсус закон кабул итәргә кирәктер...»*[1].

Мөхбирнамә - аналитик жанр (хәбәри жанр – репортажга да якын, чынбарлыктагы күренешләр аерым факт, вакыйга-хәлләр аша чагылдырыла).

Мөхбирнамә белән мәкаләне еш бутыйлар.

Мөхбирнамә таррак масштаблы, җәмәгатьчелек фикерен проблемага юнәлтә. Ә мәкалә киң масштаблы, проблеманы чишү юлларын эзли.

Мөхбирнамәдә фикер күбрәк конкрет фактлар белән дәлилләнә, психологик дәлилләр белән дә көчәйтелә (мәкаләдә дә шулай).

Мөхбирнамә хат формасында була ала. (Ш.Бабич «Тормыш»газетында «Троицкида»мөхбирнамәсен бастыра).

Әзерләү: индукция, дедукция; анализ, синтез методлары кулланыла, хәбәр + комментарий = мөхбирнамә, факт, фактлар системасы, дәлилләр системасы, фикерләр системасы барлана.

Төрләре: хәбәри, аналитик, проблемалы.

Роза Камалетдинованың «Өмет белән өметсезлек чигендә»[4] дип исемләнгән мөхбирнамәсендә милләт язмышы, тел мәсьәләләре турында языла. Мөхбирнамәдә дәлил буларак өч факт китерелә. Беренчесе: «*Мәгариф стандартларыннан милли-төбәк компонентын төшереп калдыру турындагы федераль законга кул куелгач, «Бу закон Россиядәге милли мәктәпләрдә туган телне һәм әдәбиятны укытуны, үз халкыңның тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүне юкка чыгаруга корылган»*. Икенче дәлил: *Әлеге законны тормышка ашыру милли мәктәпләрнең ябылуына китерәчәк...»* Өченче дәлил: *«Нәтиҗәдә, меңъеллык тарихы булган татар әдәбиятына юкка чыгу куркынычы яный»*[4].

Мәкалә жанры – «аналитик жанрның атасы».

Мәкалә – иҗтимагый әһәмияткә ия булган проблема күтәрү, проблеманы чишү юлларын күрсәтеп, дәлилле йомгак, нәтиҗәләр ясалу белән характерлана. Мәкалә бер факт белән түгел, фактлар системасы белән эшли.

Мөхбирнамә күренешнең эчке асылын күрсәтеп бирергә омтылса, мәкалә шул күренешне тормышның башка яклары белән бәйләнештә анализлый.

Текст төзелеше тармаклы, катлаулы:

1) кереш - проблема әһәмияте күрсәтелә;

2) төп өлеш - проблема нигезендәге фактлар системасына бәя бирү;

3)йомгак - синтез, гомумиләштерүләр, нәтиҗә, чишү юлларын билгеләү.

Төрләре:

<u>А.А.Тертычный бүленеше:</u>

– гомумтикшеренү мәкаләсе (үзәктә гомуми әһәмияткә ия киң тармаклы проблема),

– гамәли-аналитик (конкретлык хас, нигездә конкрет проблема),

– бәхәс-полемика мәкаләсе (бәхәсле: автор үз позициясен яклый, оппонент фикерләре кире кагыла).

<u>И.М.Низамов бүленеше:</u>

– мәкалә-күзәтү,

– мәкалә-рецензия,

– рейд мәкаләсе,

– фәнни мәкалә.

Ф.Әмирхан мәкалә остасы дигәндә, «Әл-ислах»газетында – «Тел мәсьәләсенә бер караш», шулай ук Г.Исхакыйның «Таң йолдызы» газетында «Ачлык башланды» язмасы дәлил булып тора.

Мәкаләнең теле:

– кабатлаулар еш куллану (Г. Исхакый «Ачлык башланды»);

– автор психологиясе чагыла, эмоциональлек;

– риторик сорау;

– дәлилләргә бай.

Роза Камалетдинованың «Казанның кадерле ядкәрләре»[3] мәкаләсендә тарихчылардан, галимнәрдән Казанның меңъеллыгын раслаучы мәсьәләләр турында сораштыру үткәрә, проблеманы чишү юлларын эзли.

«Тарихны кем яза? Археологлар, тарихчылар, журналист-язучылар? Дөньяны халык журналист күзләре белән күрә, вазгыятькә-сәясәткә еш кына алар фикере аша бәя бирә. Телевидение, радиотапшырулар, газета-журналлар көн туса, хәбәр арты хәбәр ташый. Татар-болгар тарихын чагылдырган чагылдырган китаплар басыла тора, язмаларга кытлык сизелми. Ләкин тарих сәхифәләрен чагылдырган язмаларда хаталар, тарихи даталарны, мәгълүматларны бутау очраклары, төрлечә (ялгыш дип укы!) фаразлаулар да юк түгел. Һәм иң аянычлысы, газета-журнал битләренә үтеп кергән ялгышлар тарих китапларына күчә. Каләм язганны балта да юнып ташлый алмый, дип хак әйтәләр ләбаса.»[3].

Тел чараларына килгәндә, парлы сүзләр (*журналист-язучылар, вазгыятькә-сәясәткә, татар-болгар, газета-журналлар),* троплар (*журналист күзләре белән күрә, көн туса),* стилистик фигураларга *(хәбәр арты хәбәр ташый) h.б.* бай.

Чыганаклар

1. Авзалова М. Ак һәм кара // Сөембикә. 2005. №7. Б. 11-13.
2. Камалетдинова Р. Безнең Мансур.// Сөембикә. 2005. №1.
3. Камалетдинова Р. Казанның кадерле ядкәрләре // Сөембикә. 2004. Б.13-15.
4. Камалетдинова Р. Өмет белән өметсезлек чигендә // Сөембикә. 2009. №6. Б. 20-23.
5. Хәмидуллин Б. Мәхәббәт. Талант. Осталык // Сөембикә. 2006. №12.

Журналда хәбәри жанр куллану үзенчәлекләре («Сөембикә» журналы мисалында)

А.А.Гөсәйнова, КФУ укытучысы

Яшәү хаҗәтләре кешедә мәгълүм бер максат, ният уята да, аңарда уй-фикер туып, шуны бүтәннәргә җиткерү ихтыяҗы барлыкка килә. Яңалыкларны халыкка җиткерүнең иң нәтиҗәле каналы – массакүләм мәгълүмат чаралары. Вакыйга, факт турындагы хәбәрне оператив рәвештә укучыга ирештерү функциясен башкаручы хәбәри жанрлар вакытлы матбугатта киң кулланыла торган иң әһәмиятле жанрлардан исәпләнә. Нинди генә матбугат органында эшләмәсен, нинди генә темага язмасын – хәбәри жанрга һәр журналист мөрәҗәгать итә.

Текст оештыру методларыннан фактологик текстлар төренә кергән хәбәри жанрларның беренче билгесе – информативлык, ягъни, язманың укучы өчен кирәкле, кызыклы яңалыкка ия булуы. Журналист информациясенең

нигезен теләсә кайсы очракта объектив чынбарлыкның бер күренеше, бер өлеше, аерым бер вакыйгасы рәвешендәге факт тәшкил итә. «Чиста» хәбәр итү функциясен үтәүче текстларда «факт» төшенчәсе «тема» төшенчәсе белән тәңгәл килә диярлек: хәбәри төрдәге журналист язмаларының темасы, кагыйдә буларак, реаль чынбарлыктагы конкрет факт белән тәңгәлләшә. Хәбәри жанрлар, кагыйдә буларак, социаль әһәмияткә ия булган яңалыкны хәбәр итә.

Икенче мөһим билге – оперативлык. Вакыйга яки факт турындагы язма газета битендә тиз арада дөнья күрмәсә, үзенең актуальлеген югалта. Журнал тибындагы «Сөембикә»гә оперативлык билгесе хас дип әйтеп булмый. Айга бер тапкыр басыла торган басма типологиясенә туры килми.

Документальлек һәм төгәллек – хәбәри жанрларның аерылгысыз билгесе. Аларда сүз конкрет урын һәм вакыт, конкрет вакыйгалар турында бара. Шуңа күрә бу жанрларда иҗат итүче аеруча төгәл һәм объектив булырга тиеш.

Хәбәр ул – модальлекнең яңа буыны – фикерләү дәрәҗәсендә оешкан уйның Сөйләм Адресатына (алга таба - С.А.) юнәлтелүе. Аны битараф модальлек дип тә атыйлар. Хәбәр итү сөйләм төрләренең иң әһәмиятлеләреннән берсе. Хәбәр ул мөнәсәбәтле төгәл фикерләүнең нәтиҗәсе. Конкрет әйбер, күренеш, вакыйга турында хәбәр иткәндә аңа анализ ясалмый, гомумиләштерелми, нәтиҗә чыгарылмый, нәрсәнең кайда, кайчан булуы-булмавы хәбәр генә ителә.

Хәбәр итү яшәешнең төрле өлкәләрендә төрле максатны күздә тотып, сөйләмнең төрле рәвешләрендә оештырыла (мәсәлән, көнкүрештә, матбугатта, радио, телевидениедә һ.б.). Кайбер фәннәрдә (мәсәлән, информатика, стилистика, журналистикада) хәбәр теориясе һәм практикасы махсус өйрәнелә дә. Журналистикада, әйтик, аерым хәбәри (информацион) жанрлар бар [2].

Документальлекнең беренче күрсәткече ул – факт. Хәбәри жанрлар фактны хәбәр итә. Шулай да «Сөембикә» журналындагы хәбәрдә нәтиҗә дә бирелә. Мәсәлән, «Идел-йортта ниләр бар?» рубрикасында бирелгән «Яңа чор башланды»[8] хәбәрендә саннар, исемнәр, терминнар, цитаталар да китерелгән.

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы 26 февральдә бу чакырылыштагы XXI сессиянең соңгы Пленар утырышын уздырды.

Бюджет-финанс мәсьәләләре даими комиссиясе рәисе Илсур Сафиуллин бер республика газетасына биргән интервьюсында болай диде: «Кызганычка каршы, күбрәк законнарны Россиянеке белән тәңгәлләштерү өстендә эшләдек».

Әйе, бу парламент тарихка, мөгаен, үзеннән алдагыларның эшенә ревизия ясаучы (һич тә үз ирке белән түгел) буларак кереп калыр. Шулай да, республика тормышына кагылышлы күп кенә законнар эшләнде. Президентыбыз Минтимер Шәймиев сессияне йомгаклаганда: «Без республика тормышында һәм Россиядәге бөтен уңай үзгәрешләрнең башында торабыз», - диде.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәмәтшин фикеренчә, узган еллар безнең өчен парламентаризм һәм хокукый культураның үсү, ныгу чоры булды.

Шулап итеп, тарихыбызда тулы бер чор тәмамланды. 14 марттагы сайлаулар яңача: партия исемлеге һәм бер мандатлы округлар буенча үтте.»[8]

Хәбәр итү хәбәрлек (предикативлык) белән турыдан-туры бәйле. Хәбәрлекне белдерүче төп чаралар болар:

– хәбәрлек кушымчасы: президентыбыз,

– кушма хәбәр: ревизия ясаучы буларак кереп калыр,

– кереш җөмлә: (һич тә үз ирке белән түгел).

Хисап – сөйләшүгә корылган вакыйга турында сөйли (съезд, конференция, җыелыш, митинг, пресс-конференция, киңәшмә, утырыш).

1. Кыска хисап.

2. Киңәйтелгән хисап – кайбер мизгелләр киңрәк яктыртыла, чыгышлардан өзекләр:

- вакыйга турында сөйләү планы,
- вакыйга эчендә сөйләү планы.

3. Стенографик хисап – вакыйга агышы тулысы белән чагылдырыла, сүзгә-сүз.

4. Тематик хисап – вакыйганың бер генә ягына игътибар ителә.

5. Проблемалы хисап – вакыйга бер проблеманы яктырту өчен сәбәп кенә (А.А.Тертычный аны аналитик, ди).

Вакыйгага алдан әзерлек:

- темага, проблемага бәйле әдәбият;
- интернет белән танышу;
- катнашучылар белән алдан очрашудан тора.

Вакыйга барышында:

- исем-фамилияне язып бару;
- чыгышның төп эчтәлеген теркәү;
- техник чаралар куллану;
- кабат тикшерү хас.

Теле – рәсми стильгә якын. Автор, үз хисләрен җиткергәндә, экспрессив төсмергә ия сүзләргә, грамматик чараларга мөрәҗәгать итә, матур әдәбият h.б. тел-стиль чаралары да кулланырга мөмкин.

«Сөембикә» журналында «Җанлы матурлык»[3] язмасы бөтен дөньяга билгеле, иң эре, данлыклы музей – Дәүләт Эрмитажының Казандагы күргәзмәсеннән кыска хисап рәвешендә бирелгән.

«Бөтен дөньяга билгеле, иң эре, данлыклы музей – Дәүләт Эрмитажы казанлыларга зур бәйрәм ясады – сәнгать сөючеләр 27 августтан 8 ноябрьгә кадәр өр-яңа күргәзмә белән танышу бәхетенә ирештеләр».[3]

Күргәзмәдә булган картиналарның үрнәкләрен фотоаппаратка төшереп алып, кайберләре журнал битендә дә күрсәтелгән. Бу сөйләмнең телдән башка чарасы – экстралингвистик чарага кертелә.

«Сөембикә»дә бу күргәзмәнең күңелләрне күтәрерлек, күзне куандырып, җанны сөендерерлек бер вакыйга булганлыгын искәртәләр.

Репортаж жанры җәмгыять тормышындагы мөһим вакыйгаларны яктырту максатыннан кулланыла.

Репортажның эчтәлеген тәшкил итүче вакыйга, кагыйдә буларак, сөйләшүгә генә корылмый, ә эш-хәрәкәткә, динамикага бай була.

Репортаждагы вакыйгага хас сыйфатлар:

– яңа гына булган яңалык сурәтләнә;

– автор үз кичерешләре аша сөйли;

– укучы аны тулысынча күзалланырлык итеп тасвирлана;

– урын һәм вакыт күрсәтелә.

1. Вакыйгалы репортаж – оператив яктыртуны таләп иткән мөһим вакыйга: детальләштереп тасвирлау, катнашучылар, автор мөнәсәбәте, сәбәпләрен ачыклау, нәтиҗәгә омтылу, фактларга анализ.

2. Тематик репортаж - вакыйгага бәйле теманы ачу, оператив булмаска мөмкин.

3. Тәнкыйди репортаж - композиция, гадәттә, эзлекле. Тайпылыш бар (мәсәлән: иң кызыклы моменттан башлау), диалог кертеп җибәрү, өстәмә вакыт планы кертү (үткәнгә күз салу), автор исеменнән хикәяләү.

Репортаж – күзәтүче жанр. Төрле жанрлар белән үрелә. Автор «вакыйгада катнашу эффекты» тудырырга омтыла (фигыльнең хәзерге заман формасы, кыска җөмләләр, ситуатив сөйләм куллану (раслый, җанландыра)).

Репортажның «һөнәр алыштыру» ысулына М.Кольцов, А.Гудимов нигез салганнар. Аларның «Рождение первенца», «Мертвая петля», «Три дня в такси» (М.Кольцов);[1] «День первый», «Инспектор ОРУД-ГАИ» (А.Гудимов)[1] язмалары моңа үрнәк булып тора.

Вакыйганың әле яңа гына узган булуы зур әһәмияткә ия. Репортажның тагын бер үзенчәлекле билгесе: Сөйләм Иясе (алга таба - С.И.) вакыйга турында үз күзләре белән, үз кичерешләре аша сөйләргә, С.А. аны тулысынча күзалларлык итеп тасвирлап бирергә омтыла. Нәтиҗәдә С.А. да С.И. белән бергә вакыйганың шаһитенә әверелүе Сөйләм Нияте (алга таба - С.Н.) булып тора. Шуңа күрә, репортаж – укучының күзләре һәм колаклары, дип тә әйтәләр.

Репортаж текстында вакыйгаларның реаль вакыт эзлеклелеге мөмкин кадәр сакланып чагылдырыла. Шуңа күрә бу жанрдагы текстлар өчен проспекция һәм ретроспекция, автор кичерешләре, тирән һәм системалы анализ хас түгел. Бу репортажның Сөйләм Шарты (алга таба - С.Ш.) булып билгеләнә.

Бу жанр күбрәк газет типологиясенә туры килсә дә, «Сөембикә» журналында репортаж жанры элементлары белән язылган язмалар да бар. Моны Филисә Хәкимованың «Алтын мөнбәр» [7] язмасында очратырга мөмкин.

Әлеге репортажда С.Н. кино сәнгатендә бөек ислам, мөселман дөньясын чагылдыру. *«Исламның иң төньяк үзәге, меңъеллык гүзәл мәркәзебез Казан узган ел ук «кинематографиянең мәккәсе» сыйфатында танылган иде. «Алтын мөнбәр» II Халыкара мөселман фильмнары фестиваленең быел янә биредә үтүенең асыл бер мәгънәсе һәм һиммәте бар. Фестиваль оештыручылар аның эчтәлеген, юнәлешен: «Диннәр татулыгы һәм сәяси тотнаклылык» шигаре*

белән билгеләделәр. «Алтын мөнбәр»не әзерләү һәм үткәрү комитеты да эшлекле һәм абруйлы иде.»[7].

С.Ш. булып фестивальне тулысынча чынбарлыктан аерылмыйча сурәтләнүе тора. *«Һәр мәхәббәтнең үзенең Ватаны... Әлеге нисбәттән фестиваль кысаларында барган ике фильмны беркадәр шәрехләп үтәсем килә»*.[7]

Сөйләмдә бай сүзлек составы кулланылган.

Терминнар: кинематографист, интернет, портал, h.б.

Тарихи сүзләр: ханнар, фәрман, риваять, h.б.

Интервью – бер яки берничә кеше белән үткәрелгән әңгәмә. Факт, вакыйга әңгәмәдәшнең фикер мөнәсәбәте аша яктыртыла.

Интервью жанры метод буларак та кулланыла.

Интервью нигезен диалогик сөйләм тәшкил итә, хәбәри жанрлар системасында зур роль уйный,чөнки ышандыру көченә һәм объективлыкка ия.

Төрләре:

– интервью - монолог – (сорау – җавап, вакыт тарлыгы, уңайсыз шартларда факт-эпизод турында кыскача хәбәр бирергә кирәк),

– интервью-диалог (кара-каршы, киң таралган, вакыйга-факт бөтен нечкәлеге белән яктыртыла),

– интервью-анкета (шәхси төсмер аз чагыла, хәбәр итү функциясе),

– интервью-түгәрәк өстәл (проблема турында фикер алышу, исбатлау, кире кагу максатларына хезмәт итә, күләмле, җаваплар бер-берсенә тоташып бара – «Ватаным Татартан» газетында күп очрый),

– үз-үзем белән интервью (Батулла «Телдә, фикердә, эштә берлек» - «Мәдәни җомга»газетында),

– интервью - портрет,

– интервью - тикшерү.

Вакыйга уңаеннан: хәбәри, тематик, проблемалы интервьюга бүленә.

Интервьюның яралгысы – Г.Камалның «Йолдыз» газетында басылган «Думаны каршылап» язмасында күзәтелә. Бу жанрга Г.Тукай да мөрәҗәгать иткән.

Интервью-анкета – 1913 елда «Аң» журналында басылган «Яңа елда ни телисез?» дигән мисалны китерергә мөмкин.

Совет чорында җитмешенче елларга кадәр интервью жанры сирәк кулланыла, сиксәненче елларда күренә башлый, туксанынчы елларда активлаша.

Арадаш төрләр: интервью-зарисовка, интервью-сораштыру (блиц-опрос), пресс-конференция интервью алымы белән иҗат ителә.

Жанр ул сөйләмнең бер төре, дидек. Димәк, интервью да сөйләмнең бер төре. Сөйләм барлыкка килсен өчен С = М + Ч формуласын карарга кирәк. Мотив Сөйләм Иясе, Сөйләм Адресаты, Сөйләм Нияте, Сөйләм Шартыннан барлыкка килә. Интервью диалогик формада баргач, аның С.И. дә ике була, ә язма сөйләмдә ул бер генә, ягъни текстның авторы, бу очракта ул – журналист. С.А. ул «Сөембикә» журналын укучылар, шулай ук аерым бер тема белән

кызыксынган аудитория дә булырга мөмкин. Интервьюда С.Н. С.А.н ышандыру көченә һәм объективлыкка, проблеманы күрсәтүгә бәйли. Әңгәмәдә С.Н. башта әйтмә булса, журналда язмача бирелә. Шулай итеп, интервьюда С.Ш. төрлечә оештырыла.

Тел үзенчәлегенә килгәндә, журналистның сорауларына һәм әңгәмәдәш үзенчәлегенә, тематикага бәйле, җанлы сөйләм төсмеренә ия булырга тиеш, рәсми эндәшүгә бай, сорау-җавап формасы кулланыла (туры, кыек, ачык, ябык, контроль, фаш итүче сорау формалары).

«Сөембикә» журналында интервью жанрында язылган язмалар «Гамьле әңгәмәләр» рубрикасында басыла. Анда Татарстанның күренекле шәхесләре, гыйбрәтле язмыш ияләре һәм башка кешеләр белән әңгәмә үткәрелгән.

Роза Камалетдинованың «Биек әле күкләрем»[5] дип исемләнгән татарның бүгенге иң күренекле, иң данлы, атаклы шәхесләренең берсе Разил Вәлиев белән интервьюсы бирелгән.

Әңгәмәдәшнең теле әдәби, шул ук вакытта рәсми дә, чөнки Разил Вәлиев әдәбияттә күптән үз урынын тапкан талантлы һәм актив язучы: танылган шагыйрь, драматург һәм проза остасы, шул ук вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе дә булып тора.

Сөйләм һәрвакыт мәгънә белдерүгә хезмәт итә. Разил Вәлиев интервью вакытында сөйләмендә төрле сурәтләү чаралары куллана.

Мәсәлән, ассоциатив сурәтләү чаралары:

Чагыштыру: *«Сигез миллион кеше яшәгән Мәскәүдә йомычка кебек бөтерелеп, айкалып йөргәндә Казан университетында бер генә ел бергә укыган Гәүһәр Абдуллинаның очравы үзе бер гаҗәп хәл бит».*

Метафора: *«Каләм тәмен тоя башлаган чак, шулкадәр хыялландым шунда барырга, әмма ләкин авылдан турыдан-туры Мәскәү кадәр Мәскәүгә чыгып китәргә батырчылым җитмәде».*

Автор метафорасы – теге яки бу язучы яки шагыйрь тарафыннан тудырылган метафора: *«Ул коеп куйган шагыйрь генә түгел, армый-талмый татарның бәйсезлеге өчен көрәшүче сәяси эшлекле дә».*

Фразеологизмнар: *«Чынлыкта, Мәскәү дөньяга күзләремне ачты».*

Мәкаль: *«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән сүз хак бит ул, белгән һөнәрне күтәреп йөрисе юк, шуңа һәммәсен үзләштерергә тырышканмындыр».*

Шулай итеп, «Биек әле күкләрем» интервьюсында тел бизәкләү чараларын оста кулланылып, С.А. на фикерне аңлаешлы, үтемле, тәэсирле итеп җиткерүгә ирешелгән.

Мисал өчен тагын бер интервью жанрында иҗат ителгән язманы күзәтик.

«Сөембикә» журналында интервью-портрет төрендәге «Гыйбрәтле сүз туар хикмәт белән...»[6] язмасында журналист Роза Камалетдинованың галим-юрист, рус язучысы һәм фикер-акыл иясе Зөфәр Фәтхетдинов белән әңгәмәсендә тормыш юлы, аның шәхес буларак үрнәк булуы сурәтләнә.

«Нәсел башы – Чистайда, бабаларыбыз шунда гомер кичергән. Әти Бохара, Анкарада муллалыкка укыган: фарсы, кытай, рус, француз телләрен яхшы белә иде. 22 яшьлек Чистай мулласы, ягъни минем булачак әтием 1917 – 1918 елларда зинданга ябыла, төрмә шулпасының ачысын татый. Әле дә ярый, алтын сәгате була, шуны сакчыга биреп кача, Кострамага килеп чыга. Анда да ачлык, торыр урын юк.»[6].

С.И. үзе язучы булгач, С.Ш. да гыйбрәтле сүзләр, афоризмнар белән үтәлә. С.Н. бүгенге вазгыятьне С.Ш. нигезендә укучыга үтемле җиткерү тора.

«Хокуклар саклана торган дәүләттә түрәләр, ягъни чиновниклар түгел, ә бәлки хокук чыгара торган хакимият баш була. Хәтта президент та кануннарга буйсына, шуларны сакларга мәҗбүр. Ә бездә кыргый ил кануннары: чынлыкта, хакимият башкарма, хокук чыгару һәм хөкем итү органнарына бүленми. Зур урында утыра торган түрә – үзе патша, үзе Алла һәм хөкемдар.»[6].

«Сөембикә» журналындагы «Ана телен кем саклый?»[4] язмасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты галимәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, тел язмышы белән бәйле зыялылар, әдипләр «Сөембикә» журналы редакциясендә, «түгәрәк өстәл» янында тел, милләт язмышы турында сөйләшәләр. Анда түбәндәге сораулар яңгырый:

– *«Безнең телнең киләчәге нинди?»*

– *«БДИны русча тапшырасы булгач, туган телем нигә кирәк дип яһүдләр фәлсәфә куертып маташмый, борынгы еврей теле ивритны да, кайсы илдә яшәсә, шул ил халкы телен дә биш бармагыдай белә. Алар бер-берсен ничек кенә күтәрәләр әле! Ә без соң бәләкәй халыкмы?»*

– *«Туган тел байлыгы фольклорда сакланган.»*

– *«Тел язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшкәндә, телебез җәүһәрләрен туплаган иң зур хәзинә - сүзлекләр хакында берничә фикер әйтми булмас.»*

– *«Тел турында сөйләшү милләт язмышы турында сөйләшү ул.»*

– *«Нигә ул дәүләт теле түгел?»*

– *«Татар тел белеме – үсештәге фән.»*[4] h.б.

Бу очракта, С.И. төрле була. С.А. итеп тел, милләт мәсьәләләре белән кызыксынучылар билгеләнә. С.Н. булып ата-бабалардан күчкән кыйммәтле мирас – рухи байлыкларны киләчәк буыннарга тапшыру бурычы, телне саклап калу максаты тора. Түгәрәк өстәл янындагы әңгәмә вакытында С.И.ләренең С.Ш. башкача булса, журналда бирелгәндә С.И.нең, ягъни журналист шәхесенең эчке кичерешләренә, психологиясенә бәйле рәвештә язмача бирелә.

Телдән башка чараларга экстралингвистик һәм паралингвистик чаралар керә. Экстралинвистик чаралар булып тавыш, пауза, интонация h.б. торса, паралингвистик чараларга ым, ишарә, хәрәкәт керә. Әйтмә сөйләмдә сызык («-»), сорау, өндәү(«?», «!») билгеләре укылмый, ә пауза, интонация белән бирелә. Мәсәлән, әлеге язманы алыйк.

Пауза: *«Иле барның – теле бар. Дәүләтебез булмаса да, станыбыз – Татарстан бар», «Бүтән бер милләттә дә шулай зурлап – Ана теле дип йөртелми ул»* h.б.

Интонация: *«1990 елның 30 августында Декларация кабул иткәндә иң зур бәхәсләр тел тирәсендә барды. 1992 елны Татарстанда «Телләр турында»гы закон кабул иткәндә дә безнең тәкъдимнәрнең барысын да тормышка ашырып булмады. Дәүләт хезмәткәрләре дәүләт телен белергә тиеш. Киресенчә булса – мантыйкка сыймый.*

Әз генә читкә китеп бер мисал китерәм: бервакыт Мөхәммәт Сабиров сессиягә шул чакта модалы фуражка киеп килде...» Монда бер интонациянең, әкрен генә үсеп-үзгәреп, икенче интонациягә әверелүе күзәтелә. Җөмләләрдә капма-каршы сүзләр (барды, булмады), сызык («–»), абзац интонациянең үзгәрүенә китерә.

Риторик сорау җөмлә: *«Гаиләдә, бакчада, башлангыч мәктәптә өйрәнеп, аны саклап калу, үстерү мөмкин эшме? Безнең телнең киләчәге нинди?»*

Язмада паралингвиситик чараларны әңгәмә барышында фотоаппаратка төшерелгән фотосурәттә күрергә мөмкин.

Аңлашылганча, иң мөһим вакыйгаларны үз вакытында яктыртып бару – журналистика алдына куелган төп таләпләрнең берсе. Хәбәри жанрларның нәкъ менә шушы максатка хезмәт итүен күрдек.

Әдәбият

1. Информационные жанры газетной публицистики: Хрестоматия. Под ред. В.Д.Пельта. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1986. С.178-187.

2. Низамов И.М. Уем тел очында. Казан:Татар.кит. нәшр., 1995. 121 б.

Чыганаклар

1. Җанлы матурлык // Сөембикә. 2004. №11. 48 б.

2. Камалетдинова Р. «Ана телен кем саклый?»// Сөембикә, №3. 2010. 22-26 б.

3. Камалетдинова Р. Биек әле күкләрем // Сөембикә. №2. 2007. 26-29 б.

4. Камалетдинова Р. Гыйбрәтле сүз туар хикмәт белән...// Сөембикә. 2005. 20-23 б.

5. Хәкимова Ф. Алтын мөнбәр // Сөембикә. №1. 2007. 30-31 б.

6. Яңа чор башланды // Сөембикә, №3, 2004. 40 б.

Көндәлек матбугатта еш очрый торган хаталар

Л.Ш.Исхакова,
Казан шәһәре 177 нче урта мәктәбенең
милли эшләр буенча директор урынбасары,
югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
Л.Н.Воробьева,

Казан шәһәре 177 нче урта мәктәбенең
беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Вакытлы матбугат җәмгыятьтәге бөтен үзгәрешләрне, яңалыкларны чагылдырып бара. Билгеле, җәмгыятьтә барган үзгәрешләр, яңа төшенчәләр барлыкка килү һәрваккытта да телдә яңа сүз тууга китерми. Еш кына бу процесс озак бара: алдан нинди дә булса сүз барлыкка килә, аннары гына журналларда һәм газеталарда кулланыла башлый. Шулай вакытлы матбугатта сынау үткәч кенә, сүз академик сүзлекләргә күчә. Шуңа күрә вакытлы матбугат телен өйрәнү, аны классификацияләү – тел белгечләре алдында тора торган мөһим бурычларның берсе.

Икенчедән, вакытлы матбугатта тел проблемаларын, бигрәк тә анда киткән стилистик хаталарны тикшерү җәмгыять өчен бик тә зарур. Чөнки тел проблемалары – ул халык проблемалары, ә бүгенге көн – татар милләте өчен әһәмиятле замана, үзгәрешләр, реформалар заманасы.

Өченчедән, хәзерге татар телендә зур үзгәрешләр бара. Кайбер проблемалар (әйтик, яңа латин алфавитына күчәргә омтылу, орфография мәсьәләләре) журнал һәм газета битләрендә киң җәмәгатьчелек тарафыннан каралырга тиеш.

Мәкаләбездә телдәге стилистик хаталарны анализлау өчен «Ватаным Татарстан» газетасын һәм «Идел» журналын алдык. Ләкин бу теманы киңрәк тә яктыртырга мөмкин. Чөнки матбугаттагы стилистик хаталар мәсьәләләре кызыклы темаларның берсе һәм бу беребезне дә битараф калдырырга тиеш түгел.

Тел кануннары матбугатта барлыкка килә. Шуңа күрә вакытлы матбугатта телдәге хаталарга багышланган материаллар да, аны бетерү юлларын укучылар белән бергәләп эзләү дә игътибарга лаек. Бу мәкаләбез, әлбәттә, зур проблемаларны хәл итә алмый. Ләкин теманың актуальлеген ачыкларга ярдәм итә.

Хәзерге заманны матбугаттан башка күз алдына да китереп булмый. Мәгълүмат мәйданы искиткеч зур. Елның-елында әлеге мәйданда берсеннән-берсе яңа газеталар һәм журналлар пәйда булып тора. Кызганыч, әлеге матбугат чаралары арту белән, аның сыйфаты түбәнәю дә күзәтелә. Ә бит матбугат чаралары безнең яшәешебезнең көзгесе, тормышыбыз чагылышы. Сыйфатның аксавы иң беренчедән басмаларның теле начараюда күренә. Бу бигрәк тә коммерция-ведомство басмаларына кагыла. Мондый җитешсезлекләр гомум матбугатның дәрәҗәсен төшерә, дип исәплибез.

Мәсәлән, газета-журналларда төпле, кешене уйландырырлык материаллар кимеде. Жанрлар буталуы да борчылу тудыра. Соңгы елларда матбугатка хас очерк, фельетон жанрлары югалып бара.

Бүгенге көндә вакытлы матбугатта телнең бозык булуы, аларда стилистик хаталарның бик күп булуы борчылу тудыра. Газета, журнал битләрендә кайчандыр ялгыш тәрҗемә ителеп яки төгәл тәрҗемә ителмәгән сүзләр еллар буена язылып килә.

Газета һәм журналлардагы язма тел шундый иркен куелган. Нәтиҗәдә, автор үзе генә белгән, үзе уйлап чыгарылган сүзләр туа. Мәсәлән: «тәкыя» (такыя), «мәшәкәт» (мәшәкать), «хәкимият» (хакимият), «сүде» (сода), «хәттә» (хәтта), «гәйбәт» (гайбәт), «тавар» (товар), «нәзәкәт» (нәзакәт), «мөгәен» (мөгаен), «бөкере» (бөкре), «коерык» (койрык), «ахырсүз» (ахыр сүз), «йодырык» (йодрык), «үтәкүренмәле» (үтә күренмәле), «егетчак» (егет чак), «тәккәбер» (тәкәббер), «аппарганда» (алып барганда), «әлләкем» (әллә кем), «пакьлык» (пакълек) һ.б. бик күп « яңа» сүзләр барлыкка килде.

Эш аерым сүзләрнең ялгыш язылуларында гына булса да бер хәл иде, хәзер инде җөмлә төзелешенә дә игътибар кимегән кебек. Менә берничә генә мисал.

«Бөек Ватан сугышы өчен барган сугышта тылдагы халык җиңеп чыгу өчен үзе ач калса да, һич нәрсәне кызганмады». Бу җөмлә мәгънәсе белән туры килми кебек: Бөек Ватан сугышы өчен сугыш бармый бит инде. (Барса, Бөек Ватан өчен барырга мөмкин ул сугыш.)

«Алар хуҗалыгында алты мөгезле эре терлек бар». Бу җөмләдә дә автор алтыдан соң «баш» сүзен куйса, алты мөгезе булган эре терлек турындагы мәгънәсезлеккә урын калмас иде.

Бик күңелсез бу күренешнең инде газета битләреннән журналларыбызга да үтеп керүе аянычлы хәл.

Журналларыбыздагы кайбер язмаларның татар телендә түгел, ә урысчалы-татарчалы катнаш телдә язылуы һәм басылуы гаҗәпкә калдыра. Материалларны газета яки журналларга бастырырга дип әзерләгәндә игътибарлырак булсак иде.

Стилистик хаталар гадәттә рус теленнән кергән яңа алынмаларда очрый. Мәсәлән: *«Бу – вольерларда ялтыравыклы компьютер компакт-диск элеп кую»; «Шул ук брифингта республика идарәсенең салым түләүчеләрне исәпкә алу бүлеге начальнигы Ольга Агафетованың әйтүенчә, быел барлык салым түләүче, юридик затларга салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) биреләчәк».* Сәясәт өлкәсендәге неологизмнарны билгеләп китәргә була. Мисал: *«Комиссиядә ел саен уртача 180 федераль закон проекты, федерациясенең башка субъектларындагы коллегаларның 50гә якын закон тәкъдим итү инициатива-мөрәҗәгате тикшерелде».*

«Ватаным Татарстан» газетасының рус теленнән алынган калькалар белән мавыгуы – аның аеруча бер үзенчәлеге дип санарга мөмкин. Еш кына сәяси-иҗтимагый өлкәдә идиомага әверелгән сүзтезмәләрне әйтеп китәргә кирәктер: *«Беренче ел хезмәт итүче солдатларның моннан соң «кайнар нокталар»га җибәрелмәячәге өчен аналар нәкъ менә аңа рәхмәт әйтә алалар».* Рус теленнән еш кына сүзләр кушылып ясалган терминнар да кабул ителә: *«Бер айга якын сузылган тәнәфестән соң суперлига хоккей командалары чемпионатны дәвам итте».*

Аерым бер үзенчәлек итеп рус теленнән кергән алынмалар нигезендә яңа фигыльләр ясалуы да игътибарга лаеклы. Мәсәлән: *«Массакүләм мәгълүмат чаралары киләчәктә дә җәмгыятьне туплауның һәм халыклар арасындагы*

мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүнең куәтле факторы булып хезмәт итәчәгенә ышанабыз», – дип билгеләп үтелә». Башка вакытлы матбугат чараларындагы кебек үк, «Ватаным Татарстан» газетасында еш кына рус теленнән алынган яңа сүзләргә җәяләр эчендә аңлатма бирелә: *«Корылык һәм башка катаклизмнар (кискен үзгәрешләр) көтелми».*

«Бүген проба токымы алырга килделәрме?» –дип укыгач, ирексездән, бу урысча уйлап язылган җөмлә, дип куясың. Биредә бит «проба породы»ның «порода» сүзе генә тәрҗемә ителгән.

Мондый ише тәрҗемәсез сүзләр газеталарда, журналларда да очрый тора. «Особняк», «щитовой бараклар», «зарплата», «ведомость исемлеге», «отгул», «хисләр электры», «недобор», «свита», «контролировать» кебек сүзләрне тәрҗемә итеп тә биреп була югыйсә.

Бүгенге көндә матбугатта бәхәсле булып кала бирә торган сүзләр күп әле. Әйтик, повар – пешекче, предпринимательство – кәсәбәчелек, кәсепчелек. Гадәттә поварны пешекче дип тәрҗемә итәләр. Ләкин аны ашчы дип язучылар да очрый. Предприниматель сүзен кайберәүләр эшкуар, эшмәкәр дип тәрҗемә итә. Эшмәкәр – эшчән, уңган, эшлекле дигәнне аңлата. Халыкта эшмәкәрне бал басар, эшлексезне йокы басар дигән әйтем бар. Эшкуар дисәк, дөресрәк тә булыр иде кебек. Аңлатмалы сүзлектә эшкуар сүзе – эшләрне (бигрәк тә коммерция эшләрен) бернинди ысулдан да чирканмыйча, оста итеп алып баручы, дигән мәгънәдә бирелә. Предпринимательгә килгәндә, аны малтабар, малкуар, дип әйтергә тәкъдим итүчеләр дә бар.

Тел – иҗтимагый күренеш. Сүзләрнең мәгънәләре киңәя, үзгәрә, тарая. Сүзләрдә яңа мәгънә туу билгеле. Әйтик, хәзер кесә телефоны (сотовый телефон) да матбугат битләрендә төрлечә бирелә. Бездә аны берәүләр күзәнәкле телефон, икенчеләре – кәрәзле телефон дип йөртә. Урысчадан төп-төгәл тәрҗемә итим дисәң (безнеңчә – калькалаштырсаң), шулай анысы. Уйлап карыйк әле. Сотовый сүзе *соты* сүзеннән ясалган, кәрәзне аңлата. Сорау туа: бу телефонның умартачылыкка ни катнашы бар? Белгечләр болай аңлатты: балга катнашы юк, телефон номерлары тартмасында бал кәрәзендәге кебек бүлемтекләр күп булганга шулай йөртелә. Алай булса, ник без аны гади итеп – чыбыксыз телефон яки кесә телефоны дип атамыйбыз соң?

«Идел» журналы республикабызның яшьләр матбугат органының берсе буларак телне куллануда бер үрнәк булырга тиештер. Биредә кайбер очракларда хәтта публицистик материалларда гына түгел, әдәби әсәрләрдә дә стилистик хаталар китә. Бу бәлки язучы автор тарафыннан ниндидер бер яңалык, осталык кебек кабул ителәдер. Ләкин бу бу укучыга бер дә кызык түгел. Текстларда еш кына кирәксез рус сүзләрен күзәтергә мөмкин. Китерелгән мисалларда, әлбәттә, бу сүзләрне куллану берничек тә дәлилләнми. Әйтик*: «Төрле яшьтәге кешеләр берәмләп тә, төркемләп тә кызу-кызу адымнар белән савыктыргыч прогулкага ашыгалар»*.

Журналда географик атамаларда да хата табып була. Мәсәлән, Зеленодольск, Зелёный Дол татар зыялылары арасында һәрвакыт Яшел Үзән дип атала. Бу күренеш татар әдәби теленең нормасына кереп бара. Ләкин әлеге

атама журналда гына түгел, газета битендә дә нигәдер Зеленодол дип бирелә: *«Әлеге киңәшмәдә катнашучылар составы 10 гыйнварда Әлмәт, Арча, Зеленодол, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә узган территориаль җыелышларда билгеләнде».*

Бу мисалда өстәрәк әйтеп киткән кирәксез рус сүзе кулланылуы да күзәтелә. Территориаль урынына гади гына җирле сыйфатын куллану, безнең фикеребезчә, уңышлырак булыр иде.

«Ватаным Татарстан» газетасы битләрендә еш кына уңышсыз яңа сүзләр дә кулланыла. Әлбәттә, аларның уңышсызлыгын вакыт билгели, ләкин алар, кагыйдә буларак, татар теленең закончылыкларына буйсынмыйча, текстка керәләр. Әйтик, *«Ә кондитер Маргарита Аппакова алты торт һәм илледән артык вак пирожныйлар әзерләячәк».* Бу сүз татар теленең аһәңенә килешеп бетмәгәне сизелеп тора. Ләкин, икенче яктан, бу форма сүзлекләрдә дә очрый. Шулай: «пирожное, пирожный...».

Без караган мисалларда тагын бер үзенчәлекле проблема барлыкка килде. Бу – аббревиатуралар кулланышы. Мәсәлән, ИНН: *«Шул ук брифингта республика идарәсенең салым түләүчеләрне исәпкә алу бүлеге начальнигы Ольга Агафетованың әйтүенчә, быел барлык салым түләүче, юридик затларга салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) биреләчәк».* Русча ИНН – идентификационный номер налогоплательщика дип аңлатыла, ә татарча без аны СТИН – салым түләүченең идентификация номеры дип язсак, бәлки, уңышлырак булыр. Бу – татар теленең абруен күтәрер иде, дип уйлыйбыз.

Татар матбугаты тел мәсьәләләренә карата беркайчан да битараф булмады. Журнал һәм газета битләрендә тел белгечләре, галимнәр чыгышлары даими бастырыла. Ләкин, кызганычка каршы, соңгы елларда татар теленә карата мөнәсәбәт бераз салкынайды. Туган телне искә алганда, күбрәк сәяси-иҗтимагый якларны тикшерү башланды.

Телне саклау, аны куллану буенча әллә нинди кануннар, карарлар чыгару зарур түгел. Үзебезнең газиз туган телебезгә ихтирам, хөрмәт кенә кирәк. Чит илләрдән кергән, тешне сындыра торган сүзләрдән башка да матур сүзләр, чын татарча терминнар кулланырга да була бит.

Татарча фәнни-популяр стиль үзгәрештә

И.М. Низамов, КФУ профессоры,
филология фәннәре докторы

Менә бу чыгышыма карата да «Нинди темага?» дигән сорау бирүләре ихтимал. «Тел турында» диям инде. Сизәм, әңгәмәдәшем карашындагы сорау шул килеш. Нишлим соң, «тел» ул чыннан да колачлап бетерә алмаслык, бербөтен итеп күз алдына китереп булмастай төшенчә бит.

Димәк ки, өстәмә мәгълүмәт биреп, төшендеребрәк аңлату сорала. «Телне куллану мәсьәләсе», «Сөйләм төрләренең берсе», «Стилистика өлкәсе» һ.б.

дияргәдер. Сизәмсез, болары да бик үк бик тәгаен түгел, гомумиерәк – томанлырак.

Тел дөньясына караган гади генә бер категория-төшенчәне һәркем аңларлык итеп кыска гына төшендерү өчен дә фикереңә үзенә бер сөйләм рәвеше табарга мәҗбүрсең. Менә бит, бүгенге чыгышым әлләни катлаулы да түгел кебек: яшьләргә татар тел гыйлемиятендә фәнни-популяр стиль яшәвен, аны белүнең гамәли әһәмияте барлыгын белдертмәкчемен. Укучым чамалап алды булыр: шушы гади гына максатына ирешер өчен дә автор үзәккә куелган фикерен тыңлаучысына,укучысына (адресатына) белдерү, җиткерү өчен телне һәм башка корал-чараларны үзенә бер тәртип белән кулланырга тиеш була. Ә аны тыңларга алынган адресат тел гыйлеменнән моңарчы алган белемен хәтергә төшереп, **стилистика, сөйләмият, өслүб, жанр** кебек төшенчә, күренеш, хәтта фәнни системалар белән эш итәргә әзерләнә башлый.

Үгезне мөгезеннән эләктереп алганчы, бүгенге даирәгә кирәкле бер кагыйдәне искә төшереп алу зарар итмәстер: һәркайсыбызның аңында табигать, җәмгыять системалары кебек үк, чынбарлыкта, объектив яши торган тел системасы,– гомумән дә ,– аны укыту-өйрәтү эше һәм фәне дә нигезендә өч яссылыкта күзалланырга тиеш: 1) телнең төзелеше, куллану мөмкинлекләре (фонетика-фонология, морфология-морфонология, лексикология, грамматика, стилистика h.б.фәннәр өйрәнә торган өлкә), 2) телне шәхси һәм күмәк куллану закончалыклары (сөйләмият), 3) телнең халык, милләт тормышында бүгенге иҗтимагый халәте (социолингвистика).

Төрле тарихи-иҗтимагый сәбәпләр аркасында телне өйрәнү барышында аның бу юнәлешләренең нисбәтен саклап булмаган. Аерым алганда, татар социолингвистикасы махсус өйрәнүгә куелмаган. Шул ук вакытта тел куллануның сөйләмият буынындагы мәсьәләләре дә фундаменталь ачыкланган хәлендә дә, чишелеш юнәлешендә дә әлләни ерак китә алмаган. Без бүген ачыкларга алынган тема да – телне гамәли куллануда сөйләм (стиль) төрләренең роле һәм аларның бүгенге хәле заманча яңа шартларда тирәнтен өйрәнүне сорый. Заманында яңалык булып тоелган фәнни ачышлар (дөресрәге, фәнни башлангычлар) булса да аларны гамәлдә, тормышта куллану көндәлек гадәткә әйләнмәгән, алар бүген тар фәнни даирәләр, очраклы вакыт кысаларында гына куллану объекты булып кала бирә.

Ә бит безнең буын – тел куллануның биш гасырлык «тукталыш-торгынлыгыннан» соң берникадәр җанланып киткән – егерменче йөзнең соңгы елларындагы активлашуы мизгеленең шаһиты. Без – татар теле – дәүләт теле дип рәсми игълан ителеп, аның куллану даирәсе, юнәлешләренең бөреләнеп кенә түгел, сулыш алып, хәрәкәтләнеп, үсеп киткән чорында, аның сүздә генә түгел, тормышта, гамәлдә дә үзгәреш кичерә башлаган чорында яшәп калган кешеләр.

Ул чорда мәктәп программасында, дәреслекләрдә стильләрне системалы өйрәнүгә игътибар ителә иде. Фәнни-популяр стиль төренең күпчелек кулланмаларда телгә алынуы хәтердә калган. Төп асылын бик кыска гына искә төшерик. Башта үзенчәлекле бер төсмеренә диккать итик: башка стиль

төрләренең атамалары бер генә сүздән торганда, бу стиль төрчәсенең атамасы ике берәмлектән хасил: **фәнни + популяр**. Атаманың бу үзгәлеге стиль төренең хәсиятендә дә чагылыш таба: фәннилек белдергән тел берәмлекләре (атама-исем, термин-профессионализм h.б.) + халыкчанлык, гаммәвилекне белдергән берәмлекләр (телдән сөйләү, гади сөйләм элементлары, күчерелмә мәгънәле берәмлекләр, экстра,-паралингвистик чаралар h.б.). Бу төр стильнең эчке хәсияте белән бәйле тел чараларын күзалларга теләгәндә, аң (акыл) + хис бердәйлеген дә искә төшерү гамәли әһәмиятле булыр. Бу ике канат сүз, гыйбарәләре төрлечә бит, асылда алар конкретлыкны (документальлекне) белдерү чаралары, икенче канаты хис-тойгы (эмоциональлек) белдерү чаралары. Һәр ике төр лексик чара сөйләм оештыруда һәркайсы үз функцияләрен үтәп, төрлечә тәэсир итәләр, ә менә аларның бердәйлеге, ягъни сөйләмдәге синтезы үзенә бер кыйммәтле, тәэсирле гармоник чара хасил итә ала. Бу инде фәнни-популяр өслүб дигән үзгә бер сөйләмнең башкалардан аерым булган тәэсир чарасы. Бу инде милли сөйләмнең кыйммәтле казанышы була ала. Татар стилистикасында мондый кыйммәтле чара бар. Ул бүген дә хәрәкәттә. Ихтыяҗ булганда без аны бүген дә эшкә җигә алабыз. Менә шуны фәнни өйрәнү, гамәли куллану осталыгына ирешү бурычы алдыбызда тора да инде. Әйдәгез, бу тезис-кагыйдәне гамәлдә ничек үтәп буласын бүгенге мисаллар белән дәлилләп карыйк. Анализ өчен фәнни-популяр стильдә төрле темага язылган берничә текст тәкъдим итәбез. Укучыбызның үзен дә анализда катнашуын үтенәбез.

Беренче мисал җыр сәнгате темасына. Авторы – бу стиль төрен куллануда бай тәҗрибә туплаган иҗатчы Мәхмүт Нигъмәтҗанов, музыка белгече, профессор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе.

«Инде Динә Гарипованың кеше күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтә торган тавышының сере нидән гыйбарәт соң? Билгеле, мин 1нче каналдан ишеткән һәм үземдә булган башка язмалардан *чыгып* кына фикер йөртәм. Кешенең камилләшкән тавышы – иң мөһим, *югары дәрәҗәдәге музыка коралы* ул. Анда кешенең рухи халәте, эмоциональ ***байлыгы***, кичерешләр ***тирәнлеге*** һәм намусы да чагылыш таба.

Инде Динәнең профессиональ яктан тавыш сыйфатына тукталып узыйк. Аның *диапазоны ике октавадан артык*, һәм иң мөһиме – шул ***киң авазлар даласынд*а**гы һәр өлеше тигез, көчәнүсез, саф яңгырый, йә ***чишмә сыман, йә көчле дулкынлы диңгез кеби***, олы оркестрны җиңеп, иң югары яңгырашка ирешә. Һәр әсәрдә, хәтта җөмләдә дә җырчы төрле алымнардан оста файдалана. Татар эстрадасында мондый осталык, төгәллек белән олы оркестрга кушылып җырлый алган кешене хәтерли алмыйм. Монда *интонация* байлыгын, *ритм*нан оста файдалануны да искә алмый булмый.

Мин әле иң мөһимен – тавыш яңгырашы, йөрәк тембры турында әйтмәдем. Ул тавышка, яңгырашка ***сихри*** көч, ***җан*** бирә. Һәр әсәрдә җырчы тавышына яңадан-яңа төсмер өсти. *Тембрның акустик төзелеше* күптән мәгълүм, әмма аны сүз белән аңлату, чагылдыру бик читен. Һәр музыка коралының үзенең *махсус тембры* бар. Телефоннан сөйләшкәндә дә без кешене

тавыш тембрыннан таныйбыз. *Скрипканың*, мәсәлән бер кылында да ***чиксез*** төрле тембрлар тудырып була. Динәнең дә кабатланмас, үзенә генә хас бай, ***күңелләрне кузгата торган сихри*** тембры бар, кирәк санаса ул тавышына *микро-вирато* да өстәп җибәрә. Аның интонация төгәллегенә ***шаккатарлык,*** ул әйтерсең, ***снайперча*** музыканың ***иң югары «түбәсенә» менеп***, кульминация ясый да бик оста гына ишетелер-ишетелмәс *флажолетка* да күчә... Кыскача гына әйткәндә, безнең алдыбызда тыйнак, ***искиткеч*** талантлы, зур осталыкка ирешкән, ана теленең нечкә *фонетик сыйфатларын* саклап, киң музыкаль образлар ачарлык саф татар музыкант-җырчыбыз калкып чыкты...».

Үрнәк мисалда бу төр стильнең асыл үзенчәлеге, кабатлыйбыз, фәнни сөйләм берәмлекләренең (музыка профессионализмнары) һәм популяр (гади) сөйләм элементларының (***көчәнүсез, читен*** һ.б.*;* алар безнең текстта үзенчәлекле шрифт белән ассызыкланган) табигый бердәйлеге – гармонияле синтезы шактый ачык күренә.

Шул ук вакытта бу төр стильдә дә сөйләм закончалыкларының кечкенә генә бозылуы да укучы тарафыннан дикъкатьсез калмавын кисәтик. Әйтик, терминның камил булмавы (*югары дәрәҗәдәге музыка коралы)* яисә урынсыз термин куллану *(«телнең нечкә фонетик сыйфатлары»* дөрес түгелдер, җырдагы сүз авазларның әйтелеше ягъни фонологик сыйфатлары турында барырга тиештер). Янә кереш сүзнең *(билгеле)*, кальканың *(чыгып)* урынсыз кулланылуы да сөйләм агышының «популярлыгын» бозмый калмаган.

Янә бер мисал. Ул әле китерелгәнгә якын, кардәш тема – сәхнә (театр) сөйләме, шуның белән аерылгысыз бәйле матур әдәбият сөйләменең драматургия өлкәсенә караган фәнни-популяр шәкелдә язылган мәкаләдән бер өзек. Театр белгече, популяр автор, бу төр сөйләм җанрының татар сөйләмиятендә нигезен барлыкка китерүгә өлеш керткән белгечләрнең берсе Дания Гыймранова иҗаты үрнәге.

«Музыкаль рольләрне уйнау *актрисаны* (Рауза Хәйретдинованы) үзеннән-үзе лирик ***дулкынга көйли***, аларда татар хатын-кызы язмышы төрле вариантларда үзенең ачык чагылышын таба. Ул чакта Р.Хәйретдинова күбрәк *уңай героиняларны уйный*. Моңа мисал итеп М.Әблиевнең «Шәмсекамәр»ендәге Разия, Т.Гыйззәтнең «Шомлы көннәр»ендәге Гөлчирә, Ш.Шаһгалинең «Таң атканда»сындагы Гөлбикә *образларын* күрсәтергә була. Алар берникадәр *үзенчәлекле характерда* булса да кешелек сыйфатлары ягыннан *уңай образлар*. *Вокал мөмкинлекләре* киң булу өстенә, *актриса* халыкның гореф-гадәтләрен дә бөтен нечкәлекләренә кадәр бик яхшы белә. Ул иҗат иткән образларда самимилек, табигыйлек, хәтта авылча гадилек ***(гыйбатлык белән бутый күрмәгез)***, характер ***яктылыгы***, ачыклыгы ***ярылып ята***. Алар халык җырларында җырланган, урман-кырларда, болыннарда ***тәгәрәшеп үскән*** чибәр, сылу кызларны хәтердә яңарта. Ул образлар аша халкыбызның рухын тоясың. Бу җәһәттән олуг язучыбыз Әмирхан Еникинең 1956 елда К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»н кую уңае белән язылган бер *рецензиясен* мисал итеп китерәсе килә...». (М.ж., 2013, 1 март.).

Мондый текстларда популярлыкка ирешү фәнни чаралар белән эш иткәндә дә күзәтелә. Мәсәлән, бу очракта үтә фәнни терминны гади итеп аңлатып бирү алымын күрдек. Әлбәттә инде, күчерелмә мәгънәле, сурәти чаралар: ул (Рауза) сәхнәгә ***җил сыман атылып килеп керә...; ут уйнатып чыгып та китә...; мәхәббәт дәрьясында иркен йөзгән...; кытлык кичермәде*** h.б.

Монда янә бер тезис сорала шикелле: фәнни-популяр стильдә дә, башка стиль төрләрендәге кебек, штамп-калып барлыкка килү куркынычы юк түгел. Шул ук вакытта бу хилафлыктан котылу юллары да, ягъни иҗадый эзләнү табышларына ирешү мөмкинлеге дә аз түгел. Әйтик, сәхнә, драматургия сөйләмен чеп-чи фәнчә, академик тонда аңлату белән аны гамәли яктан ачып бирә торган популяр стиль арасында аерма бар: монысы җанлы сөйләмгә тартым, сүз сайлауда ирекле лек сизелә. Театр белгече Рабит Батулла «Хәтәр хәтер» исемендәге истәлегендә театр эшчәнлеген, артистлык сәнгатен фәнни нигездә тирәнтен анализ ясарга омтылып, тасвир чараларын мул кулланып язган иде: анда троп-сүзләрдән алып (миңа бу роль ***батмый***; Әхмәт абый ***куырды*** гына безне) бөтен бер жаргон, гыйбарәләргә хәтле (Әхмәт абый Харамшаны ***яндырып*** уйнаган иде; вак гармуннарда ***өздереп*** уйный; Тамашачы ***шаша;*** Мин үземне мәһабәт ир-җегет дип уйлап йөри идем, шуңа күрә сәхнәдә мәхәббәт каһарманнарын уйнарга омтылам һәм укытучыларның ***колагына чикерткә булып керәм, миңа матур рольләр бирегез, дим*** h.б.

Шул ук вакытта термин, профессионализмнарны, алынмаларны төшендереп бирү ысулларын да да киң кулланган (2 нче сыйныфның кышкы *татилында (каникулында)* мин авылга кайттым» (М.ж., 2013, 15 февр.).

Фәнни-популяр стиль төсмерен барлыкка китерүче ике катлам чыганакны табигый синтезлау төгәл фәннәр турында фикер йөрткәндә (аңлатканда яисә тасвирлаганда) шактый катлаулана. Әйтик, заманча фәннәр арасында экология юнәлеше дә соңгы елларда активлашты. Татар галимнәре дә бу фәннең нигезләрен аңлату, гамәли әһәмиятен төшендерү юнәлешендә матбугатта еш чыгыш ясый. Менә мисал – педогогия фәннәре докторы, КФУ профессоры Җәүдәт Хөсәеневнең бер язмасыннан өзек:

«Татарстан Республикасы мәйданы борынгы заманнарда урманлы төбәк булып саналган. Ләкин соңгы 170 ел *эчендә* биредәге урманнарны күпләп кискәннәр. Хәзерге вакытта туган ягыбызда урманнар бик аз һәм алар республика *территориясендә* тигез таралмаган. Аерым районнарда урманнар *бары тик* 3 процент *кына* сакланып калган, ә кайберләрендә исә ул 45 процент чамасы мәйданны били. Урман ул икмәк үсми торган, яисә үсеп тә, үзен аклый алмаган җирләрдә дә үсә ала. Шулай булгач, аны авыл хуҗалыгы өчен яраксыз бар урыннарга да утыртырга кирәк.

Урманны ***җирнең үпкәсе*** дип атыйлар. Халык кислородка бай һава суласын өчен Татарстан республикасы барлык мәйданының 25 процентында урманнар үсәргә тиеш, әмма, ни кызганыч, әле ул 16 процент кына тәшкил итә. Нефть химиясе, машина төзелеше, нефть сәнәгате объектлары белән ***шыплап тулган*** һәм республиканың халкы тыгыз урнашкан районнарда урман

мәйданнары ике мәртәбәгә артык булырга тиеш. Ләкин алар бик аз, әле районнарда ул бары тик 10–12 процент кына мәйдан били. Чөнки Камаз, Алаз, Түбән Кама химия комбинаты шикелле гигантлар төзегәндә,табигатьне саклауга тиешле игътибар бирелмәде. Кыска гына вакыт *эчендә* урман эчләрендә ял базалары, профилакторий-санаторийлар, пионер лагерьлары төзеп куйдылар. Күп гасыр яшәгән нарат урманнары киселде. Соңгы вакытта еш күзәтелә торган табигать бәла-казалары да туган ягыбыздагы урманнарның күпләп юк ителүенә сәбәпче булып тора (М.җ., 2013, 22 март).

Бу язмада гади сөйләм элементлары (***отыры***), троп, метафора, чагыштыру, әйтем, мәкаль, афоризмнар: (***бер генә чишмәгә җан өрсә дә...; урманны җирнең үпкәсе дип атыйлар; урмансызлык – уңайсызлык; урманның кадерен ул беткәч кенә аңлый башлыйбыз...*** h.б.).

Игътибарга алынырга тиешле бер фактор күзәтелә икән: популярлык төсмере салынган лексик чаралар арасында калькаларның да «кысылу» куркынычы бар. Бу текстта, мәсәлән, « табигатьне саклау җәһәтеннән ***чыгып...***» h.б.;

Фикерләү катлаулырак булган саен аны белдерә торган лексик-семантик, грамматик һәм стилистик чараларны сайлап алу, синтезлау да катлаулана бара. Фәлсәфә фәне, аерым алганда аның теология өлкәсенә караган юнәлешләре-темалары да татар гыйлемендә үзенә мөстәкыйльрәк фикерләү алымнары белән эш итә, ягъни үзенә мөстәкыйль сыйфатлары булган популяр сөйләм формалашкан дип бәяләргә нигез бар. Моны бер мисал – Рашат Сафинның «Яшәү мәгънәсе – танып белү» дигән мәкаләсендә (М.җ., 2013, 6 сент.) күзәтеп алыйк әле.

«Ислам өйрәтүенчә, Аллаһтан башка илаһ юк. *Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.* Динебездә менә шушы хакыйкатьне тану иманга килүнең төп шарты булып тора. *Мөәмин-мөселман* әлеге хакыйкатькә ихластан инана һәм аны тануы хакында *шаһидлек кыла.* Шуңа күрә бу гыйбарә *шаһәдәт* дип атала. Аның мәгънәсе нидән гыйбарәт? Шәригатьтә моңа төгәл җавап юк. Дөресрәге, ***бар-барын***, тик ул тулы түгел. Шуның аркасында бүген мөселман дөньясы ***тирән кризис*** кичерә. Мәсьәләне ачыклап үтик.

Аллаһ парлылар дөньясы итеп яралткан (Коръән, 51:4) Җиһан төзелешендә һәм яшәешендә бу – универсаль принцип. Ул илаһи идарәчелекнең бөтен катламнарында үз чагылышын тапкан (әйтик, плюс–минус, Аллаһ–кеше, ир–хатын, идея–материя h.б,). Шаһәдәтне әлеге универсаль принципның формуласы дип әйтә алабыз. Ул ике – *тәүхиди* һәм *иҗтиһади* кисәкләрдән тора. Беренчесе Аллаһтан башка һичбер илаһ юклыгы турында кисәтсә, икенчесе исә Мөхәммәднең Аллаһ илчесе булуы хакыйкый чынбарлык икәнен раслый...» (М.җ., 2013, 6 сент.).

Биредә «популяр» сыйфатын аклый торган чараларны мантыйкый-синтаксик дип атарга мөмкиндер: фәнни-дөрес тон җәенке җөмләләр белән ирешелә. Фәнни төшенчә-терминны өстәмә аңлатып-төшендереп барган искәрмәләр (алар җәяләр эчендә бирелә) җөмлә кисәкләре буларак кабул ителә. Урынлы табылган тасвир чаралары да, аерым алганда чагыштырулар, фәлсәфи

чыгарма буларак кабул ителә (***Бераз аякка баскач, ул (фән) ата-анасына буйсынудан чыгарга омтылучы үсмер сыман... динне кире кага башлаган;*** гади троп, метафора, әйтем, мәкальләр дә табигый кабул ителә (***чүп өстенә чүмәлә*** h.б.). Шушы авторыбызның икенче бер мәкаләсендә дә («Диннәр берләшүе – заман таләбе») стильләр төрлелеге чагыла торган төрле лексик, фразеологик тасвир чаралары (***татар акылы төштән соң; тату; сабак алу*** h.б.); чаралары белән бергә синтаксик фигуралар да көчле тасвир-сурәт чарасы буларак кулланыла. Мәкаләне йомгаклаган соңгы җөмләгә генә игътибар итик: ***Ә бит вакыт, җәмәгать, моннан арынырга, ай, бик вакыт...*** (М.ж., 2013, 25 окт.).

Фәнни-популяр стильне өйрәнү өчен тәкъдим ителә торган текстлар, авторлар турында һәр укучыбызның үз тәкъдиме, фикерләре барлыгы бәхәссез. Шөкер, бу кыйблада мирасыбыз мулдан. Бу темага багышлап уку-укыту кулланмасы чыгару мөмкинлеге бирелсә, ул мәҗмугада, әйтик, тарих темасына Индус Таһировның, авыл хуҗалыгы турында Марат Әхмәтевнең, икътыйсад турында Илсөяр Хәйруллинаның, спорт турында Атлас Гафиятевнең һәм дә янә уннарча оста каләмдәшләребезнең иҗат җимешләрен күрә алыр идек. Бу исемлекне үзегез дә тулыландыра аласыз.

Хәзер менә сөйләмебездә фәнни-популяр стиль барлыгына һәм аралашуыбызда аның шактый әһәмиятле урын тотуына инанганнан соң, бу лингвистик күренешкә гыйлемиятебездә ни дәрәҗәдә игътибар бирүебез турында уйланып алыйк. Башта бер сорау: бу хакта уйланырга кирәк микән соң? Кирәк икән! Моны без көндәлек тормышта тоеп торабыз. Узган ел азагында КФУда «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» дип аталган II халыкара фәнни-гамәли форум булды. Югала-үлә баручы телләр өчен борчылу байтак чыгышларда әйтелде. Менә Төркиянең Эгей университеты профессоры Мостафа бәй Өнәр сүзләре: «Дэвид Кристалл дигән галим, бүген дөньяда 6-7 мең тел бар дип исәпли, – диде ул. – Аның фаразы буенча шушы телләрнен яртысы юкка чыгачак икән. Телләрнең үлүе дә табигый бер күренеш. Төрки телләр арасында да юкка чыкканнары бар...».

Игътибар итик әле: галим телнең бетүен аерым өлешләрдән башлана дип аңлата, телнең аерым бизәкләре кими бара, ягъни хәсияти сыйфатлары. Татар теле турында тәгаенләбрәк әйткәндә, галим дәүләт теле буларак ул да бүген куркыныч астында, ди. Дөрес, әдәбият теле буларак, аңа куркыныч янамый, чөнки мең еллык әдәби мирас бар. Ләкин тел яшәсен өчен ул гына җитми. Татар теле фән теле буларак та кулланылырга тиеш – информатикада, физикада, химиядә...

Үткән гасырның 30–40 нчы елларында төрек теле фән теле буларак аякка бастырыла. Татар теле дә беренче чиратта укыту, фән теле буларак гамәлгә куелырга тиеш. Телне саклау –ул филологлар эше генә түгел, татар телен яшәтүдә Татарстан хөкүмәтенең анык максаты булса гына моңа ирешергә мөмкин. Татар теленә дәүләти дәрәҗәдә кулланыш бирү кирәк...».

Бу форумнан репортаж биргән журналистыбызның әлеге чыгыштан ясаган нәтиҗәсе белән без дә ризалашабыз: бу бит татар теленең барлык тарихи

сөйләм төрләрен, ягъни җанрларын сакларга, үстерергә, камилләштерергә кирәк дигән сүз. (Э.Сиражи. Телсез калмыйк, илсез калмыйк, дисәк... // М.җ., 2013, 25 окт.). Бу хакта икенче бер форумда артист Әзһәр Шакиров әйткән фикерләр дә ышандырырлык дәлил бит: «Соңгы елларда татар телен ничек саклап калырга, дип борчылабыз. Бу фестивальгә (XIII төбәкара «Идел-йорт» халык театрлары фестивале) йөргәндә мин бер нәрсәгә бик нык ышанам – әгәр татар телен сакларга, үстерергә, милләтебезнең барлыгын исбат итәргә телисең икән, халыкны берләштерүче бер зур көч бар, ул – сәнгать, һәм бигрәк тә театр сәнгате. Беренчедән, театр телне саклап калуның иң үтемле чарасы. Икенчедән, авыл җирендә, районда театр булу ул халыкны берләштерә, дуслаштыра... (М.җ. 2013, 25 окт.).

Телнең стиль мөмкинлекләре тулы колачына, көченә файдаланылсын, ягъни фәнни-популяр стиль дә татар кешесе сөйләмендә лаеклы урын биләсен өчен, безнеңчә, ике төп шарт зарур. Беренчедән, җәмгыятьнең һәр шәхесе аның яшәештәге асылын, фәндәге өйрәнелү дәрәҗәсен белергә тиеш. Моның шулайлыгына шик белдерергә сәбәпләр бар мәллә? Бар бугай шул: бүген тел гыйлемиятендә дә, гамәлиятендә дә хәтта төп жанрларның (ягъни төп сөйләм төрләре – стильләренең) атама-исемнәренең алмашынып торуы, димәк ки, һаман утырып бетмәве, бәхәсләр чыгып торуы да бу сөйләм төрләренең әле һаман фәнни ачыкланып бетмәвенә ишарә. Нәсер, хәтирә, ядкәр, мәдхия, мәрсия кебек җанрлар турында әле һаман бәхәсләр бара. (Рабит Батулла. М.җ., 2013, 15 февр.). Язучыбызның «Хәтәр хәтер» дигән хәтирәләрендә «Нәсер» дигән бүлек бар. Анда «Кыйсса», «Роман», «Повесть», «Нәсер», «Эссе»., Хикәя», «Хикәят» кебек жанрларның һаман да төрлечә аңлатылуы турында фикерләр әйтелә... «Кызганыч ки, соңгы вакытларда татар язучылары «нәсер» кебек матур яңгырашлы, тирән мәгънәгә ия кәлимәбез урынына «эссе» дип яза башлады. Ауропа дәрәҗәсенә күтәрелергә тырышыпмы, әллә без кемнән ким дипме, кайбер язучылар матбугатта «фәлсәфи хикәяләр, фәлсәфи уйланулар, эссе, сатирик парчалар» кебек, ана телебезгә ятышсыз жанрлар билгеләп, әсәрләрен бастырып чыгара тора. Укып баксаң, кайчак анда кулга тотып карарлык бер генә фәлсәфи фикер дә булмый. Әсәрнең атамасы астына автор язып куйган сүз аның җанрын билгеләми, әсәрнең җанрын вакыйгалар, холыклар, фикер әйтү шәкеле билгели».

Шөкер, безнең җәмгыятьтә бүген телне куллану нәзәриясе, шул җөмләдән стилистика нигезләре турында тарихи мәгълүмат җитәрлек һәм халыкның сөйләм культурасы дәрәҗәсе иң алга киткән милләтләр дәрәҗәсендә дип горурланып әйтергә була. Бу юнәлештәге мирасны яшьләр дә үзләштерсен өчен бу өлкәдә фәнни, педагогик әдәбиятыбыз бар. Телебезнең кулланылу дәрәҗәсе иң кысылган, изелгәннәр хәлендә булса да, 500 ел бу бу юнәлештә торгынлык хакимлек итсә дә, мөмкинлек булу белән татар тел гыйлеме өслүбият, стилистика, сөйләмият юнәлешләрен ничек тә өйрәнергә, укытуга җәлеп итәргә омтылган.

Бу юнәлешне фәнни кыйблада өйрәнү омтылышын К.Насыйри, Г.Ибраһимов, Л.Җәләй ясый. Аннары инде Х.Курбатов, В.Хаков, Ф. Фасеев,

В.Хангилдин, С.Поварисов, И.Бәширова, Р.Абдуллина бу теманы махсус өйрәнү юлыннан китә. Кыскасы, татар теленең тармаклы (стилистик) куллану тарихы һәм мөмкинлекләре егерменче гасырда тел гыйлемендә шактый системалы һәм тирәнтен, колачлы өйрәнелә. Бу эшчәнлекнең нәтиҗәләре татар теле грамматикасы дәреслекләрендә, Академик басмада һәм энциклопедик йомгаклауларда лаеклы урын ала.

Мәсәлән, «Татар энциклопедиясе»ндә «Стилистика» термин-төшенчәсенә махсус мәкалә багышланган; кыскача эчтәлеге болай. Башта игътибарга алыйк әле: бүгенге милли аңда, хәтта фәнни даирәдә дә, стилистика төшенчәсе ике кыйблага да – әдәбият нәзәриясенә дә (стиль – ул сәнгатле, сурәтле тасвирлау чарасы), шул ук вакытта тел гыйлемиятенә дә карый дигән фикер яши бирә. Энциклопедиябез бу икеле-микелелеккә берникадәр ачыклык кертә. Анда «стилистика – тел гыйлеменең телдәге стильләр системасын, тел ярдәмендә сөйләм оештырып аралашуның төрледән-төрле рәвешләрендә тасвирлау чараларын куллану закончалыкларын өйрәтә торган бүлеге» диелгән. Бу очракта татар теле гыйлемиятендә элек-электән кулануга кереп килгән өслүбият терминын фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү дә бик вакытлы, урынлы буласы икән дә. Хәер, стилистиканың ике тармагын бутамас өчен безнең моңарчыгы фәнни филологик әдәбияттә «функциональ стилистика» һәм «лингвистик стилистика» дигән атамалар да кулланыла иде. Тел стилистикасы дигән төшенчәне фәнни нигездә аеруны үз хезмәтләрендә В.Хаков башлап җибәреп, аңа шактый тәфсилле анализ ясаган иде. Ана телебезнең сөйләмне төрле мотивларга (кемнең; кемгә; нинди нияттән; нинди шартларда – әйтепме, языпмы, күрсәтепме h.б.) бәйләп оештырганда, фикер һәм хис нечкәлекләрен белдереп, җиткереп, төрлечә тәэсир итү мөмкинлеген бирә торган чараларының (өн, аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст шәкелләрендә) тәэсир үзенчәлекләрен ачыклый инде ул өслүбият.

Татар кешесенә хезмәт иткән, аның сөйләмен тәэсирле итү, төрлеләндерү мөмкинлеге биргән өслүб чаралары система булып тупланган мең еллык тарихи мирасыбыз бар. Татар халык иҗатының бай хәзинәсендә генә дә дастан, әкият, җыр, мәзәк, бәет, мөнәҗәт, мәрсия, хикәят кебек жанр төрлелеге үзе үк өслүб мирасының ифрат бай булуына ишарә. Халкыбызның тел мирасын куллануны баету чаралары – сәнгатьнең төрледән-төрле формаларына ия булуы да шул хакта сөйли: төрле жанрлардагы әдәби, сәнгати иҗат (нәфис әдәбият, публицистик-журналистик иҗат, сәхнә сәнгате, рәсем, нәкыш, җыр-бию h.б.) төрледән-төрле сөйләм шәкелләрендә (жанрларында – журналистикада гына да йөз тирәсе жанр төрләре тәгаенләнә) ана телебезнең бай мөмкинлекләрен өйрәнергә юл ача.

Хәзер килеп, әлеге энциклопедик документта рәсмиләштерелгән өслүб төрләрен санап китик (алар башлыча рәсми-методик документларда, мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә дә шул ук дәрәҗәдә диярлек теркәлгән): менә татарның фәнни нигезләнеп, рәсми кабул ителгән, бүген актив кулланышта булган тел стиле төрләре: әдәби-сәнгати стиль (нәфис әдәбият

стиле), фәнни стиль, рәсми-эш кәгазьләре стиле, иҗтимагый-публицистик стиль, эпистоляр (хатлар) стиле.

Шунысы әһәмиятле, бу мәкаләдә әлеге төп өслүб төрләренең кыскача гына булса да төп-асыл сыйфатлары тәгаенләнгән, аларның, әгәр бар икән, төп стильнең өстәмә төрләре (подстильләре) аерып аталган. Менә фәнни стильнең өч төре аерып тәгаенләнгән: фәнни, фәнни-мәгариф, фәнни-популяр.

Искә алыйк, моңарчы гомумиләштерелгән фәнни-рәсми документларда фәнни-популяр стиль төре аерым чыгарылмый иде, гәрчә термин-төшенчә үзе (*фәнни-популяр*) Аңлатмалы сүзлегебездә теркәлгән булса да (Фәнни-популяр. Фән һәм техника өлкәсендәге казанышлар белән гади, аңлаешлы формада таныштыра торган. *Фәнни-популяр әдәбият. Фәнни-популяр фильм.* 358 б.); шуңа күрәдер инде гамәли журнал, басмаларда аларны жанр төре буларак фәнни-популяр дип тәгаенләү күзәтелми иде.

Сөйләмне (текстны) популярлаштыру, ягъни, сүзлек аңлатканча, гадиләштерү, аңлаешлы итү өчен төрле алымнар кулланыла. Менә кайберләре генә: гади сөйләмдә өстәмәләр бирү: а) текст эче өстәмәсе җәяләр эченә алынып бирелә («Кол Галинең тууына 800 ел тулу уңае белән – тел галиме Фазыл Фасиев, текстны транскрипцияләп, искәрмәләр һәм глоссарий **(аңлатмалы сүзлек)** белән фәнгә мәгълүм кулъязмаларын тасвирлап бастырып чыгара (А.Мөбарәкшинаның рецензиясе. «Чын мирас, 2014, №2, 120 б.); б) бит асты искәрмәсе; в) текст тышы искәрмәсе.

Фәнни-популяр стиль төренең барлыгы, димәк ки аны өйрәнү ихтыяҗының булуы ул аерым галим, белгечләрнең мәсьәләне төпле өйрәнүе, объектив нәтиҗәләре йомгагы буларак барлыкка килгән. Менә кайбер галимнәребезнең бу юнәлештәге фикерләре.

Фәнни стильне җентекле өйрәнгән В.Хаков мондый нәтиҗә ясаган. Татар милли әдәби теле формалашу чорында фәнни стильдә төп ике юнәлеш барлыкка килә. Аның беренчесе – элек-электән традицион язма китап телен чагылдырган һәм югары стиль үзенчәлекләрен эченә алган фәнни әсәрләр (Ш.Мәржани һ.б. галимнәрнең хезмәтләре). Икенчесе – халык сөйләү телендә, халык стилендә язылган әсәрләр. Һәр ике юнәлешнең традицияләре бик ерактан килә.

Фәнни гуманитар әсәрләрне киң сферага җәелдерүдә, халыкчан итүдә Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Зәки Вәлиди, Гайнетдин Әхмәрев һ.б. зур эш башкаралар. Бу юнәлеш соңа таба төрле фәннәр өлкәсендә башка галимнәр тарафыннан тагы да үстерелә.

Бер закончалык күзәтелә: халыкчанлык юнәлеше фәнни стильдә матур әдәбият стиленә караганда чагыштырмача акрынрак бара. Бу, һичшиксез, фәнни әсәрләрнең специфик үзенчәлекләре белән бәйләнгән, дип билгели Вахит Хаков (Татар әдәби теле (стилистика). Казан: Татар кит.нәшр., 1999. 257 б.).

Татар телендә фәнни стиль белән бәйләнештә аның төрчәсе фәнни-популяр стиле барлыгын ышанычлы итеп Х.Курбатов икърар итте: «Фәнни иншалау стиле. Фәнни әдәбиятнең белгечләр өчен язылганы һәм белгеч булмаган кешеләр өчен язылганы бар. Шуңа карап фәнни стиль һәм фәнни-

популяр стильләр барлыкка килгән. Фәнни стильдә, башлыча, белгечләрнең үзләре генә аңларлык сүзләр һәм терминнар кулланылса, фәнни-популяр стиль мөмкин кадәр гади тел белән шул язылганның асылына башкаларны да төшендерүне күздә тота».

Фәнни сөйләмнең хәсияти сыйфатларын төпле ачыклау белән берәттән популярлык сыйфатларына да галим дәлил, мисаллар китерә. (Х.Курбатов. Сүз сәнгате: татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. Казан: Мәгариф, 2002. 28–29 б.).

Сүз уңаеннан бер фикерне өстәп китик: сөйләмне тәэсирле, йогынтылы итү өчен тел чараларын сайлау осталыгына ирешкәндә стильләр төрлелегеннән файдалану тәҗрибәсен өйрәнергә омтылган белгечләргә, беренче чиратта иҗатчыларга, тел гыйлеменең, филологиянең стилистика, поэтика, риторика, социолингвистика һ.б. юнәлешләрен төпле өйрәнергә кирәк була. Татар теленә кагылган менә бу юнәлешләрдәге күзәтүләр күренекле әдибебезнең әлеге һәм башка хезмәтләрендә шактый җентекле яктыртылган.

Заманында, матбугат сөйләмен өйрәнү, фәнни хезмәт язу өчен гаммәви чаралар сөйләмен колачлы өйрәнергә керешкәндә үземә дә татар сөйләм системасын, жанрларын төпле анализларга кирәк булды. Матбугатка, аның сөйләменә мөнәсәбәттә гамәлдәге стильләр системасының тәэсирен җентекле күзәтергә туры килгән иде. Татар телендә публицистик сөйләм төренең (журналистик-публицистик, иҗтимагый-публицистик дип тә атала) басма гаммәви чараларның йөзилле еллык тарихы буена махсус стиль төре булып формалаша, үсә, камилләшә бару факторы, аның составында гаммәви аралашу чаралары сөйләме барлыгы, бүген дә стильләр системасында актив хәрәкәт итүе безнең хезмәтләрдә дә икрар ителгән иде (И.М.Низамов, Матбугатның тәэсирле сүзе.: Газет сөйләме мәсьәләләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 1982. 126 б.; Аныкы ук. Уем – тел очында...Татар сөйләменең нигезләре.– Казан.Татар.кит.нәшр., 1999. 287 б.).

Бу өлкәдәге өйрәнүләребезнең нәтиҗәсе буларак без фәнни стильнең фәнни-публицистик, ә рәсми стильнең рәсми-журналистик төсмерләре (подстильләре) барлыгын исбат иткән, бу төшенчәләрне фәнни әйләнешкә тәкъдим иткән идек. Гыйлми җәмәгатьчелек ул тезисларны кабул иткән иде. Бу закончалыкларны дәлилләгәндә, без татар гыйлемиятендә техник-конкрет фәннәр (математика, физика, химия һ.б) буенча гына түгел, гуманитар, филологик фәннәр (философия, психология, мантыйк һ.б.) буенча да фәнни басмаларның бөтенләй дә диярлек булмавын, ә татар фикерләвендә бу конкрет предмет-фәннәрнең предмет буларак та, фән буларак та әкренләп үсүе, татар белгечләре, галимнәренең исә үз фикерләрен җәмәгатьчелеккә җиткерү ихтыяҗын, фәнни сөйләм таләпләрен берникадәр үзгәртеп булса да, көндәлек матбугат стиленә яраклаштырып белдерергә мәҗбүр булуы сәбәпче дигән идек. Бу ничарадан бичаралыкның йогынтысын без фәнни-популяр стильнең формалашуында гына түгел, бүгенге яшәешендә дә күрдек. Процесс дәвам итә. Без аны бүгенге яшь галимнәр иҗатында да күзәтәбез. Чөнки тормыш үзе моңа дәлилләр биреп тора: телебезнең дәүләт теле буларак төрле юнәлешләрдә

(стильләрдә, даирәләрдә, төрле шартларда) кулланылуы, төрле инновацион үзгәрешләр йогынтысына бирелүе, алынмалар, төрледән-төрле экстра,-паралингвистик чаралар (мәсәлән, интернет сөйләмендә халыкара чараларның тәэсир итүе) белән чуарлануы h.б. Боларны фәнни нигездә җентекле өйрәнергә кирәк.

Гомумән дә бу стиль төренең үсешенә, үзгәрүенә интернет сөйләменең йогынтысы зур, тик ул әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Безнең гомуми язмаларда берникадәр күзәтү, йомгаклар бар. Төплерәк өйрәнү сорала. Әйтик, Азатлык радиосының аналитик язмаларында (Татар конгрессы корылтаена, башка милли вакыйгаларга багышланган махсус тапшыруларда h.б.) жанрлар синтезын, фәнни-популяр стильнең хәрәкәттәге хәлен күзәтергә була.

Бу чыгышыбызның күптән әзерләнеп килеп тә нәкъ менә «Мәгариф» журналының 100 еллык юбилее уңаеннан оештырылган конференциягә туры китерелүе очраклы хәл түгел. Татар телен гомумән дә, аерым алганда аның стильләренең үстерелүендә, шул процессны өйрәнүдә, фәнни-популяр стильнең әкренләп формалаша, үсә баруында бу журналның әһәмияте зур. Аның бу кыйммәтле үзенчәлеге фәндә моңарчы да искә алынып торылды, журналның бу юнәлештәге эшчәнлеге филолог-студентларның, аспирантларның фәнни эшләрендә чагылды, укытучыларның гамәли эшчәнлеген камилләштерү юнәлешендә күнегү материаллары булып хезмәт итте.

Журнал татар стилистикасы фәнен үстерүгә дә игътибар итә килде. Хәтерлим: татар сөйләмияте турында тәүге мәгълүматны башлап «Мәгариф» (ул чорда «Совет мәктәбе») бәян итте, җитмешенче елларда минем дә берничә фәнни-популяр язмам урын алды. Татарның көчле стилистлары В.Хаков, Х.Курбатов, Ф.Сафиуллина, И.Бәширова һәм дә башкалар журналның даими авторлары иде.

Бу кыйблада «Фән һәм тел» , «Фән һәм мәктәп» журналларының да бай тәҗрибәсе бар, алар иң катлаулы төгәл һәм техник фәннәрне дә мәктәптә, югары уку йортларында үтемле итеп аңлата алган мөгаллимнәребезнең үрнәген бирә килде; «Казан утлары», «Сөембикә» журналларында да стиль төрлелеге мөмкинлекләрен, бу өлкәдә әдәбиятебез туплаган тәҗрибәдән оста файдалану үрнәкләрен күрсәтә килгән язмалар басылып тора. Аларны бөртекләп өйрәнергә, яшь иҗатчыларга да ирештерә торырга кирәк. Монда яшь галим, белгечләрдән активлык сорала. Кызганыч ки, соңгы елларда мондый активлыкның, аерым алганда фәнни-популяр стиль белән кызыксынуның, бу төр сөйләм белән мәшгульлекнең сүрелә баруы күзәтелә. Шәхсән үзем ике диссертация яклау советында әгъзамын. Яшьләрнең фән белән кызыксынуы кимеми – диссертация яклау сан ягыннан артып тора. Шул ук вакытта яшьләрнең фәнни казанышларын халыкка җиткерү, үз ачышларын пропагандаларга омтылуы җитенкерәми. Фән казанышы бит ул халыкныкы, милләтнеке. Халыкта фәнгә мөнәсәбәт тәрбияләү дә галимнең үз бурычыдыр. Ә моңа фәнни-популяр сөйләм ярдәмендә, махсус чыгыш-язмалар белән эш итә белеп кенә ирешеп була. Бүген яшьләр бу өлкәдә җаваплылыкны үз өсләренә

алырга омтылмый кебек. Сәләт тә, тәҗрибә-осталык та җитми, күрәсең. Югыйсә, диссертация яклаган һәр яшь галимгә фәнни-популяр язмасын бастыру мөмкинлеге барлыгын (аерым алганда андый язмаларга «Мәдәни җомга» газетының «И туган тел...» кушымтасында урын биреләсен) искәртә киләбез. Тик моңардан файдаланучылар бармак белән генә санарлык.

Узган ел берара журналлар белән бәйле үзгәрешләр була башлагач, Казанда да ВАК журналы ачалар икән, дигән хәбәр таралып алды. Әйбәт булыр иде: чөнки диссертация яклаучыларга фәнни хезмәтләрен бастырыр өчен дәүләткүләм Аттестация комиссиясенең басмалары җитәрлек түгел, яшьләр матбугатка чыга алмый интегә.

Тик мондый басманы татар журналы «Мәгариф»не (һәм әле чыгып килгән башка басмаларны) томалау исәбенә ирешү зур хата, хәтта җинаять булыр иде. Беренчедән, ул инде татарча журнал булмаячак, язманың эчтәлеге татар теленә, бүтән төрки телләргә караса да, ВАКта диссертацияләр урысча гына якланырга тиеш дигән катгый тәртип хакимлек иткәндә, аның журналларында да язмалар урысча гына булырга тиешлеге мәнди анасына да аңлашыладыр.

Монда бер өстәмә сорала: безнең кайбер журналларда, мәҗмугаларда (мәсәлән, КФУның «Тонус» альманахында, Татарстан, Башкортстандагы кайбер басмаларда) язмалар ике-өч телдә (алфавитта) басыла. Без аларга, гомумән, уңай карыйбыз. Тик мондый форма фәнни-популяр стильне үстерүдә нинди дә булса уңай тәэсир ясый дип булмыйдыр. Һәрхәлдә бу стильне үстерүдә тик татарча чыга торган басма гына чынлап хезмәт итә аладыр. «Мәгариф» бу кыйблада йөз ел башкарган изге эшен намус белән дәвам иттерер дигән өметтә калабыз. Аның укучылар гаиләсен дә шушындый ниятле укучыларыбыз тәшкил итәр, дибез.

Сөйләм төрләренең иҗтимагый аралашуда активлашуына, аерым алганда фәнни-популяр стильнең киләчәктә үсешенә нигез булырдай икенче шарт – ул тел куллануга киләчәктә ихтыяҗ. Тел куллануда фәннилекне көчәйтү, аерым алганда төрле катлам сөйләм рәвешләрен органик рәвештә синтезланып, бер-берсенә керешеп, баетышу барышын фәнни өйрәнү ихтыяҗы ул тормыштан, гамәли таләпләрдән килеп туа. Соңгы вакытта татар журналлары дөньясында шактый җанлану бара: яңалары барлыкка килде, икенчеләре газета рәвешен үзгәртте, өченчеләре исем-атамаларын алыштырды. Болар, башлыча, аларның формасына кагылса, җисемнәренә дә тәэсир итми калмый. 2014 ел башында Татарстан радиосы «Безнең мирас» журналына багышланган «түгәрәк өстәл» оештырып, анда басманың бүгенгесе, киләчәге турында сөйләшү үткәрде. Вакытлы чара. Гомумән дә, форсаты да чыгып тора бит: соңгы елларда татарча бу кадәр дә журнал күргәнебез юк иде бит әле. Аларны чын мәгънәсендә халык укый торган, популяр итәргә омтылыш ясап калырга кирәктер. Бөтен көчне куеп!

Тапшыруга журнал чыгаруны оештыручы җитәкче даирәдән тыш күренекле язучылар, журналист, тарихчы, җәмәгать эшлеклеләре, сәнгать белгечләре дә чакырылган иде. Төрледән-төрле фикер, тәкъдим әйтелде. Без

инде бүгенге темабызга – журналның бер бөтен әсәр буларак, укучы аны башыннан азагынача мавыгып, файдасын күреп укып чыксын өчен бик тә төрле теманы эченә алып та шуларның бер әсәр кебек кабул ителүенә ничек ирешергә кирәклегенә тукталыйк.

Татарстан республикасының традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Фәнзилә Җәүһәрова бик урынлы деталь белән сөйләшүгә конкретлык кыяфәте кертеп җибәрде: журналга фәнни-популяр дигән өстәмә исем бирелүе зур җаваплылык өсти – димәк ки, басманы барлык халык укый алырлык булырга тиеш, диде. Башка катнашучылар да бу тезиска сизгер булдылар: моңа таянып, кайбер гамәли әһәмиятле киңәшләр дә әйтелде, мәсәлән, журналны республиканың барлык мәктәпләренә һәм китапханәләренә, идарә органнарына дәүләт исәбенә яздыртып булмасмы; журналның тематикасын халыкның төрле катламнарына ярарлык итү чараларын күрергә кирәк һ.б. Безнеңчә, популярлык бирә торган сыйфатлар рәтендә жанр үзенчәлекләрен, материалларны сурәти, фото чаралар белән бизәлүне искә төшерүләре дә урынлы иде. Шулай да төп сыйфатлар арасында әсәрләрнең теле турында борчылып гәпләшү үзеннән-үзе соралган табигый шарт иде. Популярлык шартына ярар өчен әсәрнең тел-сөйләм сыйфаты нинди булырга тиешлеге йөз елдан күбрәк тарихы булган матбугат өчен әллә кайчан фәнни тәгаенләнгән, кагыйдә буларак урнашкан-береккән булуга карамастан, яңа шартларда таләп ителә торган яңа таләпләр килеп чыгып тора икән. Тел өлкәсенә кагылганнары да. Нинди генә темага, нинди генә җанрда язылса (әйтелсә дә) фикер беренче чиратта ана телебез белән белдерелә. Әлбәттә, сөйләм оештырганда тел чаралары рәтендә тавыш, ым, ишарә, сурәт, фото кебек экстра-, паралингвистик чаралар да әһәмиятле. Шулай да, тел – үзәк чара-корал. Әлеге әңгәмә барышында бу закончалык-кагыйдә үзеннән-үзе калкып чыкты. Әлбәттә, фәнни-популярлык умырткасы ул ана теле икәненә басым ясаучыларның, беренче нәүбәттә, шагыйрь, язучы, журналистлар булуы һич очраклы түгел. Әңгәмәчеләр башлыча шагыйрь булса да Р.Харис, Р.Вәлиев, М.Галиев, Р.Зәйдулла телгә тар шигъриятчеләр юнәлешендә түгел, ә бәлки телнең гомуми аңлашу-аралашу чарасы икәнлеген күздә тотып фикер йөрттеләр. Әлбәттә, фәнни күзаллауда гомуми таләп-сыйфатлар өстенлек итсә, өндәү-үгет көчлерәк булса да тел таләпләре системасына кертерлек тезислар да әйтелде. Мәсәлән, фәнни-популяр сөйләмдә тәрҗемә текстының урыны мәсьәләсе җитдидән кузгатылды. Әлегә андый текстлар популярлыктан ерак тора, дип борчылып әйтелде. Тискәре мисаллар китерелде, аларның сәбәпләрен ачыкларга омтылыш ясалды. Иншалла, файдасы тими калмас.

Шушы уйлану барышында күптән түгел хәтер дәфтәренә теркәп куйган бер өзек искә төште: «Урыс теле йогынтысында татар теленең табигыйлыгына зыян килә, аның үзенә генә хас үзенчәлекләре, сыйфаты, фән теле белән әйткәндә, нормалары бозыла бара. Моның бер сәбәбе – татарча сөйләгәндә һәм язганда кирәксезгә урыс сүзләре кушып сөйләү булса, икенчесе – урыс теле әйтелмәләре үрнәгендә туган телнең табигатенә туры килми торган уңышсыз әйләнмәләр, тәгъбирләр ясап куллану. Андый әйләнмәләр (сүзтезмәләр) шуңа

күрә гайре табигый килеп чыга: аларны тәшкил иткән сүзләр татарның үзенеке булса да, әйтелмәнең өлгесе, төзелеше урысныкы. Мәсәлән, соңгы вакытларда урыс теленнән хәрефкә-хәреф тәрҗемә ителгән (калькалаштырылган) *тере акча, тере тавыш, тере чәчәк, текә егетләр* кебек йөзләрчә ясалма, уңышсыз тәгъбирләр шундый ялгышларны тәшкил итә.(Р.Юсупов. М.ж., 2013, 15 февр.). Академик ясаган мондый нәтиҗәнең фәнни-популяр сөйләмне дә читләтеп үтмәвен, үзебезнең күзәтү-анализларыбызга таянып икърар итеп, моңа нык борчылуыбызны белдерми кала алмыйбыз.

Инде гомумиләштеребрәк әйтергә кирәк булса, популярлык төшенчәсе ул чыннан да бу терминның асылын тәшкил иткән халыкчанлык мәгънәсенә туры килә бугай. Чыннан да популяр итеп тик бүген халык куллана торган телнең барлык тәэсир чара, мөмкинлекләрен гамәлгә җигеп, шуларның нечкә кушылуыннан-синтезыннан бик оста файдаланып кына фикереңне белдереп, әйтеп-язып була. Ә моңа гомерең буе тырышып иҗат итеп, тәҗрибә туплап кына ирешәсең.

Хәзерге татар матбугатында сүзләр язылышында яңа күренешләр

Г.М.Сөнгатов,
КФУ доценты, филология фәннәре кандидаты

XX гасырның соңгы дистә елларында җәмгыятьтә килеп чыккан үзгәрешләргә бәйле рәвештә, татар теленең төрле катламнарында һәм тел берәмлекләренең кулланылышында шактый үзгәрешләр барлыкка килде. Яңа үзенчәлекләр тууга телнең хәрәкәтчән күренеш булуы, аның стиль төрлелеге кебек факторлар да тәэсир итте.

Мәгълүм ки, хәзер гамәлдә йөрүче кирилл алфавиты 1939 елда кабул ителә, бердәйләштерелгән орфография 1941 елда расланган. Шул вакыттан алып, узган гасырның 80 еллар азагына кадәр язылышта тотрыклылык саклана, вариантлылык хасил иткән очраклардан берничә төрне генә билгеләп китәргә мөмкин. Болар арасыннан иң киң таралганнары – исем-фамилияләр язылышындагы төрлелек (**Рафаэль – Рафаил**, **Резеда – Резедә - Ризидә** h.б.), паронимнар язылышы (**аз-әз, акрын - әкрен** h.б.), алынма сүзләр язылышындагы төрлелек (**самовар – самавыр**, **инкарь – инкяр** h.б.). 80 еллар ахыры - 90 еллар башында исә матбугат телендә төрлелек тудырган очраклар шактый артты. Җәмгыятьтә демократия, хәбәрдәрлек туу, яңалыклар кертергә омтылу белән бергә, традицияләрне бозу, күнегелгән кагыйдәләрне санга сукмый башлау да, билгеле, зур роль уйнады. Журналистлар иҗатында һәм төрле катлам укучылар язмаларында сүзләр язылышына караган тенденцияләрне билгеләп китик.

Кыйтга, дәүләт, республика исемнәрен төрлечә язу киң таралды: **Европа – Ауропа**, **Аурупа**; **Россия – Русия**, **Рәсәй**; **Казахстан – Казакъстан –**

Казагыстан; **Палестина – Фәләстин – Фәләстыйн; Мари Республикасы – Мари Эль, Мари иле** h.б. Бу төркемдә вариантлар очрау белән бергә, аерым басмаларның даими языльшны беркетү юлын сайлаганын да искәртергә кирәк. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» - **Европа** языльшына өстенлек бирә. «Мәдәни җомга» – **Ауропа - Аурупа** языльшларын куллана; «Ватаным Татарстан»да **Казакъстан** очрый, «Татарстан яшьләре» **Казахстан** языльшын гына файдалана h.б.

Шәһәр, район үзәкләре исемнәре языльшындагы вариантлылык: **Кама Тамагы**, **Балык Бистәсе** кебек языльшлар совет чорында да кулланылса, **Яшел Үзән** дип язу 90 елларда гына ныклап беректе. Әлеге төркемгә караган иң зур үзенчәлек исә - атамаларны татарчалаштырып язуга йөз тоту: **Ижевск – Ижау**, **Ульяновск –Ульян**, **Саратов – Сарытау** h.б.

Алынма сүзләрне татарчалаштыру күренеше. Бу төркемдә иң зур урынны рус сүзләрен һәм рус теле аша кергән алынмаларны гади сөйләмдәгечә куллану күренеше алып тора. Мәсәлән: **чүт** кенә арттырдым («КН», 2011, №3,), **крәстиән** хуҗалыклары («МҖ», 2007, 30 март), **кәҗүнни** йорт көтә («ВТ», 2008, 3 июль) h.б. Әлеге тармакта шулай ук Европа телләреннән рус теле аша үтеп кергән алынмаларны төрле дәрәҗәдә – яки тулаем, яки аерым иҗекләрен яраклаштырып язу да күзәтелә. Мәсәлән: **Кампитр** һәм интернет... («МҖ», 2011, 25 февр.), **сәвит** халкы («ТЯ», 2011, 1 февр.), **гүләйт** итте («А-к», 2009, 10 дек.) h.б.

Әйтергә кирәк, мондый күренешнең башлангычлары гарәп язуы чорында ук салынып, латин алфавитын кулланганда шактый көчәйгән иде. Кирилл офографиясе исә европа алынмаларын рус телендәгечә нигезләде: бер төрле сүзләрне генә (**карават, самавыр, кәтлит** h.б.) татарчалаштыру норма төсе алды. XX гасыр ахырында исә публицистика телендә бу тенденция киң колач җәйде.

Алынмаларны язуда төрлелек гарәп-фарсы сүзләрендә дә шактый очрый: бу **мөхиткә** яраклашу... («ШК», 2005, 17 сент.); татар **мохитендә**…(«ВТ», 2008, 17 окт.), **табипларга** ышанычым бетте («ШК», 2008, 7 ноябрь), **табиб** кебек кирәкле һөнәр («ТЯ», 2008, 4 март) h.б.

Диалект, гади сөйләм үзенчәлекләрен матбугат телендә чагылдыру активлашты. Шундыйлардан **й (я, ю, е)** урынына **җ** хәрефен язу, аваз яки иҗек өстәү һәм, киресенчә, кыскарту кебек очракларның шактый күп күренүен билгеләргә мөмкин. Кайбер мисаллар: ярты Русия **җүләрләр** йортында булыр иде («ТЯ», 2009, 4 апр.), Нәсиб абыйның **җон** бөртеге дә селкенми («ТЯ», 2010, 18 дек.), **бәлкем**, өлкән буын арасыннан табылыр («ВТ», 2011, 2 март), 2004 елдан бүгенгә **тиклем** («ВТ», 2011, 12 апр.) h.б.

Хәзерге матбугат телендә орфографиянең экономия принцибына ныграк таяну омтылышы сизелә. Бу, башлыча, кыскартылма сүзләрне актив куллануда чагыла. Аерым очраклардан **нче** кисәкчәсенең кулланылышын билгеләп үтәргә кирәк. Аның языльшы бик чикләнде, тәртип саннарын язганда ул кулланылмый диярлек, шулай да кайбер язмаларда элеккечә куллану очрый.

Мәсәлән: 19 **нчы** гасырда («ТЯ», 2013, 28 сент.), 28 **нче** маддә («ИМ», 2013, 18 гыйнв.), 1990 **нчы** елда («БГ», 2013, 13 ноябрь) h.б.

Соңгы дистә еллар татар матбугаты телендә **я** теркәгечен ике хәреф белән - **йә** язылышында күрсәтүгә өстенлек бирелә. Мәсәлән: төп эшне **йә** бик иртә, **йә** бик кичке якта башкарабыз («ШК», 2009, 27 март), **йә** үзе җинаять кыла, **йә** аның объектына әверелә («ШК», 2009, 27 март) h.б.

Төрлелек кайбер төр алынма сүзләргә кушымчалар ялганганда да үзен сиздерә. Мәсәлән, гарәп теленнән кергән **әдәбият**, **нәшрият** сүзләренә традицион булган калын кушымча ялгау белән бергә, нечкә вариантны өстәү күзәтелә: үзебезнең **әдәбиятне** үзебез баетырга тиешбез («БГ», 2007, 6 гыйнв.), татар теле һәм **әдәбиятен** укыта («Й-з», 2008, 8 окт.), Татарстан китап **нәшрияте** («МҖ», 2006, 8 дек.) h.б. Кушымчалар язылышындагы вариантлылык бер үк шәхеснең исем-фамилиясен язганда да күзәтелә. Мәсәлән: **Анастасияга** күзләрен кыса-кыса; **Анастасияне** сәхнәдән дә тиз генә төшерергә теләмәделәр («КН», 2008, №41 – бер үк язмада ике төрле язылыш); **М.Ш.Шәймиевның** дусты («БГ», 2011, 19 гыйнв.), Минтимер **Шәймиевкә** («БГ», 2008, 29 окт.) h.б.

Татар басмаларының телен тикшерү күрсәткәнчә, соңгы дистә елларда язылышта сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килгән. Аларның күбесе, электән дәвам иткән язылыш нормалары белән керешеп, төрлелек, шактый чуарлык тудыра. Әлеге хәл татар орфографиясен яңарту, хәзерге әдәби телебездәге үзгәрешләрне исәпкә алып, фәнни нигездә заманча камилләштерү кирәклеген күрсәтә.

Чыганаклар

«А-к» – «Акчарлак»,
«БГ» – «Безнең гәҗит»,
«ВТ» - «Ватаным Татарстан»,
«ИМ» – «Ирек мәйданы»,
«Й-з» – «Йолдыз» (Апас р-ны),
«КН» – «Кәеф ничек»,
«МҖ» - «Мәдәни җомга»,
«ШК» - «Шәһри Казан».

Произношение и правописание русско-европейских заимствований в современных татарских СМИ

Г.М.Сунгатов, доцент КФУ,
кандидат филологических наук

Взаимодействие того или иного языка с другими языками, наряду с его внутренней структурой и закономерностями, является одним из важнейших факторов его эволюции. Известно, что в каждом языке есть определенное

количество слов, вошедших из других языков. Носителями языка заимствования воспринимаются и воспроизводятся согласно собственным артикулярно-акустическим навыкам и особенностям. Изменению подвергаются не только звуковые единицы, но и отношения между ними, т.е. взаимосвязь, которая называется функциональным аспектом фонетических процессов [1, 8-14].

Огромное количество арабо-персидиских заимствований в татарский язык вошло в связи с принятием ислама, т.е. начиная с X века. Языковые контакты татарского и русского языков также играли определенную роль в истории развития этих языков, в частности в изменении лексического состава. В татарском языке функционируют исконно русские слова, употребляемые с изменением их фонетического облика, иногда и грамматической структуры [2, 148]. Основная часть из них относится к общеупотребительной лексике. Например, **арыш (рожь), камыт (хомут), өстәл (стол), эскерт (скирда)** и т.д.

Другая группа заимствований связана с общественно-политическими событиями XX века: начиная с 20-х годов прошлого столетия через русский язык проникли сотни общественно-политических, научных терминов и общеупотребительных слов из европейских языков. Причем эти заимствования в основном произносились как в русском языке, орфографирование данной группы лексики осуществлялось также по правилам русского языка [2, 149].

Если взглянуть на общую тенденцию развития мировых языков, то можно увидеть, что слова, вошедшие из других языков, усваиваются по нормам не языка-источника, а языка, принявшего иноязычную лексику. Например, в русском языке слова латинского, греческого, английского, немецкого и другого происхождения в большинстве случаев употребляются согласно фонетическим и морфологическим закономерностям русского языка. В период своего развития русский язык не принял ни одну иноязычную фонему. Как уже отмечали, в татарский язык и в другие тюркские языки бывшего Союза европейские слова вошли по нормам русского языка, что привело к проникновению несколько гласных и согласных фонем иноязычного происхождения [3, с. 4].

Таким образом, приходится констатировать, что в современном татарском литературном языке сосуществуют три фонологические подсистемы: исконно тюркские слова с типичными для татарского языка фонемами; группа слов, где употребляются нетипичные для татарского языка фонемы из арабского и персидского языков; европейские слова, усвоенные по произносительным нормам русского языка.

Именно по этой причине очень трудно составить единые орфоэпические и орфографические правила. В настоящее время существуют разные мнения по вопросам произношения и графического оформления данной группы заимствований в татарском языке. Первый подход заключается в том, чтобы произносить и писать заимствованные слова как в русском языке, т.е. продолжать традиции советского периода: **импичмент, джакузи, дефолт, инновация** и т.д.

Второй подход – заменять их когда-то употребляемыми или вновь вошедшими арабско-персидскими словами, например: **республика - җөмһүрият**, **культура - мәдәният**, **инженер - мөһәндис**, **класс - сыйныф** т.д. В этом направлении активно работает периодическая печать. Эта тенденция во многом объясняется тем, что арабско-персидские заимствования в большинстве случаев легче усваивались по произносительным нормам татарского языка.

Еще один подход сводится к тому, чтобы активизировать работу по изменению фонетического облика слов и их ассимиляцию по примеру таких заимствований, как **кәмпитр** – **компьютер**, **фатир** – **квартира**, **нимес** – **немец**, **гәзит** – **газета** и т.д. – только с татарскими фонемами.

И, наконец, для избавления от чрезмерно большого количества иноязычных слов образовать новые слова, термины по словообразовательным моделям татарского языка. В татарском языке существует около ста словообразовательных аффиксов, большинство из которых в течение столетий вообще не использовалось или мало применялось в словообразовательном процессе. В этом направлении примером может служить родственный турецкий язык, другие тюркские языки. В Турции в 20–е годы XX века началось вытеснение арабских слов и лингвисты на научной основе, целенаправленно приступили к образованию новых слов: вместо арабского **мәктәп** (школа) - **окул** от основы **уку** (читать); **бакан** (министр) от общетюркского **багу** (смотреть); **башбакан** (главный министр) в значении **премьер-министр**.

Рассмотрим на конкретных примерах подробнее одну из особенностей употребления заимствованных слов в последние годы в татарских СМИ, а именно – их употребление в русских и татарских вариантах. Так, вариативным является произношение и написание названия первого месяца года – январь, которое и в словарях указывается в двух вариантах [5].

Гыйнвар ахырында тагын 70 гаилә фатирлы булачак. (Х, 2011, 6 гыйнв.).

Январь аенда Казанның Калининский бистәсендә яшәүче 67 яшьлек Попенкова Алевтинаның үле гәүдәсе табылган. (А, 2008, 24 апр.).

Необходимо отметить, что начиная с конца 80-х годов XX века в СМИ преобладает употребление ассимилированного варианта **гыйнвар**.

Многовариантность в употреблении вызвало слово **больница**. В языке радио и телепередач сохраняется и употребление как в языке – источнике – **больница**, и ассимилированный вариант – **бүлнис**, но в большинстве случаев это слово заменяется арабско-персидскими заимствованиями **сырхауханә**, **хастаханә**, **дәваханә.**

– Уколны кайда кадыйлар?

– **Бүлнистә**. (МТ, 2010, 10 дек.).

Больницадан чыккач ук, сәхнәгә әйләнеп кайтырга уйлый (К.Н., 2008, № 2).

Некоторые слова вариативно произносятся в одном и том же речевом тексте. Например, в речи кулинара Резеды Хусаиновой слово **кукуруза** произносилось и в полном, и в сокращенном варианте:

Ул – **кукуруз** белән кыздырылган балык кәтлите.

Аннан **кукурузаны** салып чыгабыз (Х.И., 2010, 14 дек.).

Татарский вариант слова **дискотека** – **дискәтүк** впервые замечалось нами в журнале «Идел».

Безнең татар **дискәтүкләре** булса да, интелектуаль яшьләргә аралашырлык татар клубы юк. (И., 2004, №2).

В последние годы этот вариант заметно активизировался. Например:

Һәр чәршәмбе **дискәтүкләр** үтәчәк (Х.И., 2010, 18 окт. участница).

«Яшьләр тукталышы» **дискәтүге** (Р., 2010, дек.).

Примечательно, в одной беседе ведущая произносит это слово в полном варианте, а ее собеседник употребляет татарский вариант:

Ведущая: Татарча **дискотекаларга** яшьләр яңалык алып киләме?

Собеседник: **Дискәтүккә** килгән кешедән тәкъдим көтеп утыра алмыйбыз инде. (Х.И., 2010, 14 дек.).

Ассимилированные варианты встречаются и в группе слов, характерных для научного и публицистического стилей татарского языка. Например:

Профессор: **Прафисыр** аңа борылып та карамады (И., 2007, №3).

Академик: «**Әкәдемикләр** әкиятләрен дөрескә чыгару өчен беренче чиратта татарның бетүе фарызлыгы аңлашылса кирәк (Т.Я., 2008, 15 гыйнв.).

Компьютер: Портатив **кампитр** – бик уңайлы нәрсә (М.Ж., 2007, 27 апр.)

Оптимизация: Ә узган атнада директорлар советында заводның кризис кичерүе игълан ителде һәм эшчеләрне «**уптымизацияләргә**» кирәк дип таптылар (К.К., 2008, 21 ноябрь).

В языке современных СМИ часто встречаются ассимилированное произношение и написание модальных слов, вошедших из русского языка. В основном они характерны для просторечия. Так, на канале ТНВ такие слова были замечаны в передачах, где участвуют представители разных слоев населения. Например:

Еще: Юкә балы булса **ишшу** әйбәт (Х.М., 2010, 13 дек., участница).

Тоже: Ул **тужы** бик кирәкле әйбер (К.К, 2010, 13 окт., участник).

На страницах периодических изданий варианты русских слов, характерные для просторечия, встречаются довольно часто.

Например:

Зря: **Зрәгә** генә укытучы булып китмәдең инде син! (А., 2008, 13 ноябрь)

Почти: Ул бит **пачти** син инде! (И., 2007, №3).

Неужели: **Нүжәли** мондый «фигура» белән уйнап була. (И., 2007, №2).

Пустяк: ...**Пүчтәк** кенә шәхесләребезне зурга саныйбыз, шуңа күнәбез. (Т.Я., 2008, 12 апр.)

Вес таки: Тулы ук түгел идең син **чүтеки** (Т.Я., 2008, 15 ноябрь)

В последние годы эти проблемы не раз обсуждались в татарской периодической печати, в научных кругах предпринимались попытки совершенствования орфографии татарского языка. Так как все сложные случаи связаны в основном с правописанием заимствованных слов, по нашему

мнению, сначала все-таки надо решить вопросы произношения, ведь орфоэпия по отношению к орфографии является первичной. Практика создания новой орфографии на латинице показывает, что даже переход на эту графику не решает проблем орфографирования иноязычных слов без должного обоснования их звукового оформления, т.е. орфоэпии.

Источники

Х. – «Хәбәрләр», информационная программа на татарском языке. Канал ТНВ.

М.Т. – «Мунча ташы». Канал ТНВ.

Х.И. – «Хәерле иртә», утренняя передача на татарском языке. Канал ТНВ.

Р. – Реклама. Канал ТНВ.

Х.М. – «Халкым–минем», передача на татарском языке.Канал ТНВ.

К.К. – «Кара–каршы», передача на татарском языке. Канал ТНВ.

К.Н. – «Кәеф ничек», газета на татарском языке.

А. – «Акчарлак», газета на татарском языке.

И. – «Идел», молодежный журнал на татарском языке.

Т.Я. – «Татарстан яшьләре», молодежная газета на татарском языке.

М.Җ. – «Мәдәни җомга», газета на татарском языке.

Литература

1. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. Казан: Тат. кит. нәшр., 2003. 223 б.

2. Татар грамматикасы. Т.I. М.: Инсан, Казан: Фикер, 1998. 512 б.

3. Хәзерге татар әдәбияты. Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. 297 б.

4. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе. Казан: Мәгариф, 2009. 239 б.

5. Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфографик сүзлеге. Казан: Яңалиф, 2004. 192 б.

Белем һәм тәрбия чарасы буларак очерк жанры

И.Ф.Фәттахов, КФУ доценты,
филология фәннәре кандидаты

Гази Кашшаф җаваплы редактор булып эшләгән 1950-1958 елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында очерк жанры да көчәйгән, чөнки бу еллар «коммунизмның бөек төзелешләре» чоры дип тарихка кереп калган. Сугыштан соңгы җимерек халык хуҗалыгын 1949 елда торгызып бетергәч, туган илебездә коммунизм төзү игълан ителә. Шуңа күрә партия матбугаттан зур төзелешләр, хезмәт алдынгылары һәм батырлары хакында күбрәк язуны, сөйләүне таләп иткән. Нәтиҗәдә язучы-публицистлар очерк

жанрында да актив иҗат иткәннәр. Белем һәм тәрбия чарасы буларак очерк жанры бу эшкә шактый саллы өлеш керткән.

1950 елда журналда барысы унсигез очерк басылган. Бу жанрга җанлы иҗади якын килүнең якты мисалы булып Г.Кашшаф үзе тора. «Ватан данын җырлаучы» очеркында («Совет әдәбияты » (алга таба – С.ә.), 1950, № 2, 47–53 б.) автор Яшел Үзән сайлау округыннан икенче тапкыр СССР Югары Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән шагыйрь Әхмәт Ерикәйнең очерк-портретын тудырган. Ул аның «гади генә биографиясе» белән укучыны таныштырып, Ә.Ерикәйнең тормыш һәм иҗат юлын тулы итеп тасвирлаган. Тәнкыйтьче Г.Кашшаф шагыйрьнең шигырь-поэмаларын тирәнтен анализлап, уңышлары белән янәшә йомшак якларын да (кайбер кабатланулар, башка очракларда образларның схематик эшләнүе) күрсәткән, «без алардан күз йомарга уйламыйбыз», – дип язган.

Гамир Насрый да бу жанрда нәтиҗәле иҗат иткән, мәсәлән, 1950 елда аның өч очеркы басылып чыккан. «Атаклы машинист» очеркында (С.ә., 1950. № 2, 54–59 б.) автор Юдино паровоз депосының карт, тәҗрибәле машинисты (43 еллык стажлы) Крылов Митрофан Григорьевич турында сөйли. Ул бөтен Советлар Союзына билгеле булган, чөнки 1939 елда Ленин орденын алган, ә сугышта «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнгән. Чистай сәгать заводы эшчеләре – сайлаучылар – М.Г.Крыловны икенче тапкыр СССР Югары Советы депутатлыгына кандидат итеп күрсәткәннәр.

Гамир Насрыйның һәм Сабир Бәхтияровның «Җитен комбинатында» очеркы (С.Ә., 1950, № 3, 36–49 б.) Казан җитен комбинатының атаклы тукучысы, 1950 елның 12 мартында СССР Югары Советына депутат итеп сайланган Лаврентьева Наталья Ивановна портретын тудырган.

Г.Насрыйның өченче очеркында (Талкыш кырлары буйлап // С.ә., 1950. №12, 43–64 б.) ТАССРның Чистай районы Татар Талкышы авылы игенчеләренең хезмәт уңышлары турында сүз бара.

Гариф Галиев арышның «Казан 5+6» исемле яңа сортын үстергән селекционер, Сталин бүләге иясе Хәдичә Байчурова турында очерк язган (С.ә., 1950, № 3, 50–58 б.).

Мондый эчтәлектәге очерклар хезмәт тәрбиясе чарасы булып санала. Алар укучы күңелендә хезмәтне ярату, хезмәт кешесенә хөрмәт хисләре тәрбияләгән.

1951 елда исә журнал битләрендә ун очерк дөнья күргән. Редакция рус очеркчыларына да игътибар иткән. Мәсәлән, Борис Орешниковның «Совет депутаты» очеркы (С.ә., 1951, № 1, 84-89 б.) утыз ел заводта эшләгән эшче, Казан шәһәр Советы депутаты Гарипов Кәрим Гариф улы турында. Ул инде егерме биш ел дәвамында Казанның район һәм шәһәр Советларына депутат итеп сайланган. Б.Орешников совет депутаты дигән мактаулы исемгә ирешкән алдынгы татар эшчесенең портретын тудырган. Бу – ул чакта милләтләрне бүлмәүнең, бер-берсенә каршы куймауның матур күренеше. Кызганыч, хәзерге татар публицистикасында мондый очерклар язылмый.

Очеркны укыгач, шундый нәтиҗә ясадык: Советлар вакытында депутат итеп гади халык вәкилләре сайланган булса, бүген «череп» баеган байларны – олигархларны, бизнес-структура президентларын, дәүләт корпорациясе җитәкчеләрен сайлаталар. Элек Кәрим Гарипов кебек гади кешеләр кадер-хөрмәттә яшәгән, хезмәт батырларын дан-дәрәҗәгә күмгәннәр, хезмәт кешесен депутат итеп сайлаганнар. Хәзерге заманда беренче чиратта акчалы кеше мактауга лаек һәм депутат була. Кайда гаделлек, тигезлек соң?

Вл.Кузьмин «Авыл көтепханәсендә» очеркында (С.ә., 1951, № 4, 81–90 б.) Татарстанның Буа районы Толымбай авылы көтепханәчесе Рәмзия Тажиеваның тырышып эшләвен бик җентекле чагылдырган.

Зәки Нуринең «Сталинградтан төньяктарак (Юл язмалары)» очеркында (С.ә., 1951, № 9, 109-114 б.) Сталинград ГЭСын төзү тәфсилле чагылган. З.Нури әлеге гигантны коруда турыдан-туры катнашкан кеше. Ә шул ук авторның «Яшел фабрика мастерлары» очеркында (С.ә., 1951, №10, 82-88 б.) ТАССРның Тәтеш районындагы «Азат» колхозының хәтта 250 гектар мәйданны биләп торган зур питомнигы хакында сөйләнелә. Зәки Нури үзе шунда барып, питомник җитәкчесе белән сөйләшкән, аның булдыклылыгын тасвир кылган.

Сафа Сабировның «Коммунизм маягы» очеркы (С.ә., 1951, №2, 82-97 б.) Куйбышев ГРЭСын төзүгә багышланган. Әйе, Куйбышев гидроузелын сала башлау, шул заман терминологиясе белән әйткәндә, коммунизм маякларының берсе саналган. Ул үзенең коточкыч зурлыгы, төзелеш масштабы ягыннан коммунизмның бөек төзелеше дип аталган. Автор бу төзелештә ихлас күңелдән теләп катнашкан ирекле хезмәт кешеләрен – экскаваторчыларны, бульдозерларчыларны тасвирлаган.

Ләкин инде бүген без чын хакыйкатне беләбез: коммунизмның бөек төзелешләрендә ГУЛАГ тоткыннары да катнашкан, ягъни Советлар бушлай кол хезмәтен (рабсила) кулланган. Сталин шулай кушкан. Җимерелгән совет икътисадын торгызу өчен сугыштан соң ГУЛАГтагы 9 млн. тоткын эшләгән, алар җитештергән продукция илебездәге эчке тулаем җыемның (ВВП) 10 %ын тәшкил иткән. (Бу хакта «5» телеканалының «Середина века: 1956 год» тапшыруы 2013 елның 23 маенда күрсәтте. Эфир вакыты: 6 сәг. – 7 сәг.). 50 еллар башында исә ул турыда хәтта уйларга да ярамаган бит.

Самат Шакирның «Атказанган укытучы» очеркында (С.ә., 1951, №11, 70-78 б.) Татарстанның Теләче районының Янсуар урта мәктәбе директоры, ТАССРның атказанган мөгаллиме (1946) Евдокия Сергеевнаның (фамилиясе нишләптер язылмаган) педагогик эшчәнлеге шул еллар пафосы белән яктыртылган.

Афзал Шамов очеркларыннан да кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин: алар гади тел белән, мавыктыргыч һәм уйландырырлык итеп язылган; бай фактик материалга ия. Мисал өчен, аның «Зөя буенда» дигән күләмле очеркыннан (С.ә., 1955, №9, 3-20 б.; №10, 9-25 б.) Килдураз (Ураз бабай), Лашчы (Лашчы исемле солдат) авылларына нигез салучылар турында уникаль мәгълүмат табарга мөмкин. Бу бит Сембер губернасының Буа өязе (хәзер Татарстанның Буа районы) татар авыллары килеп чыгышын өйрәнгәндә тарихи

кыйммәткә ия мәгълүмат. «Килдураз» сүзенең этимологиясе Ураз килде дигәнне аңлата. Чыннан да, әлеге авылга беренче булып Ураз бабай нигез салган. Авыл исемендә ул кайбер үзгәреш кичергән: Килде Ураз – Килдураз.

Моннан тыш, А.Шамов аграр мәсьәләләргә дә кагылган, аерым алганда, бу ике авылны үзенә берләштергән «Коммуна» колхозында терлекчелек һәм игенчелек торышы. Мисал өчен, ул «Коммуна»ның түбән җитештерү күрсәткечләрен Чуваш республикасының Вурнар районы Сталин исемендәге күрше колхозның югары җитештерүчәнлеге белән чагыштырган. Чувашлар кукуруз үстерү технологиясен яхшы үзләштереп, үз терлекләрен сыйфатлы азык – кукуруз силосы белән тәэмин иткәннәр икән. Моның белән автор КПСС ҮК гыйнвар пленумының (1955 ел) колхозларның экономик үсешенә юнәлтелгән карарларын тормышка ашыруның әһәмиятен ассызыклаган. Өстәмәсенә, публицист очеркның ахырында исеме аталмаган ниндидер китаптан кукуруз турында шактый озын өзек китергән.

Ш.Мөдәррис, Г.Ахуновның «Таудан тауга (Колхоз авылы турында язмалар)» очеркында да (С.ә., 1955, №11, 63-77 б.) илленче елларның беренче яртысындагы колхоз авылы тормышы ТАССРның Кукмара районының Тукай һәм Молотов исемендәге колхозлары мисалында тасвирланган. Авторлар бу хуҗалыкларның председательләре Вилдан Закиров һәм Барый Әхмәдиевнең эшен уңай бәяләп, гади колхозчыларның җанлы энтузиазмы, хезмәт уңышлары хакында тулы бер картина тудырганнар: төзелгән траншеяләр, силос, бәрәңге саклау өчен чокырлар; артезиан коелары; электро-, радиобаганалар; Ленин исем. колхоздан маршал Рокоссовскийның элекке шәхси повары Миңнегали Ярыев кебек авыл инженерлары кулы белән корылган электростанцияләр һәм радиочелтәр. Шул ук вакытта очеркчылар КПСС ҮКның сентябрь пленумы (1953 ел) карарларын гамәлгә кертү юлында ямьсез факт булган начар үстерелгән кукуруз кыры турында да язарга онытмаганнар.

Чыннан да, 1954-1958 елларда авылда зур үзгәрешләр күзәтелгән. Барлык яхшы күренешләр партиянең 1953 елгы сентябрь пленумыннан башланган. Күпләр туган якларына кире кайткан, агачтан яңа йортлар салган... Авыл үз тракторчыларын, комбайнчыларын, механикларын кайтырга чакырган. Озак уйлап тормыйча кайтканнар. Күп туйлар уздырылган, бу шулай ук яхшы күренеш саналган. Чынлап та, авыл кешеләре матур киләчәккә ышанып яши башлаганнар. Хрущёв аларны өметләндереп кенә калмаган, ә матди-техник яктан бик нык ярдәм иткән. Никита Сергеевич заманында авыл күрелмәгән күләмдә ярдәм алган.

Рухи дөньяда да сизелерлек үзгәреш – үз халкыңның үткәненә йөз белән борылу булган. Зыялылар үз бабайларының тарихы белән тирәнрәк кызыксына башлаган. Партиянең ХХ съездыннан соң әдәби мираска игътибар арткан. Мәсәлән, С.Хәким: хәзер мин лирик чигенешләрне Габделҗаббар Кандалыйга кадәр, хәтта Кол Галигә хәтле («Йосыф вә Зөләйха» атаклы поэмасының авторы) ясый алам, әдәби пространствода иркен маневр ясыйм, дигән (Хәким С. Безнең көннәр поэзиясе // С.ә., 1958, № 7.). Бу хәл гаҗәп булган! Ә бит 1953 елга кадәр бары тик бер Тукай белән чикләнгәннәр.

Лениногорск каласын, гомумән, нефтьчеләр темасын тулырак, җентеклерәк чагылдырган Г.Кашшафның «Яңа шәһәрдә» исемле очеркы журналның 1958 елгы 1 нче санында (47-58 б.) басылган. Очеркның «Соңгы күренешләр...» дигән беренче бүлеген автор, Н.В.Гоголь («Үле җаннар»), Г.Тукай («Пар ат»), Ф.Кәрими («Истамбулдан мәктүпләр») кебек, юлны сурәтләүдән башлап җибәргән. Ләкин бер аерманы искәртергә кирәк дип саныйбыз: рус-татар әдипләре чорында хәрәкәт итү чарасы җигүле ат булса, Кашшаф заманында инде «Победа» машинасы: *«Машина шәп, юл тигез, иптәшем күп сүзле түгел... Без Казаннан караңгыда ук чыгып киттек.*

Юлдашым Камил, бүген мине таң тишегеннән уятып, «Победа»сына утыртып алып китте. Ул шофёр янында, мин түрдә. Бу юлдан минем элек тә узганым бар, ләкин көн артлы көн туа, һәр көн яңалык алып килә, һәм без, шул яңалыкларга карап, уйланып барабыз. Ара-тирә Камил:

– Күрәсеңме? – дип сорап куя. Сүзне озынга сузмый гына мин:

– Күрәм, – дим. Күргән нәрсәбез я яңа салынган күпер, яки яңа йорт була. Шуннан соң без бик озак сөйләшми барабыз. Менә таң яктылыгы белән бергә уң якта сөтле рәшә күтәрелгән кебек була. Ныклабрак карагач, ераклта-ераклта күксел тау шәүләсе сузылып киткәнен аера башлыйсың. Әйе, ул Иделнең уң як яры, ничек җәелгән Идел, ә... (Әйтеп бетермәүгә мисал бу. – Г.Ф.)

– Күрәсеңме? – ди Камил, яңадан миңа борылып.

– Күрәм, – дим мин һәм тагын үз уйларыма чумам.» (47 б.)

Әйтеп бетермәүгә тагын берничә мисал: *«Машина дуңгыз, сарык көтүен икегә ярып, җайлап кына алга тәгәри...»* (47 б.)

«Миңа атның яхшысын, акыллысын бирделәр, эшне чыбыркыга җибәрми...» (49 б.)

Чагыштыруга күп мисаллар таптык, мәсәлән: *«Әллә шагыйрьнең романтик пафослары миңа бик нык йоккан иде, әллә инде юлдашым шундый туры килде, мин инде үземне шигъри болытлар өстеннән йөзеп барган кебек сизә идем.»* (47 б.)

«Оядан чыгып йөгергән чебешләр кебек, паромдагы машиналар берәм-берәм чыгып, пырылдап тауга очтылар, аннан соң паромга ярдагы машиналар төялде. Бик күп төялделәр... Һәм без Чулманның икенче ягына юл алдык.» (48 б.)

«Нинаять, без бер сәгать 20 минуттан соң Мурзиха пристанена килеп туктыйбыз! Менә ул хәзер борынгы Чулманның киңлеге ничек!» (48 б.)

«Кичә йолдызлар аеруча күңелле җемелдиләр һәм, җирнең матурлыгына сокланган кебек, күзләрен киң итеп ачканнар иде. Ә менә бүген инә күзе чаклы бер ут елтырасынчы!

Еракка карадыңни, күккә сузылдыңни, җиргә текәлдеңни! Нични күренми, әйтерсең, менә шушы караңгылык эченнән шуышасың...» (49 б.)

Антитезага да мисал бар: *«Менә, авыл төне... Ләкин элекке җәһәннәм базы караңгылыгы бөрки торган авыллар инде мәңгелеккә артта калган. Аны хәзер шомлы әкият итеп кенә сөйләргә мөмкин.*

Төпсез караңгылык һәм мәңгелек ут...» (49 б.)

Автор синтаксик параллелизм да кулланган: *«Әкият дигәннән минем хәтергә икенче бер легенда килеп төште. Һәм ул бүгенге Лениногорскига да, Ютазыга да, Баулыга да бик нык бәйле шикелле.*

Борынгы дини китапларда мең ел янган уттан бер кош яратылуы турында әкият бар...

Мең елдан соң нинди кош яралыр, ләкин Тимәш тавы битендә инде 1948 елдан бирле ажгырып ут янып ята. Татарстанда беренче тапкыр девон нефте менә шушы вышкадан бәреп чыккан. Ул әле дә нефть ургылдырып тора, насоска күчәргә исәбе дә юк. Аның газын 1948 елда кабызганнар, ул зур факел булган. Хәзер дә ул бик көчле һәм ажгырып ут янып ята. Бу утны җил-давыл да, яңгыр сулары да, кар өермәләре дә сүндерә алмый... Ләкин мең елдан соң аңардан кош яралырмы, юкмы, анысын 2948 елда яшәүчеләр күрерләр, ә менә хәзер ул коштан кыйммәтлерәк нәрсә бирә! Анда көн-төн известь яндыралар. Безнең төзелешләргә известь шулкадәр кирәк, аны шул факелда яндырып торалар, алып китеп торалар...» (50 б.)

«Мин «Нефтяник» гостиницасына туктадым. Икенче каттагы иркен генә бүлмәнең тәрәзәләре көньякка караганнар, аннан шәһәрнең үзәге – горком күренеп тора. ...

Шулай да бик кызык төзелә икән бу шәһәр. Башка шәһәрләр кебек, ул үзәгеннән төзелә башламаган, бер як кырыйдан төзелеп киткән. Хәзер исә шәһәрнең үзәге әрем үсеп утыра торган, казлар, кәҗәләр көтүләп йөри торган шәрә ялан. Дөрес, анда шәһәр партия комитетының мәһабәт йорты калкып тора, аның тирәсендә әле күпереп, купшыланып китәргә өлгермәгән бакчасы да бар. Ләкин шулай да ул ялгыз...» (51 б.)

Лениногорск кебек йөзләгән яңа шәһәрләр төзелгән ул заманда. Бу зур күрсәткеч илнең икътисады яхшы эшләгәнне, эшсезлек булмаганны аңлата... Мисал өчен: *«Мәктәпләр сигезгә җиткән. Алты урта мәктәп бар, 1958 елда яңадан ике мәктәп өлгерә. Шәһәрдә хәзер төзүчеләр мәктәбе, техника училищесы, нефть техникумы (кичке бүлек), нефть институтының кичке бүлек филиалы, курсларның өч комбинаты. Шәһәрдә ике катлы зур мунча, беренче разрядлы мода ательесы һ.б. бар.*

1959 елда шәһәрнең үз телевизор үзәге төзелергә тиеш. Әле биш-алты ел элек кенә салына башлаган шәһәр хәзер шундый үскән, шундый җәелгән. Син аны җәүләп түгел, машинага утырып та барлык урамнарын бер генә көндә әйләнеп чыга алмассың...» (53 б.)

Ләкин Гази Кашшаф бу очеркында чын татар кешесенең җанын «ашый», йөрәген борчый торган туган тел, татар мәктәбе булмау мәсьәсәләсен бик кыю яктырткан. Ул безгә чынбарлыктагы контрастны шундый оста итеп тасвирлап биргән ки, аның кыюлыгына сокланырлык. Авылдан нефть чыгарырга дип Лениногорскига эшкә күчеп килгән татар яшьләре туган телдә сөйләшкән, ә ана телендә сөйләшмәүче яки сөйләшә белмәүче, яки сөйләшергә оялучы һәм сораганына татарча җавап бирмәүче урыслашкан «татар» түрәләрен – партиянең шәһәр һәм район комитеты секретарьларын, нефть идарәсе җитәкчеләрен – күреп, публицистның йөрәге әрнегән, ул атаклы журнал аша

бөтен татар халкына чаң суккан. Менә бер өзек укып китик: *«...Тик безнең икенче нәрсәгә исебез китте. Яңа ачылган алты мәктәпнең берсе дә татар мәктәбе түгел диделәр безгә. Шуннан соң мин шәһәр халкын күзәтебрәк йөри башладым: урам тулы татар, кайда гына барып керсәң дә татарча сөйләшәләр. Нефть тирә-як татар авылларыннан менә дигән батыр егетләрне, сылу кызларны үзенә чакырып китергән... һәм бу хәл кешеләрнең аралашуларына үзенчәлекле бер төс керткән. Горкомда, мәсәлән, минем белән татарча сөйләштеләр. Мин соңыннан гына ул сөйләшүче иптәшнең татар түгеллеген белдем. Ә менә шул ук горкомда секретарьларның берсе минем татарча соравыма русча җавап кайтарды. Горкомның икенче секретаре Фаварис Мирсаяф улы Тукаевның татарча сөйләшмәвенә нефть бораулаучы таза ирләр дә аптырыйлар икән.*

- Ул татармы соң? – дип сорадылар миннән. – Беркайчан да ул, буровойга килеп, татарча сөйләшкәне юк, ә әйтәсе сүзләр бар безнең...

Ничә еллар буенча аның җитәкчелеге астында эшләүче эшчеләр массасы секретарьның татармы, армы, русмы икәнен белмиләр, татарча эндәшсәң дә русча гына сөйләшә диләр. Шуңа күрә миңа Конституция нигезендә эш итүче Совет башкарма җитәкчесе Хәй Вилдановның да нефтьчеләр өчен бары тик рус телендә генә марш булдырырга янып йөрүе гаҗәпләндермәде. Алар инде бөек рус культурасын ахырынача чөмереп бетергәннәр, күрәсең, ана телендә массага якынаю, ана телендә аларны тәрбияләү безнең эшебез түгел инде ул, дип карыйлар булса кирәк. Алдагы елда тагын берничә яңа мәктәп өлгерер, алары да аның, бәлки, татарча укытмаслар...

Ихтыярсыз рәвештә В.И.Ленинның сүзләре искә төшә, ул рус булмаган халыкларның руслашкан вәкилләре милли мәсьәләне танымаска тырышулары өчен ачынып язган». (56 б.)

Бездә сорау туды: Г.Кашшафның җаваплы редактор вазыйфасыннан китүе шушы очеркка бәйле түгелме? КПССның Татар өлкә комитетының идеология бүлеге аңа карата чара күрмәгәнме? Бу сорау ачык кала.

Дөрес, безгә өлкә комитеты тарафыннан 1959 елда Г.Кашшафның Казан дәүләт университетына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә журналистика белгечлеге буенча читтән торып укучы студентларны укытырга җибәрелүе мәгълүм.

Очеркына Г.Кашшаф халык әдәбиятыннан җыр да кертеп җибәргән:

«Йорт салуның ние бар,
Мүклисе дә, чүклисе,
Кыз алуның ние бар,
Кочаклыйсы да йоклыйсы!»

Әлеге очеркта «Яшьлек җыр сорый» дигән бүлек бар. Бүлекнең исемен Г.Кашшаф афоризмы дип уйлыйбыз, мәсәлән: *«Яшьлек кайда да бер. Ул чәчәк ярата, романтикага бирелә, мәхәббәт белән исерә, уен-көлке белән мавыга. Яшьлек сөйгәне белән ялгыз гына калырга да тели, компания белән шаулашып җырларга һәм бөтерелеп биергә ашкынып тора.*

Шомырт төсле кара үткен күзләр ялт-йолт эзләнә башлый, кая юл тотарга икән? Парккамы, әллә танца мәйданынамы? Аның алсу йөзендә дәртлелек, шаянлык балкый, ул мәхәббәт ялкынына кызарган һәм шашынып ашкынуын чагылдыра. Көдрә чәчләр йомшак кына ап-ак муенны иркәлиләр, яхшы материядән тегелгән чәчәкле күлмәк, бөтен гәүдәнең нәфислегенә, җиңеллегенә тиң килгән, ә кыйммәтле босоножкалар кигән аяклар теләсә нинди вальска бөтерелеп китәргә торалар. Ул үзенең егетен көтә, шундый ук яшь һәм шундый ук таза егет әнә шул урамнан киң адымнар белән йөгерә-атлап монда килә. Сез бу кызны мәхәббәт белән исергән гимназистка дип уйламагыз. Юк, түгел. Ул без көндез күреп узган төзүче кызларның берсе». (56 б.)

Эндәш сүзләр дә очрады безгә: *«Чулман! Аның икенче як яры бөтенләй күренми, бәлки ул томан эченә йотылгандыр?»* (48 б.)

Инкарь җөмлә: *«Юк, ярны күрсәтми торган куе томан юк бүген.»* (48 б.)

Ритмик хәрәкәткә мондый мисал күреп алдык: *«Йөзләрчә чакрымнарга сузылган ясалма диңгезнең нәкъ безнең республикадагы иңе урыны белән 40 кмга җитә. Шул мәйдандагы су, дулкыннар күтәреп, ярларга, буага ташлана, ул ыргый, ярсый, ачулана, шомландыра, вакыт-вакыт күк белән тоташып, яшенле яңгырлар көче белән дә һөҗүм итеп карый.»* (48 б.)

Безнең күзәтүләргә караганда, 1950 – 1958 елларда журнал битләрендә Бөек Ватан сугышына (алга таба – БВС), аның батырларына багышланган очерклар юк диярлек. Шулай да берничә бар (Насрый Г. Атаклы машинист // С.ә., 1950, №2, 54-59 б.; Заботин И. Сталинград турында очерклар // С.ә., 1952, №1, 64-78 б.; Касыймов Э. Брест каһарманы // С.ә., 1958, №2, 55-65 б.).

Фикерли белүчеләрнең башында иң әүвәл ни өчен шулай дигән сорау туачак. Хәзер билгеле булганча, БВС беткәч, фашистлар әсирлегеннән Кызыл Армиянең 2 млн. солдаты Туган илгә кайтарылган. Ләкин шуның 400 меңгә якыны ГУЛАГка озатылган, ә 1,5 млн. совет солдаты хәрби хезмәтен тәмамлау өчен армиягә кире җибәрелгән («5» канал. «Середина века: 1956 год» телетапшыруы. 2013 елның 23 мае. 6 сәг. – 7 сәг.). Шуңа күрә дошман әсирлегенә төшкән, әмма аннан качарга тырышкан Пётр Гаврилов, берничә тапкыр качып та кабат тотылган Нәби Дәүли, Норвегия диңгезендәге яшерен утраудан дошман очкычына утырып кача алган Михаил Девятаев, башларын кистергән Муса Җәлил, Гайнан Кормаш, Габдулла Алиш кебек каһарманнар яки немец тоткынлыгыннан качып, җиде көн буе агач башында үгез койрыгы суырып утырган, аннары җиргә төшкәч, яңадан кулга алынып, карцерга – бөртек сибелгән салкын суга ыргытылган безнең туганыбыз Габделнәфыйк Шәрифуллин (1920–1995) шикелле солдатлар турында 1956 елга кадәр, гомумән, язарга ярамаган, ягъни Н.С.Хрущёв аларны аклатып, ГУЛАГтан ирекка чыгарттыргач яисә Совет Армиясеннән тыныч тормышка кайтаргач кына, шушындый батыр солдатларыбыз турында халыкка сөйләргә мөмкинлек туган. Шул рәвешле, Сталин төзеткән ГУЛАГ системасы СССР Югары Советы указы нигезендә 1956 елның октябрь аенда бөтенләй җимерелгән.

Безнең уйлавыбызча, «Совет әдәбияты» журналында сугыш геройлары турындагы очеркларның аз басылуы шушы сәяси сәбәпкә бәйле булган.

Эдуард Касыймовның «Брест каһарманы» очеркы төзелеше ягыннан да игътибарыбызны җәлеп итте, чөнки үзенчәлекле биш бүлеккә бүленгән, ә аларның һәркайсы зур әһәмияткә ия: 1. Кояш кыздырып байый; 2. Тыныч төн, дәһшәтле таң; 3. Ватан өчен! 4. Соңгы чиктә; 5.Уналты ел узгач...

Әлеге очеркта БВСның башы: 1941 елның 22 июне, Брест оборонасы, аның каһарманнарының батырлыгы, шул исәптән майор, Советлар Берлеге батыры Пётр Михайлович Гавриловның каһарманлыгы да сурәтләнгән.

Брест оборонасын саклаучылар 1956 елның җәендә, Брест оборонасының 15 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә уздырылган тантанадан соң, Брест ныгытмасына юл тотканнар. Брестта аның янына бер хатын-кыз килгән дә: «Синең хатының исән, ул Косово шәһәрендәге гарипләр йортында яши», – дигән. Аннары Пётр Михайлович аның белән поездга утырып, Югославиягә, Сербиягә киткән.

Шул рәвешле, уналты ел узгач кына, П.М.Гаврилов үзенең хатынын эзләп тапкан. Каһарманның хәләл җефете белән очрашуын Э.Касыймов менә ничек дулкынландыргыч итеп, эчкерсез хисләр белән сугарып тасвирлаган. Пётр Гаврилов белән хатыны Екатерина сөйләшкәнен шулкадәр җылы, оста сурәтләгән ки, әйтерсең лә, үзе тыңлап торган: *«Бу хәлдә янына керергә ярамас, каушаудан әллә нишләр», – дип әлеге хатынны алдан кертеп җибәрдем. «Бар, сөйләш, алдан әзерләп куй», – дидем. Үзем ишек төбендә калдым. Тегеләр сөйләшәләр. Мин Катямның сулкылдаган хәлсез тавышын ишетәм.*

– Хәл-әхвәл белешкәч, әлеге хатын һәлак булган ире турында:

– Беләсеңме, Катюша, минем ирем кайтты ич. Пленда булган, – диде.

– Шулаймы? Зур сөенечле икәнсең... Котлыйм, котлыйм, – ди, аннары уфтанып. – Минеке кайтмас инде, кайтмас, – диде аңа каршы минем хатын.

– Ә кайтса? Менә хәзер кайтып төшсә, нишләр идең?

– Белмим...

Алар берникадәр сүзсез тордылар. Аннары теге хатын:

– Катюша, ирең кайтты бит синең, – диде шатлыклы тавыш белән.

Катям һаман ышанмый.

– Юкны сөйлисең, ул күптән һәлак булгандыр инде, – ди.

Шул вакыт мин түзә алмадым, эчтә нидер өзелеп төшкәндәй булды, күзләрдән яшь агарга тотынды, мин эчкә атылдым... Калганын хәтерләмим.

Бераздан, инде тәмам тынычлангач, Катяга:

– Сине алырга килдем, әйдә, киттек, – дим.

– Юк, Петя, мин моннан беркая да бармыйм, син әнә кем булгансың, син инде өйләнгәнсеңдер, ә мин, ә мин... – ди. Үзенең күзләреннән бөртек-бөртек яшь тәгәри.

Шул төнне үк мин аны Брестка алып кайттым, иң яхшы врачларны чакырттым.» (Касыймов Э. Брест каһарманы // С.ә., 1958, №2, 65 б.)

Ләкин инде соң булган, табиблар ярдәм итә алмаганнар, чөнки Екатерина Гаврилова параличланып, йөри алмас хәлдә урын өстендә яткан. Һәм Пётр Михайловичның хатыны Катя 1956 елның декабрендә үлгән.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, без моңа кадәр Советлар Берлеге батыры, туган Татарстаныбызның Питрәч районы Күн авылыннан чыккан Пётр Михайловичның тормыш юлы хакында русча-татарча документаль әсәрләр белән таныш булсак та, кинофильмнар карасак та, аның язмышындагы мондый гыйбрәтле фактны белми идек. Татар халкының сәләтле язучысы, очеркчы буларак танылган, әмма фани дөньядан иртә китеп барган Эдуард Касыймов, ниһаять, күзебезне каплап торган кара пәрдәнең бер почмагын ачтырды. Ул очеркны язар өчен иң элек каһарманның Казанда Гоголь урамындагы фатирында үзе белән күрешеп, төн буе сөйләшкән һәм язарына искиткеч күп «азык» алган, кадерле истәлекләрне блокнотына да, «күңел дәфтәре»нә дә теркәп куйган.

Ватанпәрвәрлек темасы бүген яңадан актуальләшкәндә, яшь буын Пётр Гаврилов кебек геройларыбызны онытмаска тиеш.